УДК
ББК
Н

Казан (Идел буе) Федераль университетының журналистика һәм социология факультеты Гыйльми советында расланган.

Рецензентлары:
**Гарифуллин В.З**. – филология фәннәре докторы, профессор.
**Сөнгатов Г.М.** – филология фәннәре кандидаты, доцент.

**Низамов И.М.**

Татарча әдәби редакцияләү: Югары уку йортлары өчен дәреслек.– Казан: Казан (Идел буе) федераль университеты нәшрияты, 2012. – 159 б.

Кулланма беренче нәүбәттә югары уку йортларының журналистика һәм нәшрият белгечлекләре буенча укучы студентларга – булачак редакторларга тәкъдим ителә. Ул, шулай ук, эшчәнлеге китап, матбугат, радио, телевидение белән бәйле, текст белән эш итүче белгечләрне, галим-педагогларны, иҗатчы авторларны, һәр китап сөючене кызыксындырыр дип өметләнәбез.

© Казан (Идел буе) федераль университеты, 2012
© Низамов И.М., 2012

# Кереш сүз

Хөрмәтле Студент!

Хәзерге заманда – җәмгыять күпчелеге белемле кешеләрдән торган бер вакытта – язу-сызу һәркайсыбызның диярлек көндәлек ихтыяҗына әверелде. Фикерне язып белдерү, язган фикерне кабул итү (уку, тыңлау, күрү һ.б.) киң таралып, бу күренеш кешеләрнең аралашу колачының киңәюенә, иҗтимагый активлыкларының тагын да үсүенә уңай йогынты ясый.

Үзең берәр язма язасыңмы, әллә башка берәү язганны төзәтәсеңме – һәр очракта язмача текст белән эшләү, ягъни фикерне язмача бер формага салу – уйлануга, иҗат итүгә бәйле булган, һәр кеше үзенчә башкара торган кызыклы, катлаулы бер шөгыльдер. Мәктәптә укыганда ук тел, әдәбият, психология һәм мантыйк (логика) дәресләрендә текст белән эшләүнең – аны редакцияләүнең башлангыч төшенчәләре, кайбер күнекмәләре бирелсә дә, тормышта без әледән-әле бу хакта махсус белем, күнекмәләр җитмәвен тоеп яшибез, вакыт-вакыт кулланмаларга, белгечләргә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булабыз.

Менә шуннан ук аңлашыла: халыкка көн саен тәкъдим ителә торган дистәләрчә газет, журналларны, күп төрле китап, брошюра, афиша, листовкаларны, радио, телевидение тапшырулары текстларын, әлбәттә, мондый башлангыч мәгълүмат, гади күнекмәләр белән коралланып кына әзерләп булмый. Бу катлаулы, җаваплы эшне махсус белгечләр – редакторлар башкара.

Булачак журналист университеттан редакторлык һөнәрен дә үзләштереп чыга. Моның өчен аңар **«Татарча әдәби редакцияләү»** курсы тәкъдим ителә. Сезнең кулда менә шул курсның уку кулланмасы.

Курсның предметы редакторлык хезмәтен, ягъни редакторның кульязма өстендә эшләү алымнарын, методикасын анализлау, өйрәнүдән гыйбарәт. Курс студентларны әдәби редакцияләү барышының нәзари-методик нигезләре, текстны анализлау, автордан төзәттерү, эшкәртү алымнары белән таныштыру максатын куя, аларга язма текстның (әсәрнең) эчтәлеге белән формасының ярашылган булуына, композициясенең төзек, эчтәлегенә туры килгән, үтемле булуына, фикер агышының мантыйкый эзлекле, аһәңле, тел, өслүб (стиль) ягыннан җиңел аңлаешлы, тиз укылышлы булуына ирешер өчен күнекмәләр бирүне күздә тота.

Бу дисциплинаның өлкән курсларда укытылуы – очраклы хәл түгел. Шуңарчы студент, башка фәннәрне өйрәнеп, редакция коллективларында берникадәр хезмәт, иҗат гамәлләре үтеп, бер яктан, редакцияли торган текстның әсәр буларак төрен, жанрын, төзелешен таный, анализлый, бәяли белергә, икенче яктан, бердәнбер төп коралы – ана телен, аның төзелешен, хәрәкәттәге хәлен (сөйләмне) төпле үзләштерергә, өченче яктан, граждан буларак та, сәяси, әхлакый, хезмәти чыныгу чоры үтеп, берникадәр тормыш тәҗрибәсе тупларга өлгерә. Ә редакторга бу өч нәрсә һава, су,

ризык кебек үк кирәк. Курсны өйрәнү барышында да студентлар шушы юнәлешләрдә даими укырга, белем байлыкларын өсти, яңарта торырга бурычлы.

Уку барышы лекцияләр тыңлаудан, гамәли дәресләрдә күнегүләр үткәрүдән гыйбарәт. «Редакциядә иҗат көне» һәм башка дисциплиналарны үзләштергәндә дә редакцияләү күнегүләре алырга мөмкин. Программа азагында бирелгән әдәбият исемлегенә игътибарлы булырга, ярдәмлекләр белән дә мөстәкыйль эш итәргә, лекция, гамәли дәресләрдә актив булырга киңәш итәбез. Язма эшләрне дә үз вакытында, сыйфатлы итеп үти барырга кирәк.

Хәерле сәгатьтә, булачак редакторлар!

# ***Кереш тема:*** **“Татарча әдәби редакцияләү” курсының предметы, максаты, бурычлары, уку-өйрәнү тәртибе**

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге*

***Редакцияләү, редакция, редактор*** төшенчәләре ни аңлата? Матбугатта, радио, телевидениедә яисә башкача бәян ителергә тиешле татарча текстларны әзерләүнең методик нигезләрен, һөнәри алымнарын өйрәнә торган фән буларак әдәби редакцияләүнең асылы: предметы, төп категория-төшенчәләре, максаты, бурычлары.

Китапның, матбугат, радио,-телевидение, интернетның, башка мәгълүмат чараларының тормышыбызда тоткан әһәмиятле урыны, бүгенге хәле, бурычлары. Аларның укучы, тыңлаучы һәм тамашачыга йогынтысын, үтемлелеген, сыйфатын күтәрүдә редакторның роле һәм җаваплылыгы. Җәмәгать фикере – редактор эшенә бәя. Редакцияләү – иҗади хезмәт.

Автор тексты – редакторның эш предметы. Аны төзәтүнең – иҗтимагый-сәяси, фәнни һәм әдәби эшчәнлекләрне берләштергән бөтен бер методик система тәшкил итүе. Бу системаның төрле мәгълүмат чараларында (китап, газет, радио, телевидение, күргәзмә агитация, интернет һ.б.) төрлечә гамәлгә ашырылуы, төзәтүнең төрле уңай алымнарын туплавы.

Автор белән редактор мөнәсәбәте турында гомуми төшенчә. Редакторның текстны автор белән бергәләп төзәтүенең хокукый, психологик, техник яклары.

Редактор эшчәнлегенә кагылган төп төшенчәләрнең (***редактор укуы, анализы, бәяләмәсе һ.б***.) кыскача асылы. Текстта китә торган мәгънәви, фактик, композицион, техник, тел-стиль һәм башка хаталар турында беренчел мәгълүмат. Текстны төзәтү методикасы. Төзәтүнең төп төрләре. Редактор эшенең оештыру, иҗади һәм техник ягы. Бу эшчәнлекнең компьютер һәм башка техник яңалыклар белән бәйләнеше. Редактор һәм башка һөнәр ияләре.

«Татарча әдәби редакцияләү» курсының бүтән фән, дисциплина, курсларга мөнәсәбәте. Курсны өйрәнү барышы. Язма-контроль эшләр үтәү тәртибе. «Редакторның иҗади йөзе» темасына (анкета нигезендә) реферат язу, аны яклау. Досье. Әдәбият. Мөстәкыйль уку, күнегүләр үткәрү тәртибе.

Яңа фән-дисциплина өйрәнүгә керешәбез – “Татарча әдәби редакцияләү” курсы. Асылы нидән гыйбарәт? Курс атамасындагы һәр төшенчәне ап-ачык күзалларга кирәк. Мәсәлән, **редакция, редактор, редакцияләү**. Болар, гомумән алганда, таныш сүз, төшенчәләр. Шулай да һәркайсының асылына тәмам төшенеп җитәргә кирәк. Мәсәлән, нәрсә ул редакцияләү? Әйдәгез, бергәләп төшеник.

Сорау – җавап рәвешендә барган дәрес-әңгәмәдә **әсәр, автор, текст, төзәтү, эшкәртү, басарга әзерләү** һәм башка төшенчәләр дә телгә алыныр. Бәхәс тә чыгар. Әйтик, **редакция, редакцияләү** – берничә мәгънәле терминнар. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә менә мондый вариантлары теркәлгән: Редакцияләү, редакция: 1) текстны эшкәртү, төзәтү эше: аны басу өчен әзерләү. 2) китап, газета, журналларны һ.б. текстларны басарга әзерләү, төзәтү һәм бастырып чыгару эшләренә җитәкчелек итү (586 б.).

Сүзлеккә теркәлмәгән тагын бер мәгънәсе бар: фикерне үзгәртеп, бүтән рәвешкә салып белдерү. Мәсәлән: *Бу фикерне бүтәнчәрәк редакциядә әйтергә кирәк*, диләр.

Менә шушы төшенчәләрне бербөтен эш-гамәл дип, язма текст белән бәйле акыл эшчәнлеге дип күзалласак, аны иҗадый, иҗтимагый, әдәби-журналистлык эшенең бер төрен тәшкил итә дип белербез. Аны өйрәнә торган фән исә **әдәби редакцияләү** дип атала да инде.

Язма текст белән бәйле бу эшчәнлекнең төп максаты – ул шушы җәмгыятьтә яшәүче кешеләрнең үзенә тәкъдим ителгән текстка иҗтимагый ихтыяҗын канәгатьләндерерлек булуына ирешү. Бу ихтыяҗ нинди таләпләрдән хасыйл була? Россия матбугатының, шул җөмләдән татар матбугатының да гасырлар буена тупланган редакторлык эше тәҗрибәсенең үзенә күрә кагыйдә-тәртибе береккән – текст өч таләпне канәгатьләндерергә тиеш: тема дөрес сайлап алынганмы, ул дөрес башкарып чыгылганмы, тиз аңлаешлы, үтемле чаралар белән җиткерелгәнме.

Әлбәттә, бу таләпләр иң башта текстны беренче язган кешегә – авторга куела. Шул ук вакытта автор белән укучы арасында **арадашчы**-медиатор – редактор булуы, аның әдәби редакцияләү дигән катлаулы бер иҗадый-иҗтимагый хезмәте булуы тарихи бер күренештер. Бу күренеш автор башкара торган хезмәттән дә, редакторның үз мөстәкыйль хезмәтеннән дә хасыйл була. Менә ни өчен редактор исеме китапта булсын, газет-журналда, радио,-телевидение тапшыруында булсын һәрвакыт автор исеме белән янәшә, бергә куела.

Гәрчә, әдәби редакцияләү фәне турыдан-туры инде автор тарафыннан әзерләнгән текстка бәйле булса да, аны әзер текст белән генә бәйле гади бер техник эшкәртү эше генә дип карау һич дөрес түгел. Ә бүгенге тормышта әле андый ялгышулар очрый. “Мин редактор, миңа текст бирегез”, дип утыручылар да бар әле. Редактор хезмәтен киңрәк яссылыкта карарга кирәк – тар кысалы шөгыль дип түгел, ә бәлки теге яки бу иҗтимагый эшчәнлекнең (әйтик, иҗтимагый-сәяси, әдәби-журналистик, фәнни һ.б.) аерылгысыз өлеше, дәвамы дип күз алдына китерергә кирәк.

Татарның бөтен редакторлык тарихы моңа мисаллар белән тулы. Ә бу тарих мең елдан да ашып киткән. Кол Галинең “Йосыф кыйссасы”ның гына да 400ләп кулъязма нөсхәсе саклана. Һәркаюсы диярлек төрледән-төрле үзгәреш-төзәтмәләр кертелгән текстлар. Редакторлык эше. Ул

чакларда әле махсус шундый һөнәр ияләре булмаган, андый изге хезмәтне шәкерт, мөгаллим, хәзрәтләр, шагыйрь, чәчәннәр башкарган.

Татарча басма текстлар китап, календарь, газет-журналлар сыйфатында дөнъя күрә башлагач та бу эш, нигездә, әлеге шул дөньявый һәм руханый зыялылар җилкәсенә төшә. Мөгаллим, фольклорчы Каюм Насыйрый календарьлар редакцияләүнең бай тәҗрибәсен туплый башлый. Бер-бер артлы газет-журналлар басыла башлагач, милләткә Исмәгыйль Гаспралы, Ризаэтдин Фәхретдин, Габдулла Тукай, Фатыйх Әмирхан, Садрый Максудый, Фатыйх Кәрими, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов исемнәре нәкъ менә редактор буларак та танылды. Асылында алар мөхәррирләр, ягъни милләтне алдынгы карашлы фикер-тәкъдимнәр белән тәрәккыять иттерү белән янган, шул максатта китап язган, газет-журнал нәшер итүне оештырган, шул матбаганы үзе үк язган, төзәткән, бастырып, үзе үк халыкка җиткерү белән махсусан шөгыльләнгән мәгърифәтчеләр, руханыйлар, зыялылар булган.

Димәк ки, **мөхәррир** һәм **редактор** бер үк төшенчә түгел. Бүген дә аларны бутарга кирәкмәс, гәрчә берара алынмаларны “татарчалаштыру” сырхавы кабынып, “редактор”ны “мөхәррир”гә алыштыру булып алган иде. Бу – киң таралган иҗтимагый терминның дәрәҗәсенә “сугудан”, татар теленең лексик байлыгын ярлыландырудан башкага китермәде.

Хәер, безнең чор редакторларының, бүгенге редакторларның да күпчелеге халык, милләт мәнфәгатендә күренекле әсәрләр язган, җәмәгать эшләре башкара торган язучылар, журналистлар, сәясәтче җитәкчеләр, фән, әдәбият, сәнгать әһелләре. Мулланур Вахитов, Гадел Кутуй, Муса Җәлил, Шәмси Хамматов кебек редакторларыбыз чын мәгънәсендә мөхәррир дип тә танылган абруйлы затлар иде.

Бүген дә китап нәшриятләрендә, газет, журнал редакцияләрендә, радио, телевидениедә, реклам агентлыкларында, җитәкче оешмаларның матбугат үзәкләрендә редакторлык вазыйфасын иҗадый һәм иҗтимагый эшчәнлеге белән халык алдында абруй казанган мөхәррирләр – язучы, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре аз түгел.

Редактор эшчәнлегенең иҗтимагый әһәмияте, дәрәҗәсе никадәр колачлы булмасын, ул бик төгәл һөнәри вазыйфа, ул үзенә генә хас вазыйфаи һәм һөнәри билгеләр белән аерыла. Иң беренче чиратта, редактор язма текстны әдәби эшкәртүче – бәяләүче, төзәтүче, автор белән бергә камилләштерүче.

Текстка бәйле бу гамәли эш ике юнәлешне ачыклаудан башлана: 1) нәрсәне эшкәртергә, ягъни төзәтергә, 2) нәрсә белән эшкәртергә (төзәтергә). Бу сорауларны төгәл ачыклау өчен редактор бик ачык бурыч-максат куя: текст укучы (тыңлаучы, тамашачы) мәнфәгате-таләбенә туры килә торган, ягъни иҗтимагый кирәкле, кимчелексез булырга тиеш.

Шушы таләпкә җавап бирмәү фактлары, гадәттә, гомумиләштерелеп “хаталы” төшенчәсе белән бәяләнә. **Нәрсә ул хата?** Бу төшенчә-термин “Татарча әдәби редакцияләү” курсының буеннан-буена үзәктә торачак.

Хатаның асылын аңларга (кимчелек, хилафлык, каршылык, мәгънәсезлек, аһәңсез, өтек, икеле-микеле һ.б. төшенчә-төсмерләрне дә уйлап, анализлап), төрләрен (мантыйкый, фактик, структур-композицион, баш исеме, тел-стиль, техник, орфография-пунктуация һ.б. хаталар) үзләштерергә, алардан котылу алым-юлларын гамәлгә ашыру күнекмәләре бирү – курсның беренчел бурычларыннан. Аларга йөгертеп-тезислап кына күз салыйк.

Нәрсәне редакцияләү максатын ачык күзаллау һәм аны төгәл үтәр өчен редактор халыкчан рухлы, бай тормыш тәҗрибәсе булган, мөстәкыйль фикерле, киң карашлы, заман рухы белән яшәүче, яңалыкка омтылучы иҗат иясе булырга тиеш. Ул өзлексез белем өсти, тормыш тәҗрибәсен баета.

Безнең курс та татар редакторының асыл сыйфатларын ачарга, редакцияләүнең бурычларын, аның принципларын өйрәнергә, тәҗрибәле редакторларның осталык үрнәкләренә нигезләнгән күнекмәләр үзләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

Бу – редакцияләү процессының бер ягы, бер “җебе”. Икенче “җебе” ул текстны нәрсә белән, ничек эшкәртү. Мәгълүм ки, безнең коралыбыз, инструментыбыз бер генә. Ул да булса – туган тел.

Текстны эшкәртү барышында автор юл куйган төрле хаталар төзәтелә; бу кирәкле гамәл туган тел ярдәмендә башкарыла. Телне хәрәкәткә китерү – ул **сөйләм** дип атала, ягъни мотивларга бәйле рәвештә телне без текстны язганда, тәрҗемә иткәндә һәм менә аны редакцияләгәндә кулланабыз, димәк, **төзәтү барышында сөйләм оештырабыз**. Әдәби редакцияләү курсы менә шушы мотивларга бәйләп, ягъни текстның төренә карап аны төзәтү юлларын ачыклый, тел чараларын сайлап алу күнекмәләрен бирә.

Редактор нәрсәне төзәтә? Хатаны, диярсез. Дөрес. Ә нәрсә ул хата? Укучы күзаллаганга туры килмәү – ялгышлык, хилафлык-китеклек, кимчелек, диярсез. Монысы да дөрес. Хикмәт шунда ки, укучы бу кимчелекне сизсә дә аның асылын, сәбәбен еш очракта аңлатып бирә алмый; шуңа күрә автор да аны тоймаган, юл куйган. Ә менә редакторның һөнәри сәләте шул хаталарны тоеп, сәбәбен аңлатып бирүдән, хата җибәргән авторга да төшендереп, төзәтү юл-чараларын аңлата алудан, текстның төзәтелүенә ирешүдән гыйбарәт.

Әйдәгез, менә бу текстларда юл куелган кимчелекләрне тоемлап, төрләрен берникадәр тәгаенләп, төзәтү чараларын барлап карыйк әле.

*1) Безнең илдә хатын-кызлар ирләр белән тигез хокуклы* (РФ Конституциясе проекты тәрҗемәсеннән);

2) Газетларда баш исемнәре: *Кибет ишеген ачты; Тарихта бер Гата; Кешедән олы ат юк;*

3) *Альяпкыч кигән әни; Агачтан эшләнгән көрәк белән...; Үзенең автобиографиясендә Г.Алпаров боларны яза..; Аяклары белән тыпырчынып елады;*

4*) Кайбыч хакимияте быел беренче сыйныфка баручы укучыларның һәркайсына бушлай мәктәп формасы бүләк итте;*

Кимчелекләрне җентекле анализлаганнан соң, ачыкладык ки: хаталарны, чыннан да, төркемләргә була икән. Кирәк тә. Беренче чиратта, аеруча җитдиләрдән мантыйкый, фактик хаталар икән. Әсәрнең структур-композиция хаталары да (композициянең бүленеше максатка ярашлы булмый, эчтәлек белән форма нисбәте сакланмый һ.б.), баш исемендә дә кытыршылыклар китә икән. Аларны төзәтү үзенә бер методик алымнар сорала. Өйрәнербез.

Бу процессларны гамәлгә ашыру текстны һөнәри нечкә белү нәтиҗәсендә генә мөмкин. Ә текстны белү, аны җентекле анализлый алу менә мондый фәнни төшенчәләр белән бәйле:

– **текстны редактор укуы**. Өч тапкыр укыла: танышу, таркату, җыю (кушу) өчен;

– **текстка редактор анализы.** Анализ эчтәлекне анализлаудан һәм форманы анализлаудан гыйбарәт. Аерым алганда, формага анализ ясау, мәсәлән, җанрларны төпле белү белән бәйле. Аннары, әсәрнең төрен, текстның эчке һәм тышкы төзелешен тәмам ачыклап бетерми торып та (әйтик, газетың республика күләмме, әллә район күләм газетмы, корпоратив яисә шәхси (коммерция) басмасымы) аны төзәтүдә телнең нинди чараларын җәлеп итүне ачыклау кыен.

Газетны оештыру, басып чыгару белән бәйле төрледән-төрле башка факторлар да материалны тел чаралары белән камилләштерү осталыгына кайтып кала. Димәк ки, коралыбыз ана телен бөтен яклап, профессионалларча җентекле өйрәнергә (фонетик, морфологик, лексик, синтаксик, интонацион, орфоэпик һ.б. үзенчәлекләрен) һөнәри югарылыкта белергә, күнегүләр белән баерга тиешбез. Димәк, курсны үтү барышында шул фәннәрне кабат-кабат искә төшерергә, белемне тулыландырырга кирәк булыр. Аеруча әдәби стилистика, сөйләмият, социолингвистика фәннәре нигезләрен гамәли яссылыкта үзләштерү зарурдыр.

Редактор анализына нигезләнеп, ике җитди документ әзерләнә һәм гамәлгә ашырыла: **1) автор белән эшләү планы, 2) редактор бәяләмәсе.** Боларның асылын ачыклауга алдагы дәресләрдә махсус тукталырбыз.

Күренгәнчә, редакцияләү эшчәнлеге күп көч, илһам, иҗат азаплары, тәҗрибә осталыгы сорый. Юккамы иң катлаулы сәяси-иҗтимагый әдәбият төрен редакцияләү классcикларының берсе: “Әдәби эшкәртү сәнгать ул, нинди тон алуың, образлы итеп фикерләвең, урынлы чагыштырулар таба белүең бик мөһим...”, дигән.

Безнең курс менә шушы катлаулы да, җаваплы да эшнең асылын, закончалыкларын фәнни нигезләрдә өйрәтә. Тәҗрибәле редакторларыбыз “миңа ошамый”, “халык болай сөйләшми”, “фәлән язучы болай язмый”, “матур яңгырамый” кебек бәяләмә, критерийлар белән түгел, ә фәнни

дәлилләр, исбатламалар белән эш итә. Курс менә шундый эш алымнарына өйрәтә дә.

Менә шушындый методология һәм методика белән эшләү **редакцияләүнең фәнни төрләрен һәм алымнарын** барлыкка китергән, тарихи тәҗрибә буларак тупланган, береккән. Аларны әлегә санап кына китик; курсны үтү барышында берәм-берәм барларбыз:

– үзең язган текстны үзең редакцияләү;

– бүтән кеше язганны редакцияләү;

– текстны чагыштырып, төзәтеп, кыскартып, яңадан язып һәм башка алымнар белән редакцияләү.

Безнең программада, башкалардан аермалы буларак, редакцияләүнең үзгә бер төре – тәрҗемә текстын төзәтү төре дә тәкъдим ителә. Бар үзең тәрҗемә иткән текстны редакцияләү, бар бүтән тәрҗемәче текстын төзәтү.

Курс шулай ук редактор белән автор мөнәсәбәте, автор хокукы, корректорлык эше, төзәтү тамгалары, китап (басма) аппараты, техник редактор, рәссам, компьютер-программчы, типография эшчәнлеге нигезләре темаларына да мәгълүмат, күнегүләр бирәчәк.

**Курсны уку-үзләштерү тәртибе.** Лекция һәм гамәли дәресләр чиратлаштырып-берләштереп алып барыла. Досье булдыру кирәк. Лекция, гамәли эш дәфтәре. Күнегү текстлары, күргәзмә материаллар туплау өчен үзенә бер папка кирәк булыр. Әлбәттә инде, кулланылырга тиешле әдәбият исемлеге белән бүгеннән танышу зарур. Программада да, шушы дәреслекнең азагында да әдәбият исемлеге бәян ителгән. Эшне шуның белән танышудан башлыйк.

Хәерле сәгатьтә!

**Күнегү**

Үзегезнең район (шәһәр, корпоратив һ.б.) газетының яисә алдырып даими укый торган татарча бер газетның бер санына күзәтү ясагыз. Һәр матераилга карата өч сорауга җавап бирегез: а) тема дөрес сайланганмы, ә) дөрес башкарып чыгылганмы, б) әдәби яктан дөрес эшкәртелгәнме. Һәр язмага, редактор анализы ясап, ике документ әзерләп карагыз: 1) автор белән эшләү планы (хаталарны системага салып билгеләгез), 2) редактор бәяләмәсе.

**Куен дәфтәренә** (редакторлык эше турында уйлану):

***Юрий Некрасов***: минем редакторлык принцибым: төзәтергә теләмәсәң (төзәтә алмасаң), төзәтмә;

***Карл Маркс:*** барысын да шиккә ал;

***“Работница”***: һәркем теләгәнен язарга хаклы, тик язма газет битенә чыгарыла икән, без инде грамотасызлыкны, тәмсез теллелекне ишәйтергә (тиражларга) тиеш түгел, чыгырдан чыккан гыйбарәләр, хис ташуы, тупаслык, сүгенү, фикер шап-шаклыгы – монда инде редактор кулы

сорала... Медицинаның “Җәрәхәтләмә!” дигән изге кагыйдәсе безгә– журналистларга да тулысынча кагыла;

***Илдар Низамов***: безнең язучыларның, журналистларның язмалары – ул редакторларыбызның да йөзе.

## *Беренче тема*: Редакцияләүнең бурычлары

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Халыкның тәрәккыять юлында рухи ихтыяҗын канәгатьләндерүдә мәгълүмат чараларының урыны, әһәмияте. Иҗтимагый чынбарлыкны дөрес чагылдыру таләбен үтәүдә редакторлык хезмәтенең роле.

Редакцияләүнең төп бурычлары. Редакторга куела торган таләпләрнең асылы. Алар бәян ителгән законнар һәм башка документлар, «язылмаган» кагыйдәләр.

***Теманы дөрес сайлап алу бурычы.*** Теманың халык ихтыяҗына җавап бирерлек көнүзәк мөһим булуы. Шушы басма, мәгълүмат чарасының укучы, тыңлаучы, тамашачысына конкрет адресланган булуы. Халыкның матди, социаль, рухи мәнфәгатьләрен, ягъни яшәешне бербөтен итеп, комплекслы чагылдыруы. Тәрбия кыйбласы ачык, өметле булуы.

Теманы дөрес сайлап алу бурычын үтәү өчен редакторның тәҗрибә, белем, эрудиция дәрәҗәсе. Тема һәм проблема чыганаклары.

***Теманы дөрес башкарып чыгу бурычы.*** Теманы тәэсирле, үтемле итү өчен дөрес юнәлеш тоту – алдынгы принципларга таяну. Халык ихтыяҗын канәгатьләндерерлек, аның гореф-гадәт, традицияләренә туры килерлек алымнар куллану. Эчтәлеккә муафыйк форма табу. Жанр төгәллеге. Ышанычлы дәлилләр, төпле аргумент, шикләнмәслек фактларга таяну зарурияте. Йомгак, нәтиҗәгә төп таләпләр. Боларга ирешүнең чаралары.

***Теманы әдәби яктан дөрес эшкәртеп, кулъязманы басарга дөрес әзерләү бурычы.*** Текст төзелешенең эчтәлеккә туры килүе. Кисәкләргә бүлүнең (рубрикацияләүнең, сәхифәләштерүнең) үзен аклавы, материалның эзлекле, тәэсир итәрлек итеп урнаштырылуы. Текстның сөйләм, жанр рәвеше буларак дөрес эшкәртелүе. Телнең, экстралингвистик чараларның дөрес, нәтиҗәле кулланылуы. Әдәби эшкәртү осталыгына ирешү юллары; бу юнәлештә автор белән эшләү үзенчәлекләре.

Редакцияләү бурычларын бербөтен итеп күзаллау һәм гамәлгә ашыру. Тормышның үзгәрүчән таләпләренә нисбәтән бурычлар.

**Редакцияләү, редакция** сүзләре (латыйнча redactus – тәртипкә китерү) күп мәгънәле. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә хезмәт процессын аңлатканнары гына да берничә:

**Редакция** 1)Текстны эшкәртү, төзәтү эше, редакцияләү. *Әсәрнең соңгы редакциясенә керешү.*

**Редакцияләү** 1) Нинди дә булса текстны укып төзәтү (дөресләү); аны басу өчен әзерләү. *Кулъязманы редакцияләү.* 2 Китап, газета, журналларны һ.б. басарга әзерләү, төзәтү һәм бастырып чыгару эшенә җитәкчелек итү. *Муса оешманың җаны булып әверелә, ул бюроны да җитәкли, газетаны да редакцияли.* Г.Кашшаф (2 т., 586 б.).

Фикерне үзгәртеп, бүтән формага салып белдерү дә шул термин белән атала: Бу тәкъдимне бүтәнчәрәк *редакциядә* әйтергә кирәк (Газет редакциясендә утырышта сөйләгән чыгыштан).

Текст өстендә эшләүне иҗтимагый-сәяси, идеология эшчәнлегенең бер төре дип санаганда (безнең курс нәкъ шушы өлкәне өйрәнергә җыена да) бу процессны атау өчен конкретрак термин – **әдәби редакцияләү** термины гамәлдә йөри.

Редакцияләү эшчәнлеген ачык күз алдына китерү, бу хезмәтнең башлангыч күнегүләрен ала башлар өчен аны аңларга булышлык итүче төшенчәләрне ачыграк, тулырак аңлап бетерү зарурдыр. Мәсәлән, редактор төшенчәсе белән мөхәррир төшенчәсе мөнәсәбәтләрен берникадәр тәфсилләп киткән идек. **Нашир, нәшир итү, нәшрият** төшенчәләре дә шундый ук әһәмияткә ия. Редакцияләү эшенең төп объекты – **текст** иң башта **китап** белән, шуннан соң инде **нәшрият** төшенчәләре белән аерылгысыз бәйле. Бүген текстны төзәтү эшенә алынырга җыенган яшь белгечкә әлеге төшенчәләрнең асыл мәгънәсен төпле төшенеп кую савап кына булыр дип, бу эшнең классик белгечләре Исмәгыйль Рәми, Рәис Даутовның “Әдәби сүзлек” (элеккеге чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. –Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.–399 б.) китабыннан өзек тәкъдим итәбез. Шуннан алган мәгълүмат бу тема белән кызыксынып китеп, җитди материал тупларга, моның өчен янә бүтән чыганаклар белән танышырга этәреп җибәрер, дип өметләнәбез.

**Китап наширләре.** Унтугызынчы йөз башыннан алып Казан каласы татарча китап бастырып таратуның үзәге булып килә. Бездә беренче китап нашире Габделгазиз Туктамыш улы Бураш 1800–1905 елларда эшли. Аннан соң 1806–1814 елларда Гали Апанай, 1814– 1829 елларда Гобәйдулла Юнысов дини эчтәлекле китаплар (“Һәфтияк”, “Әлифба иман шартлары белән”, “Сөбател-гаҗизин”, “Сәйфелмөлек” һ.б.) нәшер итәләр.

1809 елны Казан университеты янында ачылган басмаханәдә татарча дәреслекләр, тарих һәм борынгы әдәбият үрнәкләреннән дөньяви эчтәлекле әйберләр дә басыла башлый.

1830 елларда Казанда хосусый басмаханәләр ачыла башлагач, китап бастырып кәсеп итүчеләр дә арта. Шундыйлардан Фәтхулла Амашев, Рәхимҗан Сәедов, Шәйхетдин Сәетборһанов, Хөсәен Максудов шактый санда китап бастыралар. Дөрес, боларның берсен дә чын мәгънәсендәге китап нашире дип атап булмый. Алар – үзләренең төп кәсепләре булган читек-кәвеш, кызыл мал (мануфактура), вак товар (галантерия), чәй

сәүдәсе кибетләрендә китап шүрлеге ясап, үзләре заказ биреп бастырган китап товары белән дә сәүдә итүчеләр. Заманында халык боларның һәммәсен "китапчылар" дип атап йөрткән. Моннан тыш, кибете яки шүрлеге булмаган, әмма "бу китап фәлән фәләннең хәраҗәтилә (чыгымы белән) басылды " дип, гомерендә ике-өч китап бастырып таратучы аерым кешеләр (исемнәр) дә күп булган.

1850–1860 елларда һәвәскәр китапчы Рәхмәтулла Әмирханов, 1880 еллардан алып Каюм Насыйри бездә дөньяви эчтәлекле китаплар бастырып таратучы буларак танылалар.

Аннан соң китап бастырып, китап сату эше белән махсус шөгыльләнүче китапчылар мәйданга килә.

Шәмсетдин Хөсәен улы 1875 елдан китап бастырып сату эшенә керешә. Бу нәшрият "Хөсәенев вәрәсәләре" (варислары) аталып, 1918 елгача дәвам итә. 1879 елда Фәтхулла һәм Габделкәрим Кәтиевләр, 1884 елдан Мөхәммәтгали Кадыйров, 1885 елдан Мөхәммәтҗан Минһаҗетдин улы (бусы "Борадәран Кәримевләр нәшрияты" аталып, 1920 елларгача эшен дәвам иттерә), 1880–1900 елларда Минһаҗетдин Бәкерев, календарьчы һәм китапчы Фатыйх Халиди белән Шиһаб Рәхмәтуллин. 1897 елны Ибраһим Идрисов (аның нәшрияты 1908 елдан "Милләт" дип атала башлый) бер-бер артлы татар китабын бастыру эшен җәелдереп җибәрәләр. Болар өстенә тагын сөйләнгән чорда Габделҗан Уразаев, Рәхимҗан Җиһаншин, Ибраһим Ишморатов, Нәҗип Галиәкбәрев , Мөхәммәтҗан Хуҗасәедов кебекләр догалык китаплары, шамаил, бөти кебек әйберләр бастырып көн итәләр.

Егерменче йөз башында оешкан Ибраһим Терегулов (1852–1921) белән Галиәсгар Камалетдиновларның хосусый нәшриятлары (соңгысыныкы 1906 елдан "Мәгариф" исемен ала) шактый санда матур әдәбият, фәнни-популяр, тәрҗемә китаплар, уку әсбаблары бастырып тараталар.

Егерменче йөз башында Казаннан тыш урыннарда да татар китабын бастыру эше җанланып китә. 1900 елны Оренбургта Гыйлман Кәримев нигезләгән нәшрият, 1902 елда улы Фатыйх Кәримигә күчеп, "Кәримев-Хөсәенев китап ширкәте" (1906 елдан) исемендәге зур бер нәшрият булып әверелә һәм эшен 1918 елгача дәвам иттерә. Петербургта – Ильяс Бораганский, 1901 елны Троицкида "Хезмәт" нәшрияты эшен башлый. Гасыр башыннан Оренбургта Шәрәфетдин Шәһидуллинның китап-календарьлар нәшрияты һәм сәүдәсе эшкә керешә.

1905–1907 еллар инкыйлабы көннәрендә югарыда исемнәре телгә алынган китапчылардан күбесе эшләрен туктаталар. Аларга алмашка яңа юнәлештә эшләүче коммерсант китапчылар килә. 1906 елларда Казанда – Шәрәфләр нәшрияты (соңыннан ул "Мәгариф" аталып, 1921 елгача эшли), "Китап", "Гасыр","Сабах", "Юл" нәшриятлары, Орскида – "Шәрекъ", Уфада – "Кәримев-Хөсәеневләр ширкәте", Эстәрлетамакта –"Каләм", Оренбургта – "Вакыт" (1909), "Белек" (1912), Петербургта – "Әманәт",

Мәскәүдә Карамышев нәшриятлары (“Китап”, “Каләм”, “Әманәт”, “Белек”).

Матур әдәбият, гыйльми, тарихи китаплар, уку-укыту әсбаблары, мәктәп дәреслекләре бастырып таратуда бигрәк тә “Мәгариф”, “Сабах”, “Гасыр”, “Юл”, “Кәримев-Хөсәенев ширкәте”, “Вакыт” нәшриятлары алда бардылар”.

Авторлар бу мәкаләгә менә мондый өстәмә дә биргәннәр: “Хосусый нәшриятлар, басмаханәләр һәм, гомумән, татар китабының тарихи үткәне турында киң һәм тәфсилле рәвештә академик Әбрар Кәримуллинның монографик хезмәтләрендә бәйан ителгән. Кара: У истоков татарской книги.–Казань, 1971.–С.223; Китап дөньясына сәяхәт.–Казан, 1979.–208 б.; Татарская книга пореформенной России.–Казань, 1983.–С.319; Книги и люди.–Казань, 1985.С.303; Татарская книга начала XX века.–Казань,1974.–С.319)”.

Милләткә, халыкка изге нияттән хезмәт иткән бу нәшриятләрдә, аны оештырган, хәрәкәтләндергән дистәләгән милләтпәрвәр нашир-редакторлар белән янәшәдән, аларның кул астында татарның иң зыялы, алдынгы карашлы, милләтпәрвәр, үз эшенең иң нечкә белгечләре йөзләрчә редактор-мөхәррирләр эшли. Редакторлык иҗатының башлангыч адымнары, бөртекләп җыелган осталык хәзинәсе – боларны кайчан да булса туплап, бәян итеп булыр микән!? Ә бит редакторлык эшенә чынлап торып өйрәнер өчен шулардан башка мөмкин түгелдер. Мисал өчен берсенең генә булса да, бик кыскача гына булса да истәлеген яңартып алыйк. Сүз әле генә тарихи нәшриятләр рәтендә телгә алынган “Гасыр” һәм аны оештыручы, озак еллар аны җитәкчесе, мөхәррир-редакторы булган Әхмәтгәрәй Хәсәни турында булыр.

Баягы өземтә алынган “Сүзлек...”тә анын хакында кыскача гына болай бәйан ителә: “ Хәсәни Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы (1883–1934) – нашир, әдип, журналист, тәрҗемәче. Казан арты Олы Әтнә авылында туа. Атасы – 1888 елны Казанга күчеп килгән сәүдәгәр. Әхмәтгәрәй заманы өчен житеш белем алып үсә һәм яшьтән үк әдәбият белән кызыксына. Бездә ул, нигездә,1906 елны Казанда эшли башлаган “Гасыр” китап нәшриятын оештыручы нашир һәм мәшһүр “Аң” журналының мөхәррире буларак билгеле. Моның өстенә, ул Октябрьгә кадәр татар сәхнәсендә уйналып йөргән “Денщик Гали”, “Хат болгатты” исемле русчадан файдаланып язган бер пәрдәлек комедияләр, әдәби тәрҗемәләр, әдәби-иҗтимагый мәкаләләр авторы һәм, ниһаять, атаклы “Шәрекъ” клубының актив хадимнәреннән берсе буларак та мәдәният һәм иҗтимагый тарихыбызда күренекле урын тота. Аның шулай мәгълүм булуы өчен без китап, нәшрият һәм редакторлык эше белгече Әбрар Кәримуллинга бурычлы. “Книги и люди” китабында ул “Гасыр” нәшриятына һәм аның наширләре Әхмәтгәрәй Хәсәни белән Габдрахман Рәхмәтуллинга бөтен бер бүлек багышлый. Без дә кыскача гына тасвир материалын шул бүлектән күчереп бирәбез.

Ширкәтне ачуның төп максатын баширләр болай аңлата: “ ... Бу җитди эшкә без кесә калынайту максатында тотынмыйбыз. Татар китап продукциясендә халыкны агарту максатында чыгарылмаганы да аз түгел. Безнең максат исә халыкка милли нәфис әдәбият бирү, бай урыс әдәбиятен, Көнчыгыш әдәбиятен тәрҗемә итеп бирү...”. Бу максатның сүз генә булмаыйча чынлап торып эшкә ашырылуы оешу елында гына ук 10 китап басылып чыгуы исбатлыйдыр. Нәшрият барысы 153 китап бастырып чыгара. Башка нәшриятләр белән чагыштырганда, сан ягыннан әлләни шаккатырлык түгел, әмма сыйфаты бөтенләй башкача була – нәкъ менә шул чорда халык мәнфәгатенә, аны агарту максатына туры килә торган темалар: “Театр мәҗмугасы”, “Әдәбият мәҗмугасы”, медицина, фән һәм белем, “Балалар дөньясы”, “Дәрес китаплары” мәҗмугалары.

Әхмәтгәрәй Хәсәни һәм аның иҗатташы Габдрахман Рәхмәтуллин татар нәшрият һәм редакторлык эшен алга карап, планлы системага салалар. Ягъни укучыларын алдан күзаллап, шулар ихтыяҗын канәгатьләндерү максатында аларның зәвыгы, таләбен күз уңында тотып, махсус, тематик, озын сроклы план төзеп эш итәләр. Укучы мәнфәгатенә карап, план да үзгәрә, әйтик, бер-ике елдан соң фәнни әдәбият һәм йорт эшләре дигән серияләр өстәлә. Ул чорда халыкның театр белән кызыксынуы көчәеп китүен искә алып, нәфис әдәбият китапларының драма әсәрләренең ише күбәеп китә, ә кайбер елны балалар әдәбиятына өстенлек бирелә.

Нәшриятнең йөзе аның нинди авторлар белән эш итүендә дә ачык күренә. “Гасыр”ның язышучыларының һәм тәрҗемәчеләренең исемен атап китү генә дә күп нәрсә сөйли: Г.Камал, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, күренекле галим, мәгърифәтче, укытучы-мөгаллимнәр, дин әһелләре Г.Алпаров, Х.Бәдыйгый, Г.Рәхим,С.Рәхманкулов, Ш.Әхмәдиев һ.б.

Бу курсны үткәндә ни өчен нәкъ менә шушы нәшрият эшчәнлегенә һәм тәҗрибәсенә җентеклерәк тукталырга тәкъдим итүебез тагын менә нәрсәләргә нигезләнә: “Гасыр”ның һәр басмасы иң югары сәнгати, эстетик, нәшрияти, полиграфия сыйфат таләпләренә җавап бирә; кәгазенең, иллюстрацияләнүенең сыйфаты ягыннан алар башка нәшриятнекеләрдән нык аерыла; редакцияләнү, грамоталылык ягыннан да китаплар иң зәвыклы укучыларның таләбенә җавап бирерлек була. Әхмәтгәрәй Хәсәни шәхсән үзе дә, эшендә турыдан-туры терәге- булышчысы хатыны Зәйнәп Хәсәния, ширкәттәшләре Габдрахман Рәхмәтуллин да нашир бурыч-вазыйфалары белән бергә редакторлык-корректорлык эшенә дә бик җаваплы карыйлар – бөтен эшне үзләре башкара; Бу нәшрият басмаларында аңлаешсыз алынмалар белән мавыгу, терминнарның төрлечә язылуы, урын, кеше исемнәрендә, төрле атамаларда, фактик материалда хата җибәрү очраклары, орфография һәм пунктуация хилафлыклары бик сирәк күзәтелә. Гомумән дә, бу өч шәхес тә татар редакторлык эшенең иң тәҗрибәле осталары дип танылган, күпләр алардан һөнәри осталыкка өйрәнгән, аларны тарихи тәҗрибәсе бүген дә өйрәнергә тәкъдим ителергә яраклыдыр. Шунысы да әһәмиятле: аларның һәркаюсы китап нәшрияте,

редакцияләү өлкәсе белән генә чикләнми, алар татар журналистикасында вакытлы матбугатны (аерым алганда“Аң” журналын) оештыру, нашир итү, редакцияләү өлкәсендәге бай тәҗрибәсе белән дә танылган белгечләр.

Матбугатта редакторлык тарихын өйрәнүчеләр урыс даирәсендә дә редактор һөнәренең бик борыңгы икәнен белә. Беренче урыс китап басучысы Иван Федоров 1564 елда ук әле “Апостол” китабын “төзәтергә” омтылган: аңа иҗтимагый төсмер бирергә, “җиргә якынайтырга” тырышкан. Теле, стиле өстендә аеруча тырышып эшләгән: сөйләү теленә якынайткан, аңлашылмаган урыннарыннан котылырга тырышкан.

XY11 гасырда Мәскәү басма дворының төзәтүче (справщик-редактор) галимнәре Карион Истомин, Алексей Барсов һәм Федор Поликарповның исеме дан казана. Алар Славян-грек-латин академиясенең китап һәм дәреслекләрен бастырып чыгара башлый. Урысларның күренекле редакторлары дип Н.И.Новиков, И.А.Крылов, А.С.Пушкин, В.Г.Белинский, А.И.Герцен, Н.А.Некрасов, Н.Г.Чернышевский, Н.А.Добролюбов, Г.Е.Благосветов, В.С.Курочкин, М.Е.Салтыков–Щедрин, В.Г.Короленко һәм башкалар санала. Совет-партия матбугатына нигез салган редакторлардан В.И.Ленин, А.М.Горький һ.б. күренекле редакторларның эшчәнлеге, тәҗрибәсе турында бай фәнни әдәбият тупланган.

**Әдәби редакцияләүнең бурычлары** төшенчәсе китап, газет-журнал һәм бүтән гаммәви мәгълүмат чараларын әзерләү, нәшер итү һәм адресатына җиткерүнең киң колачлы эшчәнлеге алдына куелган бурычлар белән бәйле: “китап эше белгече әдәби, иҗади, методик, оештыру, аналитик, мәгълүмати һ.б. эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра. Ул үз хезмәтенең һөнәри һәм икътисадый нигезләрен яхшы белергә, олы җәмгыяви җаваплылык тоеп эшләргә, хәзерге заман мәгълүмати технологияләрен гамәли кулланып, китап сәясәтен (матбугат, радио, телевидение, интернет һ.б. дип тә өстик – *И.Н.*) билгеләүдә зирәклек күрсәтергә тиеш (Вәлиев М.Х. Милли нәшрият һәм китап редакторы.–Казан: Мәгариф, 2006, 5 б.).

Әйткәнебезчә, шушы күп санлы, һәркаюсы, кем әйтмешли, “глобаль” әһәмиятле саналган бурычлар арасыннан бу юлы без тик бер генә бөртегенә – автор язып китергән текстны укучы таләпләренә җавап бирерлек хәлгә җиткерү максатында төзәтү бурычына гына тукталабыз.

Бу бурычны үтәү автордан кабул итеп алынган тексттан башлана. Татарның нәшер-китапчылыгының мең елдан, матбагачылыгының йөз елдан да күбрәк бай тарихы-тәҗрибәсе булганга, чираттагы менә шушы китапны, менә шушы газетны... чыгаруны үз өстенә алган редактор үз өстендә җаваплылык тоеп, шушы эшенең бурычын конкрет күз алдында тотмый була алмый.

Алдына салынган текстка тотыныр алдыннан редактор күзаллый торган бурычлар бик конкрет булырга тиеш. Алар редакторга алдан ук мәгълүм

булырга, аның аңында инде алар һөнәри вазыйфасының нигезен тәшкил итәргә тиешле. Димәк ки, бу бурычлар конкрет концептлар буларак аның аңында мәгълүм бер укыту системасында, методикасында беркетелгән, сыналган булырга тиеш. Совет хәкимияте заманында, нәшрият эшчәнлегендә дә, гаммави мәгълүмат чараларында да редакторлык эшчәнлеге бу өлкәдә нәзәри һәм гамәли тәҗрибәсе булып, шуларны рәсми, фәнни нигезләргә салып бәян иткән җәмәгать эшлеклеләре –классиклар фикерләреннән тупланган, рәсми инструкция – нигезләмәләргә әверелгән, тормыш сынаулары узып, уртак кагыйдәләргә әверелгән, шушы юнәлештәге белгечләрне укытучы урта махсус һәм югары уку йортларының программаларына салынган һәм укытылган кагыйдәләр турында бара. Тарихи Казан дәүләт университетында татар журналистларын әзерләү белән шөгыльләнүче факультетның ярты гасыр диярлек укытылучы шушы курс программасы да шуларга таянып эш итә. Безнең дәреслегебездә дә редакцияләү бурычлары, принциплары, редакцияләү методикасы һәм тәртибе шушы кагыйдәләргә нигезләнеп укытыла.

Текстны (ул матур әдәбият, фәнни, рәсми, фәнни-популяр, публицистик, журналистик һ.б. төр әдәбият тексты була ала) эшкәртергә керешкәндә һәм эшкәртү барышында редактор **күз алдында өч конкрет бурычны тотып эш итә: тема дөрес сайлап алынганмы, дөрес хәл ителгәнме, әдәби-сәнгати яктан укучыга үтемле итеп башкарылганмы?** Димәк ки, редактор шушы сорауларына уңай җавап бирә торган текстны алдан күз алдына китереп , автор текстының шуңа тәңгәл булырлык дәрәҗәгә җиткерелү максатын куя.

Бурычлар аерым-аерым аталса да, алар мөстәкыйль төшенчә-күренеш буларак күзалланса да, төзәтү барышында бу өч өлешне дә бербөтен процесс итеп башкара, чөнки максат-бурычларның соңгы нәтиҗәсе бит бербөтен китап, газет, журнал яисә радио,–телевидение тапшыруы, спектакль һ.б. Текстны укый башлап, аның темасына, эчтәлегенә, формасына, үтемлек чараларына игътибар итә барып, бу хакта автор белән сөйләшер өчен үз тәкъдимнәрен башта язма читенә төрткәләп бара (хаталарның төренә карап, төрле төстәге каләм белән), аннары инде аерым кәгазь битенә тәртип белән язып куя.

Шул ук вакытта редактор әдәби эшкәртүгә керешкәч тә теманың ачылуына, эчтәлек белән форманың (сюжет, композициягә, бизәлү-оформлениесенә) тәмам тәңгәл килеп бетүенә һәм дә текстның укучыга иң тәэсирле чаралар белән җиткерелүенә ирешү өчен иҗади уйлану, эзләнүдән туктамый.

Алай гына да түгел, бу эзләнү-уйлану процессы шушы текст белән, нәкъ менә шушы мизгел кысаларына гына да сыеп бетми, чөнки татар редакторлык эшчәнлегенең бер асыл сыйфаты шунда ки, нәшрияттә булсын, радио,-телевидение, газет,журналда булсын күпчелек редактор кульязма килеп кергәнче үк әле аның темасы, төзелеше-жанры белән хәтта

нинди стильдә, тасвир чаралары белән язылачагы, бизәләчәгеннән хәбәрдәр була, чөнки гамәлдә әсәрнең, китапның идеясе, темасы һәм шуңа ярашлы рәвештә жанры-төзелеше-композициясе, нәшриятнең, газет, журналның еллык иясә айлык планына, үзенең шәхси иҗади планына туры китереп, редактор тарафыннан уйлап табылып тәкъдим ителгән була. Шул идея, темага автор табып, ул аңарга социаль заказ бирә, булачак китапның, язманың проспектын төзетә, эш барышында аңа ярдәм итеп тора.

Шушылай эшләү редакторның бурычы, намус эше, һөнәри осталыгы булып санала, аның тормышта гражданлык позициясендә тору-тормавына, һөнәри, иҗтимагый җитлеккәнлегенә бәя дә шушыннан бирелә. Без бу тезисыбызны дәресләрдә күренекле редакто һәм язучы Кыям Миңнебаев мисалында дәлилләр белән беркетә киләбез.

Аңлашыла ки, редакторлык хезмәтен тар гына кысага кертеп йомып, аны “чип-чиста” бер һөнәр дип, үзмаксат дип карау дөрес үк түгелдер, ул – нинди дә булса бер эшчәнлекнең, әйтик, язучылык, журналистлык, фәнни, мөгаллим-педагоглык һ.б. иҗтимагый бер эшчәнлекнең аерылгысыз өлеше, дәвамыдыр. Элек-электән шулай килгән, бу – татар цивилизациясенең, мәдәниятенең, мәгърифәтчелегенең канында. Менә шушындый табигатьле, холык-фигыльле булганда, шушындый уй-хис белән яшәеш иткәндә генә редакторның хезмәте нәтиҗәлерәк, җәмгыятькә файдалырак була ала. Классик редакторларыбыз Ф.Әмирханны язучылык эшеннән, Г.Исхакыйны язучылык, иҗтимагый-сәяси эшеннән, Г.Ибраһимовны мөгаллимлек-фәнни эштән аерып карау мөмкин мени. Бездә редакторлык эшенең, редакторларның **мөхәррир** дип аталуы бер дә очраклы түгел, ул төшенчә үз эченә халык аңында да язучылык, журналистлык, мәгърифәтчелек төшенчәләрен дә алган.

Шулай да редакцияләү бер бөтен процесс булса да уку-өйрәтү һәм фәнни максатларда аны өлеш, баскыч, этапларга аерып тикшерәбез. Күренгәнчә, процессның беренче этабында редактор теманы планлаштыру һәм аны хәл итү буенча оештыру эше башкара; икенче этапта кульязмага бәя бирә; өченче этапта автор белән бергәләп, кульязманы әдәби эшкәртеп, басарга әзерли. Шушы эш барышында редакторның игътибары бая күрсәтеп киткән төп өч юнәлешкә туплана. Шуларга тәфсиллерәк тукталыйк.

Башта редакторның бик конкрет бурычлары-гамәлләреннән башлыйк әле – белгеч М.Вәлиев тә (озак еллар редактор, нәшрият директоры булып эшләде, редакцияләү турында дәреслекләр дә язды) болай ди: редактор эшне кульязманың тышкы кыяфәте белән танышудан башлый. Якынча эш схемасы түбәндәгечәрәк (менә болаерак) күз алдына килә:

x Рәсем-иллюстрацияләре, сызым-таблицалары тәртипкә салынганмы, рәсем асты текстлары бармы, чыганаклар исемлеге һ.б. кушымталары эшләп җиткерелгәнме?

x Бит саннары бөтен текст буенча (үтәли) куелганмы, аннотациясе һәм эчтәлеге төзелгәнме?

x Кулъязма (кушымталары, иллюстратив материал белән бергә) алдан килешенгән (планда күрсәтелгән) күләмнән артмыймы?

Мондый “вак-төяк”не искә төшерү һич кенә дә урынсыз түгел. Чөнки гамәлдә шушы гади генә таләпләрнең үтәлмәве бик тиздән автор белән мөнәсәбәтне катлауландырачак, кирәкмәгәнгә көч, вакыт һәм акча сарыф итүгә сәбәпче булачак. Шул “вак-төяк”ләр кулъязманың китап булуы юлында җитди киртәгә әверелә. Мисал итеп, фәнни хезмәтнең камиллек дәрәҗәсе күрсәткечләреннән берсе һәм шактый мөһиме булган гыйлми аппаратны алыйк”. (103 б.). Моңа әле без дә аерым тукталырбыз.

**Теманы дөрес сайлау.** Газетның нәүбәттәге санын планлаштырганда булсын, нәшриятнең перспектив яисә еллык планын төзүдә булсын, теманың дөрес сайлануы иң җитди мәсьәләләрнең берсе санала. Нәшриятләрнең еллык эш планнарының тематик план дип аталулары да очраклы хәл түгелдер.

Кайчан соң тема дөрес сайланган санала? Әгәр дә ул:

– халыкның бүгенге иҗтимагый-сәяси-социаль, икътыйсадый, рухый, тәрбия өлкәсендәге ихтыяҗына туры килгән, игътибар үзәгендә торган мәсьәләләрне яктырткан, ягъни актуаль булса;

– шушы газет, шушы басма укучыларына адресланган, нәкъ шуларның ихтыяҗ, мәнфәгатьләрен истә тоткан булса, зәвыкларына туры килсә; бу бит редакторның булачак китабының кемгә адресланган булуын төп-төгәл белеп эш итү дигән сүз; бу – шактый катлаулы мәсьәлә. Теманың бөтен халыкка кирәклеге аңлашыла. Әмма халык ул әле бер генә төрле укучы түгел: җенси, яшь, милли үзенчәлекләре бар, һөнәри ягы, белем дәрәҗәсе төрлелеге. Махсуслашкан нәшриятләр өчен бу мәсьәлә алай катлаулы да түгел кебек – “Фән”, “Транспорт”, “Икътыйсад”, “Мәгърифәт” һ.б. Исеме үк җисеменә туры килергә тиеш.

Ә менә универсаль, җирле нәшриятләр өчен бу җитди проблемага санала. Газетлар өчен дә шулай. Әйтик, теге йә бу теманы галимнән яздыру тиеш, тик галим, гадәттә, монография формасына күнеккән, укучысын үз коллегалары, дип яисә шуларга охшаш төркем дип күз алдында тотачак. Журналист яза икән, аның дөньяга карашы киңрәк, колачлырак. Укучыны да ул төрлерәк, гомумиләштерелгәнрәк итеп тоячак, язу алымы да тәэсирлерәк, популяррак булыр. Тик фәнни тирәнлек, фәнни анализ, мантыйкый “төпченү” җитешмәячәк;

– укучыларны гомумкешелек идеяләре белән коралландырып, аларга тормышта, хезмәттә, гаиләдә юнәлеш бирә, илһамландыра, алга, тәрәккыяткә омтылдырырга сәләтле булса;

– демократия, вөҗдан иреге, фикер хөрлеге, дөреслек рухында язылган булса;

Нәшрият планын төзегәндә редактор боларны һичшиксез истә тотарга тиеш. Беренче чиратта **теманың актуальлегенең** озакка исәпләнгән категория-бурыч икәнен истә тоту зарур. План төзегәндә актуаль темалар

таптык та ди. Тик ул бит әле әзер кулъязма түгел. Аны әле язам дип торган кеше дә юк. Димәк ки, актуаль тема табу белән бер үк вакытта аны гамәлгә ашыру хәстәрен дә күрә башларга кирәк. Ике юнәлештә дә мәгълүмат чараларының мулдан булуы сорала. Тема табу өчен дә, аны гамәлгә ашыра торган авторны табу өчен дә. Тормыш белән, җәмәгать мохите белән тыгыз даими багланышта яшәү, дәүләти һәм җәмәгать оешмалары, эшханәләр, фәнни, һөнәри, мәгариф оешмалары белән даими бәйләнештә тору, матбугат, радио, телевидение белән, алардан, интернеттан мәгълүмат алу системасын булдыру һ.б. чаралар белән яшәү.

Авторлар белән даими, иҗади эш алып бару. Авторларның һәркайсы белән бәйләнештә була, анкеталар таратып, киңәшләр белән ярдәм итү, таләп-сорауларына сизгер булу. Татарстан китап нәшриятендә заманында редсовет кына түгел, аның тематик секцияләре дә (иҗтимагый-сәяси, тарихи, икътыйсадый, балалар әдәбияте, медицина һ.б,) эшли, утырышлары даими үткәрелә иде.

Теманың оештыру (планлаштыру) хәлендәге язмышы, гамәлгә ашырылуы белән кызыксыну авторларны билгәләүне тизләтә, аннары инде авторны тизләтергә дә үзенә бер кызыксындыру чарасы була. Редактор авторга задание бирү – килешү төзү белән тынычланырга тиеш түгел, кульязма хәленә җиткәнче, аннары инде китап булып басылып чыкканчы күз уңыннан төшермәгәндә генә уңышлы эшләп, үз бурычыңны тугры үтәп була.

Дәрәҗәсенә, эш урынына карап авторга ышану бер нәрсә, план-проспект алып була, ә менә кульязма таләп итә башлагач, план-проспектның реаль булмавы, автор үзенә җаваплылыкны алмавы ачыкланса, редакторга кыенга кала.

Актуальлек төшенчәсе төрле сәбәп-мотивларга нык бәйле; ул, беренче чиратта, үзгәрә-искерә, актуальлек критерийлары да үзгәрә. Мәсәлән, нәшрият, типографиядә кульязма автор теләгәнчә тиз генә үтеп китә алмый, технология нәтиҗәне никадәр генә тизләтүгә юнәлтелгән булса да, гамәлдә әле тоткарлыклар килеп чыгып тора. Китап 1–2 елда басылып чыкса да, бу да бит вакыт дигән сүз! Мондый шартларда актуальлеккә зарар килмәсен өчен ике шарт кына кала: 1) бик нык алга карап уйлау, эш итү, 2) кулъязма хәрәкәтен ничек тә тизләтү чараларын алдан күрергә, гамәлгә ашырырга.

Тема сайлау өчен иң беренче чиратта үзәк һәм җирле хәкимиятнең, шушы газет, басманы оештыручының карарлары, күрсәтмә-киңәшләре, җитди, перспектив документлары компас булып тора.

Газет-матбугат, радио,-телевидение эше бик ашыгыч-оператив башкарыла. Монда әлеге таләп-бурычларны үтәү үзенчәлекле шартларда үтә, шуңа күрә аеруча уяулык, сизгерлек, игътибар сорала. Теманы сайлаганда аның яңалыгына, актуальлегенә сизгерлек, җаваплылык хисен авторларда да тәрбияләү даими эш булырга тиеш. Район, шәһәр газетлары, корпоратив-һөнәри газетлар еш кына шушы төбәк темаларын яктыртуны

“ваклану” санап, үзәк, өлкә газетларына, радио,-телевидениеләргә ияргә тырышалар. Төбәк укучылары да үзләре яши торган шәһәр, район хәлләренә караганда башкаладагы, әллә кайлардагы хәлләрне яхшырак белә.

Ә кайвакыт киресенчә дә була: район, шәһәр-төбәк газетлары үз эченә, үз яшәешенә йомылып кала, тема чикләре тарая, шушы район, эшханә-берләшмә җитештерә торган продукция турында сводка экранына әверелә.

Көн таләбенә, укучы теләгенә җавап бирми, көн кадагына сукмый торган битараф, хәтта тискәре йогынты ясап, аның кәефен боза, төшенкелеккә бирелдерә торган материалларның да газетка, басмага үтеп керүе ихтимал. Монда автор сизгерлегеннән бигрәк редактор уяулыгы хәл итә. Әле дә хәтердә: кыш башында тәүге кар яву мизгеле, ябалак-ябалак карның яшь чыршы ылысларына утырып, могҗизадай манзара барлыкка китерү күренеше тәэсирендә парча язган идем. Ул озак язылды, тәмләп эшкәртелде, киләсе елның кыш башына гына өлгерде. Шул мәл искә төшеп, янә тәэсирләнеп китеп, мин аны үзебезнең “Кызыл таң”га тәкъдим иттем. Яратырлар, берсүзсез бирерләр, дип көтәм. Таһир Ахунҗановның редактор итеп яңарак билгеләнгән чагы иде. Менә чакыртты. Язмамны сузды. Шундук күреп алдым: почмагында “Н.П.” (“не пойдет!”).”Бөтен халык кар юклыкка җан атканда, шушыны бирикме?” диде дә бүтән бер сүз дә әйтмичә, үз эшенә утырды. Ул кышны инде декабрь урталары җитүгә карамастан бер бөртек кар төшкәне юк, бу хәвефле хәл халыкны чыннан да бик борчый иде. Шундук үземә, язмама карата нәтиҗә ясадым: язучылыкка, анысы, бәлки ярыймдыр да, тик менә редакторлыкка әлегә...

**Теманы дөрес хәл итү.** Дөрес сайланган тема укучыны канәгатьләндерерлек башкарып чыгылса гына максатына ирешә ала. Ничек хәл ителгәндә ул дөрес башкарылган була?

– автор концепциясе укучы таләп иткән, дәүләти дәрәҗә җитәкчелек, шушы басма хуҗалары үткәрә торган кыйбла-сәясәт белән аваздаш булып, гомумхалык максатына, аның ихтыяҗына хезмәт итсә;

– автор куйган мәсьәләләр идеяле, кирәкле булып, фәнни нигездә икрар ителгән булса. Бу – авторның сәяси кыйбласы, өндәгән-үгетләгән кыйбласы ап-ачык белдерелергә, нәзәри фикерләве аңлашлы булырга тиеш дигән сүз;

–фикер укучыга аңлашлы, анык дәлилләр (аргументлар) белән, шикләнмәслек фактик материал белән, үтемле, тәэсирле тел чаралары белән бәян ителгән булса.

Әлбәттә, теманы дөрес хәл итүгә һәр автор, талантына, тәҗрибәсенә, эрудициясенә, шәхси үзенчәлекләренә карап, үзенчә килә, үзенчә башкара. Шулай да, һәрхәлдә, бу төп өч нигезләмә үтәлергә тиеш. Боларга ирешү өчен кайбер конкрет киңәш-тәкъдимнәр дә өстәп китәргә була:

– мөһим мәсьәлә үзәккә, уртага куелганмы, башка мәсьәләләрнең нисбәте сакланганмы? Үзәк мәсьәләгә игътибар җитәрлекме, башкалар аны басып китмәгәнме?

– тема кирәгенчә тирән, тулы ачылсын өчен материал, фактның нәкъ тиешлесе, әһәмиятлесе алынганмы, алар җитәрлекме?

– факт, вакыйгалар объектив бәяләнгәнме, бөтен яклап тасвирланганмы, алар эзлекле бәйләнештә (мантыйкый эзлеклелектә) күзалланганмы? Факт яисә вакыйга тышкы яктан гына бәян ителеп яисә тасвирланып, эчке асылы ачылмыйча калмаганмы? Алар заманча яңамы, искермәгәнме, вак, әһәмиятсез булып тоелмыймы, шик калдырмыймы?

– йомгак, нәтиҗә, гомумиләштерүләр, фәнни билгеләмәләр җитәрлек нигезләнгәнме, төгәл дәлилләнгәнме?

Менә шушы нигезләмәләрне редакторның гамәлдә ничек үтәргә тиешлеген бер мисалда – татар стена календарен (численник) редакцияләп бастырып чыгару процессын күз алдына китерегез әле. Монда мәҗбүри истә тотылырга тиешле постулатлар: шушы ел календаре үзенә бер бөтен әсәр – мәгълүм билгеле елныкы булуы; шушы елда гына яктыртылырга тиешле вакыйга, даталары белән үзенчәлекле әсәр; Шул ук вакытта һәр бите, мәгълүм бер көннең үзенә генә хас эчтәлек белән (шул көнне булган тарихи вакыйга, шул көн туры килгән ел фасылына хас табигать үзгәрешләре-манзаралары һ.б. белән) үзенчәлекле бер әсәр. Шушындый 365 әсәр. Төп эчтәлеге белән генә түгел, оформлениесе-бизәлеше белән дә алар бер-берсен кабатламаска тиеш. Шуннан соң әле календарь – еллар буе тупланып килгән, һәр елныкы аерым-аерым булса да аны даими укучы аңында тема-вакыйгалары белән, оформлениесе-бизәлеше белән дә хәтердә уелып сакланган, башка төр календарьлардан аерылып торган үзенә бер зур контекст тәшкил иткән тарихи бер әсәр.

Монда бит редакторга һәр биткә карата үзенчә, һәр аерым әсәргә куела торган (жанрына, авторына, бизәлешенә һ.б.) барлык таләпләрне дә үтәргә сәләтле булуы, барлык таләпләрне дә үтәр өчен бөтен көчен, белемен, тәҗрибәсен бирергә тиеш була.

Өченче бурыч –ул **теманы үтемле тел-стиль чаралары белән әдәби эшкәртеп, графика-фото һ.б. сурәт чаралары белән бизәп, басарга әзерләү.** Әдәби яктан җентекле эшкәртелеп, укучыга тәкъдим ителерлек булсын өчен текст ничек редакцияләнгән була?

–тема күтәргән мәсьәләнең эчтәлеге үзенә тәңгәл форма таба алганмы? Форма дигәндә әсәрнең төзелеше, төрле бүлек, рубрикаларга бүленеше, язу алымы, теле, стиле күздә тотыламы?

– рубрика, бүлекләргә карата эчтәлек нисбәте ничек – артык йә ким түгелме, материал эзлеклелек, тәртип белән урнашканмы? Гомумән алганда да күләм темага һәм эчтәлеккә ярашлымы? Бу мәсьәлә булачак китапның сыйфатына гына түгел, аның бәясенә дә, ягъни ни хакка төшүенә дә кагыла: моны белеп-аңлап эш ителгәнме?

– рубрика, бүлек исемнәре тема, эчтәлеккә, әсәрнең тулаем жанрына, тон-агышына туры киләме?

– әсәрнең теле, стиле ачык, төгәлме, җыйнак, аңлаешлы, аһәңлеме?

**Күнегү**

Хатаны тоемлап, ачыклагыз, сәбәбен аңлатыгыз, автордан төзәттерегез

Татарстанда ел саен 16 мең гектарга агач утыртылырга тиеш булса да, хәзергә 2 мең гектар агач кына утыртыла (Татарстан радиосы, 2011, 31 май);

## *Икенче тема:* Редакцияләүнең принциплары

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Редакцияләү бурычларын үтәгәндә принципларга таяну ихтыяҗы. Редакторның дөньяга карашы мәсьәләләре.

***Инану принцибы.*** Китапның, мәгълүмат чараларының иҗтимагый фикерне үткәрүче, гомумкешелек сыйфатлары тәрбияләүче буларак үз бурычын үтәүдә редакторның идея-кыйбласы, инанганлыгының әһәмияте. Редакторның намуслы, белемле, компетентлы булуы. Гаделлек, демократия, законлылык сагында торуы.

***Дөреслек, катгый фәннилек принцибы.*** Тормышны дөрес чагылдыру зарурлыгы. Фикер төрлелеге шартларында хакыйкатькә тугрылык алымнары. Фактның дөреслеген тикшерү юллары һәм осталыгы.

***Халык белән тыгыз бәйләнеш принцибы.*** Массакүләм мәгълүмат чараларына халык мәнфәгатьләрен кайгырткан әсәрләр, чыгышлар җәлеп итү. Авторга шул юнәлештә эшләргә булышу. Матбугатта халыкның төрле катламнарының катнашуын тәэмин итү. Редактор эшчәнлегенә карата җәмәгатьчелек фикерен туплау һәм өйрәнү. Рецензия. Китап пропагандалау һәм сәүдә эшендә редакторның урыны.

***Автор хезмәтенә игътибар принцибы.*** Текстка объектив анализ һәм гадел бәя. Кимчелекләрне бетерүдә автор белән бергә эшләү. Автор хокукы. Бу хакта законнар. Таләпчәнлек һәм ярдәмчеллек. Автор стилен саклау алымнары.

***Кульъязманы әдәби эшкәртү принцибы.*** Эчтәлек таләпләренең тел ярдәмендә үтәлүе. Әдәби эшкәртүнең максаты – фикернең аңлаешлы, ачык, төгәл, җанлы, гади, кыска, аһәңле булуына ирешү. Әдәби тел (сөйләм) нормаларын саклау. Артык катлаулылыкка яисә урынсыз гадиләштерүгә юл куймау. Сөйләмдә телдән башка чараларны (экстралингвистик, паралингвистик: тавыш, сурәт, фото, шрифт, төс, ым, ишарә, декарация һ.б.) куллану мөмкинлекләре. Текстны әдәби эшкәрткәндә автор белән эшләү этаплары һәм алымнары. Редакторның тел байлыгын арттыруы.

***Редакторның эшен дөрес, яхшы оештыру принцибы.*** Редакцияләү – иҗади эшчәнлек. Аның нәтиҗәлелегенә ирешү юллары. Эш шартларын кайгырту. Редакторны укыту. Тәҗрибә уртаклашу. Уңай тәҗрибәне өйрәнү, тарату мәсьәләсе.

Китап, журнал, газет, радио-телевидение тапшыруы – күмәк хезмәт нәтиҗәсе. Аны оештыру һәм редакторларның хезмәт өлешен дөрес, гадел бәяләү.

Принцип дигәндә редакторның дөньяга карашының, эш-гамәл кыйбласының төп нигез ташларын күз уңында тотабыз. Ул үз алдына бурыч куйган икән (бурычларны үткән бүлектә ачыклап киттек), шуларны гамәлгә ашырыр өчен хәрәкәт иткәндә шул әсәси нигезләр аңарга юл күрсәткеч маяклар, тәҗрибәи, фәнни таяну нокталары булып хезмәт итә.

Мәгълүмат чаралары арасында аерым, хосусый хуҗага буйсынган, аның сәяси, иҗтимагый, шәхси кыйблаларына буйсындырылган басмалар да законда каралган, алар гамәлдә дә аз түгел; татар газет, журналлары, башка төр басмаларда да (календарь һ.б.) алар элек тә булган, хәзер дә, шөкер, күренә башлады. Шулай да асылында мәгълумат чаралары ул иҗтимагый фикерне, ягъни шушы заманда, менә шушы яшәеш чорында җәмгыятьнең яшәеш мохитен, уй-фикерен, теләк-ниятләрен туплаган кыйбланы белдерергә тиешле дип санала. Бу юнәлештә безнең шактый бай тәҗрибә бар – совет заманы матбугаты, партия-фиркачелек шартларында, ягъни марксизм-ленинизм идеологиясе шартларында сиксән ел буена бай тәҗрибә туплауга иреште. Бу тәҗрибә әле озак елларга тәэсирле булачак. Һәм уңай, һәм тискәре тәэсирле. Һәрхәлдә бу хезмәттә без әле шул тәҗрибә тәэсирен дә җиткерергә тырышачакбыз.

Кабатлыйбыз: бүгенге редакторның эш принциплары нәкъ менә иҗтимагый фикер белән бәйле, ягъни шушы фикерне белдергән текстны төзәтү белән бәйле, бүгенге басмалар (газет-журналлар, радио-телевидение, документаль кино, реклам һ.б.) иҗтимагый фикергә нигезләнә. Кагыйдә буларак гомумиләштерелгән иҗтимагый фикер – ул шушы мохиттә, шушы илдә яшәүче төп халык массасының уй-фикерен, яшәү рәвешен чагылдыра, шушы халыкның ихтыяҗын канәгатьләндерергә хезмәт итәргә тиеш, дип санала. Бу халыкның, гадәттә аның сан ягыннан ишлерәк өлешенең берләштергән катламының иҗтимагый фикерен белдергән, шул фикерне (идеяне) алга сөргән элита өлеше (гадәттә партия-фирка рәвешендә) туплаган була, шуны дәүләтнең идарә даирәләре (патша, хөкүмәт, президент, парламент һ.б.) көндәлек хәрәкәт чарасы итеп законлаштыра, кагыйдәләргә сала. Редакторлар шул кыйбланы үтәргә тиеш була. Бүгенге шартларда бу кыйбланың инде гадәткә кергән, рәсми кабул ителеп, куллануда кагыйдә сыйфатын алган берничә принңипны хәтердә тотарга кирәктер.

**Инанганлык**

Иҗтимагый фикер гадәттә халыкның, шушы басманы укучы (тыңлаучы, тамашачыларның) ихтыяҗы-мәнфәгатенә хезмәт итәргә, хезмәт иясен якларга, тәрәккыятькә хезмәт итәргә тиеш. Аның хәрәкәтенә аларны оештыручы-гамәлгә куючылар (учредительләре) гадәттә иҗтимагый сәяси көчләр (партия-фирка, җәмәгать оешмалары, закон чыгару, мәхкәмә хәкимиятләре, турыдан-туры хәкимият органнары (хөкүмәт) юнәлеш бирә; алар мәгълүм бер идеологиягә, нәзариягә (теория) нигезләнеп (дини, руханый яшәеш кыбласы да идеология санала) эш итә.

Бер генә теориягә, идеологиягә, кыйблага буйсынып эш итеп туплаган тәҗрибә бүгенге төрледән-төрле идеология, дини кыйблалар төрлелегенә күчү шартларында ышанычлы эшләү өчен җитәрлек түгел, әлбәттә. Үзебезнең инкыйлапларга кадәрге  чорлар тәҗрибәсенә дә, төрлечәрәк шартларда эшләргә күнеккән чит илләр тәҗрибәсенә дә мөрәҗәгать итәргә туры килә.

Һәрхәлдә бу принцип редакторның нинди кыйблада хәрәкәт итүен, нинди идеягә хезмәт итүен ачык белергә тиешлеген кисәтә. Ягъни иманы тәгаенләнгән, ачык булырга тиеш. Бик гомуми генә алганда, бу принцип иң башта халык мәнфәгатен истә тотарга, гомумкешелек сыйфатларын хәстәрләүне күз алдында тота. Нинди генә талантлы, халык җанлы, милләтпәрвәр яисә толерантлы булмасын, авторның, журналистның гомуми кыйбладан теге-бу тарафка авышуы, үзенчә фикер йөртүе ихтимал. Димәк, редактор ялгышмаска, аны төзәтергә бурычлы. Иҗтимагый фикер таләпләренә нигезләнеп. Ягъни: иң кирәкле мәсьәләләрне алга куя; халык фикерен белә, шуңа таяна; хезмәт кешесен яклый; гомумкешелек мәнфәгатьләрен өстен күрә; шушы төп юнәлештә барыр өчен талантын, сәләтен, көч-куәтен җигү осталыгын тырышып юнәлтә;

Бу принципны үтәү – ул көндәлек эшчәнлектә менә нәрсәне аңлата: төрле идеяләрне белеп, ачык күзалдына китереп, үз идеясенең алардан өстенлеген ачык аңлаган хәлдә, кирәк вакытта плюрализм шартларында да эшли ала; үз идеясен гамәлгә ашыруны гамәли чараларын үтәүдә, ягъни иманны беркетүдә нык тора, үз алым-юлларын булдыра; авторга мөкиббән китми, бүтән идеяле авторга игътибарлы, тәнкыйтьчел карый; конкрет фактларга таянып эш итә; үз идеясен гамәлгә ашыруның төрле җәмәгать эшләрендә катнаша (партия-фирка әгъзасы, милли, дини  хәрәкәт чараларын хуплый, өлеш кертә һ.б.); законны яклаучы, аларны үтәүче шәхес; закон, нигезләмәләрне яхшы белә, бигрәк тә үз оештыручысы оешманың, хөкүмәтнең документларын төпле белә, хуплый, үтәүне пропагандалый; демократия, гаделлек, хокукыйлык таләп, нормаларын тоемлый, хуплый, белә, үти; шуларны авторлардан да таләп итә; автор текстының буеннан-буена (эзлеклелекне саклап) тәнкыйтьчел (шикләнеп) карый; уңай белән тискәре нисбәтен тоемлый, сакларга тырыша ("кимчелекләр үзебезнең яра"), авторда да үз әсәренә шулай карау хисе тәрбияләргә тырыша; тормыш куйган мәсьәләләргә бердәйлекле (комплекслы) карарга тырыша, беренче чиратта идеология темасын, анда

да тәрбия темасын алга куярга күнегә; вакытлы матбугат басмаларын редакцияләү оперативлык сыйфатыннан аерылгысыз; анализ, оештыру, төзәтү барышында төп кыйбла, планнан авышмаска, вакланмаска, яраклашуга–комформизмга бирешмәскә, принципиаль булырга, икейөзләнмәскә, курыкмаска; теманы яхшы белү ул аны хәбәр итү нечкәлекләре генә түгел, ә тирәнтен анализлау, гамәлгә ашыру юлларын ачыклау, пропагандалау.

Идеяле газетны редакцияләү – ул бөтен йөзен ,– исеменнән алып азаккы юлларына кадәр,– телен дә, стилен дә, фикер агышын, фактлар системасын, бизәү-иллюстрациясен дә – барысын да шушы идеягә-кыйблага буйсындыру, шул идеяле укучы зәвыгына тәңгәл булган продукция бирү дигән сүз.

Бу – әлеге кыйбла-идеянең иң мөһим, умырткасы саналган нигезләмәләренең үзәктә тотылуы дигән сүз. Андый газет бүтән темаларның өстен куелуына, мәсъәләләрнең төрлечә (каршылыклы) куелуына юл куя алмый. Татар милли матбугатында элек тә коммунистик идеяле журналистлар тугры хезмәт итеп, соңгы елларда чыга башлаганнарының да башлангычында торучылар алар булуы уңай тәэсир генә итте. Шул ук вакыта дини газетларда шундый хезмәткәрләрнең эшләве һич тә хуплана алмый иде. Әйтик, урыс телле күптиражлы газетларда секта әгъзалары үтеп кергән очраклар да булды. Әлбәттә, газетта да аларның үз идеяләрен белеп-максатчанмы, әллә очраклы рәвештәме үткәрүләре ихтимал бит.

Редакторның автор материалын уңаймы әллә тискәреме бәяләве аның чын объективлыгыннан, гаделме-түгелме икәнлегеннән торса да ул, иң беренче чиратта, үз дәүләтенең, халкының, милләтенең, оештыручы органының мәнфәгатьләрен күздә тотып кына эшләнә. Кимчелекне табу үзмаксат булырга тиеш түгел, халык фикереннән уйлаганда алар бит үзебезнең яралар, аларга тоз сибү кирәкме? Тагын шунысы бар, укучының (халыкның) көндәлек фикерендә, аралашуында йөргән кимчелек гадәти чыгышларда, хәтта аерым кешенең хатында да көндәлек күренеш, норма булып тоелса да матбугатта, җәмәгать яссылыгында ачылса, бәян ителсә ул инде “күпереп”, көчәеп китә.

Идеяне аңлатуга, пропагандалауга юнәлтелгән материаллар бик азайды, булганнары да фәнни анализга, ышанычлы чыганакларга таянып, тәҗрибәләр үткәрелеп, куллану өчен таянычлы нигезләмәләр хасил итми, версия, гипотеза хәлендә генә. Үткән буын кешеләре элекке идеяләрдәге коммунизм, социализм, халыклар дуслыгы күренешләрен нәзәри яктан нык үзләштергән, хәтергә сеңдергән булып чыкты. Хәзер ул идеяләрне чын-чыннан инкарь итәрлек пропаганда алып барылмый. Ул темалар бөреләнгән очракта да редакторларның аларны халык массаларына җиткерү осталыгы әле юк. Хәтта борын-борыннан иң бай тәҗрибәгә

ирешкән дини тема да бүгенге редакторларның “сай йөзгән” темасы булып кала бирә.

Көнүзәк тема дигәндә әлеге нәзәри, ягъни төп идеяне пропагандалауга юнәлтелгән мәсьләләр түгел, халыкның нормаль яшәешен тәэмин итү өчен төп шарт булып торган икътыйсадый, социаль, тәрбия өлкәләрен караган тема-проблемаларны да үзәккә кую әһәмиятле, редактор аларны һич тә икенче, ярдәмче планда дип хис итәргә күнекмәскә тиеш. Авторның теманы вагайтуына, укучыларның аларга битарафлыгын тәрбияләүгә булган кимчелеген редакторның төзәтүе зарур. Бүген укучы җитди дип исәпләгән, аны актуаль дип санаган мәсьәләне газет “тирән сөрергә”, нәтиҗәсенә ирешерлек “тикшеренү” үткәрергә тиеш;

Газетлар, радио, телевидениегә оперативлык бик мөһим. Илдәге һәм аннан читтәге һәр җитди яңалык, вакыйга, күренешкә нәкъ вакытында бик оператив бәя бирелергә, укучыга җиткерелергә тиеш. Радио, телевидение, интернеттан газет бу ягы белән – хәбәр итүе белән бергә оператив анализ бирүе белән дә – өстен тора Газетның соңга калуы аның иң зур кимчелеге санала. Искергән матераилны редакциялəп утыручы редактор анахронизм, гайре табигый саналырга тиеш.

Әйткәнебезчә, газет хәбәр итү белән генә канәгатьләнә алмый, ул аңа бәя бирергә дә, анализлап, укучыга кирәкле нәтиҗә дә ясарга тиеш. Журналист йә бер ягына, йә икенчесенә һәвәс була, шул юнәлешне тота, ә менә редакторның һичшиксез ике юнәлештә дә сәләтле белгеч булуы шарт. Бигрәк тә татар милли журналистикасының, татар редакторларының үзенчәлеге шунда да: алар көнбатыш журналистикасына хас “сенсация” артыннан куу чиренә бирешмәделәр, хәбәр итү җитезлеге белән анализ җитезлеген бергә үреп бару осталыгына ирешә килделәр.

### Халыкчанлык. Халык белән тыгыз бәйләнеш принцибы

Бу кыйбла ике юл белән гамәлгә ашырыла: халык турында, аның фикер-теләкләрен, ихтыяҗларын үзәккә кую, даими язу; аның вәкилләренең авторлар-хәбәрчеләр вәкиллегендә күбрәк җәлеп итеп, матбугат эшчәнлегендә катнашуына ирешү. Менә бу ике кыйбла да редакторның һәр бурычын гамәлгә ашырганда истә тотылырга тиеш. Әйтик, теманы сайлаганда укучылар катламнарының барлык якларын истә тоту (яшен, җенесен, яшәү төбәкләрен, социаль хәлен, белем дәрәҗәсен һ.б.). Элекке елларда редакторлар укучылар составының өч катламын – эшче, крестьян, зыялы-интеллигентның катнашуын истә тоталар иде. Бу нисбәт сакланырга тиеш иде.

Халык мәнфәгатенең үзәктә булуы – аеруча әһәмиятле шартларның берсе. Монда яңалыкка, үсешкә юнәлтелгән мәсьәләләрнең даими, эзлекле яктыртылуы мөһим. Хезмәт кешесенең тормышын, ихтыяҗларын, омтылышын, теләк-өметләрен даими өйрәнеп, аларны гел үсештә күрсәтеп торуы зарур. Җитәкчеләр дә шулар аша халык белән бәйләнеш тотарга

тиештер. Бу бәйләнешне дә даими яктыртып тору әһәмиятле. Моңа соңгы чорларда матбугат та, аны оештыручы хуҗалар да игътибарны киметте.

Матбугат эшчәнлегенә аны укучыларның төрле катламнарын җәлеп итү белән ирешелә. Хатларны, авторларны күз уңында тотып, аларны кайгыртып эшләү – татар матбугатының да күптәнге уңай тәҗрибәсе. Авторлар составын арттырганнан-арттыра бару, тематикаларын төрләндерү, осталыкларын үстерү мәсьәләләрен даими кайгырту – ул укучылар белән элемтәне ныгыту, ягъни газетның да тиражын үстерү юлы.

Аннары, авторлар ишле, төрле булган саен газет материалларының эчтәлеге-тематикасы гына түгел, жанры, теле, стиле дә төрлеләнә.

**Тормышны дөрес һәм төгәл чагылдыру, катгый фәннилек принцибы**

Татар журналистикасында элек-электән халык инанып килгән басма сүз иң гадел, дөрес сүз, дигән таләп берегеп килгән. Бу кагыйдә газетларга да күчкән: газет ул тормышыбызның көзгесе – ул һәрчак чиста, дөрес, тормыштагыча күрсәтергә тиеш. Менә шул гаделлеккә, хакыйкатькә тугрылыгы аркасында ул гади халык арасында уңай фикер генә түгел, ә төрле түрә, чиновник, ярлылар дошманы байларда, халык исәбенә яшәүче әрәмтамакларда дошманлык хисе уята.

Ә нәрсә соң ул дөрес чагылдыру, нәрсә соң ул дөреслеккә, фәнни хакыйкатькә туры китереп редакцияләү? Бер генә фактик материал да укучыда шик уятмаска тиеш. Моңа ирешү өчен безнең элгәрләр фактны тикшерүгә күп көч сала торган булган. Әле без яшь чакта редакцияләрдә җитди материалларны тикшерү өчен урыннарга махсус бригадалар җибәрәлә иде. Авторларны дөрес язарга өйрәтү дәресләре эшли иде. Нәшриятләрдә “кече редакторларга” фактик материалны чыганаклардан махсус тикшерү функциясе йөкләнгән иде. Әле сыналып бетмәгән авторларны тикшерү, аларны өйрәтү методикасы бар иде.

Татар редакторлык эшчәнлегендә тәрҗемә текстларын төзәтү методикасының гасырлар буена бөртекләп тупланган тәҗрибәсе бар. Гомумән дә бу принцип буенча нәшрият эшчәнлеге үзенчәлекләрен җентекләп өйрәнәсе бар, элек кулланып та заман шаукымы белән урынсыз гамәлдән төшерелгән гамәлләрне (мәсәлән, нәшрияттә ике корректорның кычкырып чагыштырып укуы һ.б.) кабат торгызу хәстәрен күрергә иде.

**Автор хезмәтенә игътибарлылык принцибы**

Автор хезмәтеннән аермалы буларак, редакторлык эше бүтән һөнәри эшлекләләр белән мәҗбүри бәйләнештә булуында. Ул бер яктан укучыдан (тыңлаучы, тамашачы), икенче яктан автордан аерылгысыз булуы (медиатор) белән үзенчәлекле. Иң башта ул автор белән аерылгысыз бәйләнештә. Бу бәйләнешнең нинди булуыннан аның хезмәтенең нәтиҗәлелеге билгеләнә, бәяләнә.

Редакторның үзенең шәхси иҗат йөзе булу зарур, тормыш тәҗрибәсе арткан саен аның бу йөзе – ягъни осталык дәрәҗәсе артканнан-арта бара. Шул ук вакытта ул авторларының иҗади шәхси йөзенең дә мөстәкыйльлегенә, камилләшә, остара баруын (классик әйтмешли, корреспондентларның үз йөзләре төссезләнмәсен, үтә интеллигентланмасын, аларның рухы, стиле, үзенчәлеге саклансын өчен) даими хәстәрләргә тиеш. Автор белән эшләү – аның төп бурычларыннан. Авторының фикерләү, язу үзенчәле булу, текстта аның саклануы һәр редакторның дәрәҗәсен күтәрә. Автор язмасының "шома", штампланган хәлдә булуы редакторны борчырга тиеш, калыпланган язмада хата китү куркынычы күбрәк. Анда авторның фикерләү, язу алымы чагылмый. Әйтик, журналны яисә газетны укыганда ул бик шома, барлык материал да бертөрле, бер тында укылса, авторлар бар да бер төсле яза, дигән нәтиҗәгә киленсә, бу инде редакторның да кимчелеге санала. Авторларның төрлечә уйлавыннан, язуыннан курыкмаска кирәк. Әйтик, бер үк темага төрле автор төрле факт, мисал китерә ала. Язу алымына, тел, стиль үзенчәлекләренә килгәндә дә төрлелекне сизү, хуплау сорала. Әйтик, төрле автор һөнәренә, авылныкымы, шәһәрнекеме булуына, яшенә карап берсе туры мәгънәле сүз-берәмлекләр белән, икенчеләре күчерелмә мәгънәле сүз, гыйбарәләр белән (троплар) эш итәр. Фразеологизм, мәкаль, әйтемнәрне дә төрле автор төрлечә куллана. Аларны мондый эзләнүләргә дәртләндереп торырга, төрле чыганаклар табарга булышырга кирәк.

Текстны автордан эшкәрттертмәгәндә ни килеп чыга:

– гранкага сыймаган берничә генә җөмләле "койрыкны" кисеп ташлау да авторның ризасызлыгын тудыра. Бер караганда андагы мәгънә текст эчендә кала да кебек, әмма автор аңа азактан аеруча басым ясап әйткән була;

–хәлне, кешеләрне, алар авызыннан әйтелгән сүз, фактларны автордан да әйбәтрәк тагын кем белә инде!

Автор – хәер сораучы түгел. Ул тулы хокуклы иҗатчы. Аның хокукын редактор яклый. Ул нәшрияттә аның ышанычлысы. Редактор бигрәк тә яшь авторларны кайгыртырга, аларга сизгер булырга тиеш. Редактор үзе дә башлангычында журналист, язучы, редактор булып "үскәч" кенә ул аларны онытырга, аларга өстән карамаска тиеш.

Автор хокукы. Халыкара төшенчә һәм термин. Бар рәсми төшендерү, акт документлары. Боларны редактор яхшы үзләштергән булырга, гамәлдә үтәргә тиеш.

**Кулъязманың телен, стилен камилләштерү принцибы**

Редактор югары культуралы, белемле, эрудицияле, әдәбиятне һәм әдәби телне яратып, аны профессиональ югарылыкта белүче, тел ярдәмендә авторның әсәренең сыйфатын нык яхшыртырга булыша торган кеше. Телне сиземләү, аның белән оста эш итү – редакторның сыйфат билгесе. Редактор – тел белгече, сөйләм остасы.

Текстта нәкъ кирәкле сүзне сайлап куюның төп максаты – ул укучыга, тыңлаучыга нәкъ кирәгенчә тәэсир итү. Классиклар да бит шәкертләрен бөтен эш сүздән башлана дип өйрәткән. Сүз ул әйтергә теләгән фикернең нәкъ үз мәгънәсен чагылдырырга тиеш. Шушы басманы алдыручы барлык кеше дә бертөрле аңларлык булсын. Татар журналистикасында, нәшрият-китапчылык эшчәнлегендә дә халык ничек әйтә шулай язарга омтылу матбугат элгәрләренең асыл кагыйдәсенә әверелеп, моның өчен татар телен нәкъ менә татар халкының сөйләү теленә яраклаштыру максатын безнең мөхәррир язучыларыбыздан бигрәк, мөхәррир редакторларыбыз куйган, шул максатка ирешү өчен алар иң күп көч салган. Татар матбугаты сөйләме баштагы чорда чыннан да халыкчанлыгы белән аерылып торган. Аннары акрынлап-акрынлап әдәбилек белән гади сөйләм урталыгын табуга ирешкән. Монда Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан. Г.Исхакый, Г.Ибраһимов кебек редакторларның ифрат зур көче, мөхәррирлеге салынган.

Бу принципны гамәлгә ашыруда гарәп теле, аннары урыс теле тәэсире белән фәнни нигездә, эзлекле эш итү мөһим булган. Бу иҗади, фәнни эш әле дә дәвам иттерелә. Бүгенге редактор бу кыйбладагы тәҗрибәне өйрәнүгә җитди игътибар итәргә тиеш. Укучы зәвыгын редактор тоемларга, даими күзәтергә, бер яктан икенче якка ташланмыйча язмача белән әйтмәчә нисбәтен дөрес саклау методикасына күнегергә тиештер.

Ә укучы зәвыгының нигезләре күп еллык практика белән тәгаенләнгән: язма, чыгыш ачык һәм төгәл, кыска һәм тәэсирле булырга тиеш. Кыскалык, төгәллек (лаконичность) бигрәк тә газет материалларыннан таләп ителә. Автордан еш кына материалын кыскарттырырга туры килә. Монда да редактор методикасы һәм осталыгы сорала. Тәҗрибә күрсәткәнчә, очраклы, ашыгыч, коньюктур кыскартулар вакытында хата китүчән: бер хатадан котылганда ике-өч бүтән хата китүе турында мәзәкләр дә йөри. Бу кирәкле эшне ул авторның үзеннән эшләттерү хәерле. Янәшә утырып төшендерү, үз күз алдында эшкәртү белән бергә кыскартуның сәбәпләрен, мөмкинлекләрен ул уку барышында әзерләгән өстәмә фикер, тәкъдимнәре белән дә, хат, записка, телефоннан сөйләшүне “төртеп кую” рәвешендә теркәлгән өстәмә күрсәтмәләре белән дә башкара.

Гадәттә автор кыскартуга тискәре карый, ул моны редакциянең, редакторның махсус эше дип саный, еш очракта каршылык күрсәтә. Монда аңлату эше, авторның хатасын тануына ирешергә, үзе төзәтүенә, инанып башкаруына ирешергә кирәк. Кайвакыт авторга булышырга да кирәк була, тик редактор моны үзе эшләми, ә бәлки авторга, әдәби эшкәртүче сыйфатында, теманы яхшы белгән, редакцияләү тәҗрибәсе дә булган автордаш-белгечне тәкъдим итә.

Газетта вакыт-вакыт текстны инде верстка барышында төрле техник сәбәпләр белән мәҗбүри кыскартырга туры килә. Бу очракта да һичшиксез аны эшкәрткән редактор белән киңәш тотарга, ә ул үз чиратында автор белән килештерергә тиеш була.

Гомумиләштереп әйткәндә, автор белән эшләү – ул:

– автор белән даими, системалы эшләү, ягъни аны кайгырту, үстерү;

– әсәрнең төп, принципиаль мәсьәләләренә игътибар бирә, автор игътибарын да күбрәк шуларга юнәлтә;

– әңгәмә таләп итү, изге ният тонында барса да кече күңеллелек, иптәшлек, булышу мохите сакланырга тиеш. Бер хатага бәйләнеп, авторның бөтен эшен "бетерү" куркынычы китереп чыгарырга ярамый. Әңгәмәне, шулай ук, киңәш тоту тонында алып бару хәерле, күрсәтмә бирү, сабак, үгет-нәсихәт тонына юл куймаска омтылырга кирәк. Максат авторның хатасын ачу, кимчелеген күрсәтү генә түгел, аны бүтән хаталардан, кимчелекләрдән йолып калу, гомумән дә аңа белем бирү, өйрәтү кыйбласын тотарга кирәк. Аеруча яшьләргә игътибарлы булу сорала. Шул ук вакытта барча авторлардан да, аеруча өлкән, тәҗрибәле авторлардан өйрәнү, гамәли күнегүләр алу мөмкинлеген дә кулдан ычкындырмаска кирәктер. Иң мөһиме нинди генә абруйлы, дәрәҗәле автор булмасын, аңа мөкиббән китмәскә, әсәрнең идея-сәнгати ягының йомшаклыгына юл куймаска!

**Редактор эшен төгәл, яхшы оештыру принцибы**

Редакция эшчәнлеген, редакторның көндәлек эшен оештыру, аны кайгырту, алдан хәстәрләү – сыйфатлы редакторлык эшенә ирешүнең беренче шарты. Иң башта бу процессның күмәк эш булуын истә тоту, тырыш, белемле коллектив туплаганда, ул уңышлы эшләгәндә генә аерым редакторның шәхси иҗади эшен гамәлгә ашырып була. Коллективта, редакциядә моның өчен барлык шартлар булдырылырга тиеш:

– газет, журналның һәр саны алдан. планлы рәвештә күмәк хезмәт нәтиҗәсе буларак әзерләнгән, редакцияләнгән булырга тиеш; Югыйсә бездә әле кайвакыт газетның иртәгә чыгасы саны очраклы әзерләнгән, коллектив карашыннан, шул ук вакытта бер күздән (баш редактор) үтмәгән материаллар җыелмасыннан "әвеш-түеш" китерелә. Аның өчен кем җавап бирәсен дә күзаллап булмый;

– материалны әзерләүдә эшнең һәр буыны әһәмиятле, монда "вак" нәрсә була алмый: баш исеме, аның текстта кайда, нинди шрифт белән урнаштырылуына хәтле, башка материаллар белән нисбәте, һәр битнең композициясе, бизәлеше – барысы да алдан күз алдына китерелгән булганда гына гомуми гармониягә, бербөтенлеккә ирешеп була.

Эчтәлек белән форма (битләрнең бәйләнеше, жанрлар нисбәте, шрифт текстында фотосурәт, иллюстратив материал нисбәте, тышкы оформление) нисбәте. Газет, журнал, китап һ.б. һәр аерым төренә карап боларның үзгәлеге. Һәр очракта эчтәлек өчен җаваплылыкка бөтен диккатьне юнәлтү, формага җитәрлек җаваплылык тәрбияләмәү кыйбатка төшүе ихтимал. Моңа сабаклар җитәрлек. Газетта да сводкалар, таблицалар, фото-рәсем асты текстларында киткән гыйбрәтле хаталарны күпләп китерергә булыр иде.

Редакторның күмәк хезмәттә булуының, башка һөнәр ияләре белән аралашып кына эшләүче булуын әйткән идек инде. Аның корректор белән, компютерчы, техник редактор, художник-рәссам, типография эшчесе белән – һәркайсы белән аерым-аерым бәйләнеше аерым норматив документлар –инструкцияләр белән регламентланган – системага салынган. Аларны үтәргә кирәк. Редакторның үзенең дә корректура остасы булуы, бу эшне бөтен нечкәлекләре белән белүе зарурдыр. Гадәттә нәшриятләрдә күпчелек редакторның корректорлардан "үстерелгән" булуы уңай күренештер. Редактор корректураның сыйфатлы, тәҗрибәле белгечләр тарафыннан һәм күбрәк укылуын кайгыртырга тиештер.

Төзәтү принципларына таянып, төзәтү методологиясе туплана. Редактор кыйбланамәсе дип атыйкмы?! Менә аның кайбер нигезләмәләре:

– Гомер буе укырга, өйрәнергә кирәк. Өйрәнүнең чиге юк. Инде барысын да өйрәндем, тәмам остардым дию мөмкин түгел....

– Төзәтергә ашыкмаска: сүзләрне сызып, бүтәннәрен яза башламаска, шулай дип үзгәртергә дип карар беркетеп куймаска; укып бетерергә, уйларга, үлчәп чыгарга; эзләргә һәм табарга, шуннан соң гына автор белән киңәшләшеп, төзәттерергә.

## *Өченче тема*: Редакторның һәм редактор хезмәтенең асылы

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

**Редактор** кем ул? ***« Мөхәррир»*** төшенчәсенә ачыклык кертү. Татарда китап басу, матбугат, радио, телевидение тарихына бәйле рәвештә редакторлык хезмәтенең һөнәри, иҗтимагый эшчәнлек буларак үткән юлы.

Кол Галинең меңеллык тарихлы «Кыйссаи Йосыф» әсәренә редактор хезмәте буларак караш. Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, И.Гаспралы, Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, С.Максудый, Г.Исхакый, Х.Ямашев, Г.Ибраһимов, М.Вахитов, М.Җәлил, Ш.Хамматов һ.б.ларның редактор буларак оештыру һәм текст төзәтү тәҗрибәсе, мөхәррирлек-редакторлык хезмәтенә карашы.

Татар редакторларына гарәп, төрек, рус һәм башка мәдәни-әдәби мирасның, мохитнең уңай һәм тискәре йогынтысы, тәҗрибәне өйрәнү, куллану этаплары. Татар редакторлык хезмәтенең өйрәнелү, тәҗрибәнең таратылу дәрәҗәсе. Г.Ибраһимов, И.Рәмиев, Ә.Кәримуллин, Р.Нуруллина, Ш.Хамматов, Ф.Әгъзәмев, М.Мәрдиева һ.б. хезмәтләрен күзәтү.

Редакторлык хезмәтенең мәгълүм бер иҗтимагый эшчәнлекнең дәвамы булуы. Мөхәррирлек – катлаулы иҗади эшчәнлек. Һөнәри процессның текст кысасыннан тыш өлеше (нәшрият планын төзүдә, авторлар белән

эшләүдә, басма продукцияне пропагандалау-таратуда катнашуы һ.б.). Текст өстендә эшләү – әдәби редакцияләү барышының төп өлеше.

Редакторның текстны укуы. Редактор анализы. Анализның предметы, эчтәлеге, механизмы, нәтиҗәсе. Текстны эчтәлек, композиция, тел, өслүб (стиль) ягыннан анализлау – бербөтен процесс. Рецензент һәм аның рецензиясе. Редактор анализы нәтиҗәсе буларак редактор бәяләмәсе, автор белән эшләү планы.

Редакторның җәмәгатьчелек алдында җаваплылыгы. Тормышны яхшы белү, компетентлы, кыйблалы-иманлы булу. Искелеккә, катып калуга, цитатчылыкка каршы тору. Һөнәреңне ярату, аны төпле үзләштерү.

Анализ барышында редактор эшчәнлегенең психологик үзенчәлекләре. Шәхси иҗат алымнары. Китап, газет, журнал, радио, телевидение, күргәзмә басма һ.б. текстларын редакцияләү үзенчәлекләре.

Редакторның эш урыны. Компьютер һәм редактор. Бүтән техник чаралардан, яңа технологияләрдән файдалану. Башка хезмәттәшләр (компьютерчы, корректор, техник редактор, полиграфчылар, рәссам-фотографлар һ.б.) белән бәйләнеш. Кулланма, белешмәлек, сүзлекләр белән эш итү.

## Татар редакторы кем ул?

Матди байлык булдыручыларны – дөнья tоткаларын беләбез: эшче, игенче. Һәркайсыбыз, бөтен кешелек аларга мәңгелек бурычта; вакыт-вакыт алар хезмәтен күрмәмешкә сабышу, санга сукмау – зур гөнаһ; мондый мөнәсәбәт беркайчан да яхшы нәтиҗәгә китерми.

Рухи азык булдыручыларны, ягъни матбугат, китап чыгаручы йөзләрчә белгечләрне – оештыручыларны, халыкка җиткерүчеләрне бер исем белән “мөхәррир – редактор” дип гомумиләштереп булыр иде. Аларга карата да җәмгыятьтә мөнәсәбәт, гомумән алганда, фәкать уңай гына. Татар редакторы – ул милли мәдәниятнең тулаем да, тарихи яссылыкта да йөзен, хәсиятен билгели торган шәхес. “Ватаным Татарстан” газетының туксан еллыгын билгеләп үткәндә инандык: милләттебездән, халкыбыздан аерылгысыз олы бер тарихи күренеш бар икән, аның бүгенге, тарихи асылын, әлеге дә баягы, шул халык вәкилләре – авторлар белән бергә тырышучы редакторлар хасил итә икән. Моңа без бөтен халык белән бергәләп газетның юбилеен билгеләп үткән көннәрдә генә дә күпме шундый затның исемен ишетеп инандык.

Егерме ике ел инде университетта “Татарча әдәби редакцияләү” курсын укытам. Редакторлык эшенә бөтен гомерен биргән, университетның борыңгы, шөһрәтле нәшриятенең иң тәҗрибәле редакторы булган, бу курсны да озак еллар укыткан, йөзләрчә редактор тәрбияләп җитлектергән

филология фәннәре кандидаты Мөнҗия Борһан кызы Мәрдиеваның эшен дәвам иттерүем белән горурланам.

Ел саен һәр кереш дәресне бер гыйбарә белән башлап җибәрәм: “Татарның редакторлык эшенең мең елдан озаграк тарихы бар”, дим. Кол Галинең “Йосыф кыйссасы” поэмасының дөньяга пәйда булу факты истә тотыла. Язма мең ел буена кулдан-кулга, ягъни редактордан редакторга күчеп, эшкәртелгән, камилләштерелгән. Аның Татарстан саклагычларында гына бер-берсеннән шактый аерылган 400ләп варианты бар.

Татар редакторы дигәндә күз алдына янә дә халкыбызның дөнъяда иң мул хәзинәләреннән берсе – ким дигәндә егерме саллы томлык басма тәшкил итәрлек авыз иҗат хәзинәсе, аны җыючылар, теркәүчеләр, язып-сөйләп шомартучылар, ягъни редакцияләүчеләр килеп баса.

Редактор-мөхәррир төшенчәсенең инде безнең аңда берегеп килүенең төп сәбәпләре – китап басу, матбугат, сәхнә иҗаты белән бәйле бер гасыр ярымлык тарихы бар: тәүге редакторларыбыздан Каюм Насыйрыйның календарьлары, бөреләнеп тә чәчәк ата алмаган, кулъязма яисә гектографта гына басылган газетларыбыз; ниһаять, Исмәгыйль Гаспралының “Тәрҗеман”ы, аннан соң инде берсе артыннан берсе зур көрәш нәтиҗәсендә дөнья күрә барган “Нур”, “Әльислах”, “Кояш”, “Йолдыз”, “Тормыш”, “Аң” , “Сөембикә” газет, журналлары һәм башкалар. Татарның беренче редакторлары дигәндә күз алдына тагын да Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин (1883–1940) килә. Ул оештырган һәм редакцияләгән “Әлгасрел җәдит” (Яңа гасыр) журналы 1906 елның 15 гыйнвареннан 1907 елның 15 маена кадәр барлыгы 17 сан Уральскида әдәби, фәнни һәм иҗтимагый журнал дип чыга. Аннары “Фикер” газеты да аның редакторлыгында һәм нәширлегендә 1905 елның 27 ноябреннән 1907 елның 13 маена кадәр 73 сан чыга.

Беренчеләр турында мәгълүматны безгә Габдулла Тукай да биреп калдырган. Ул үзе дә мөхәррир, татарның беренче мөхәррирләре белән якыннан аралашкан шагыйрь безгә “мөхәррир” төшенчәсенең төрле төсмерләрен күзалларга мөмкинлек биреп калдырган. Мәсәлән, “һәртөрле *мөхәррирләр* вә *ярты мөхәррирләр* милләтемез үлгән вә яки йоклаган дип язалар” (2 т., 9 б.). Тукайда “*сугышчан мөхәррир*” дигән төшенчә бар (42 б.). Мөхәррир эше турында ул “Фикер”нең бер санында тәфсиллерәк яза (37 б.).

Һәр газет, журнал, китап иҗтимагый вакыйга-күренеш буларак кына түгел, аларны оештырып, укучыга әзерләп бирүче редакторлар исеме белән дә милләт аңында теркәлә, берегә бара. Аларның милләт хакына, ана телебез хакына башкарылган олуг тырышлык, хезмәт җимеше булып буыннан-буынга җиткерелә бара: милләтнең горурлык билгеләре Каюм Насыйрый, Исмәгыйль Гаспралы, Ризаэтдин Фәхретдин, Гатаулла Баязитов, Фатыйх Әмирхан, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Мулланур Вахитов һәм дә башкаларны мәдәният йолдызлары дип беләбез. Бәхәссез ки, бу шөһрәтле

шәхесләребез, беренче чиратта, язучы-әдипләр, җәмәгать эшлеклеләре, мөгаллим, руханыйлар; шулай да халык аларны мөхәррир-редакторлар дип тә белә: татарның мөхәррирлек-редакторлык, матбага эшчәнлеген шулар йөзендә күзаллый. Боларга Вәли Шәфигуллин, Муса Җәлил, Шәмси Хамматов кебек яңа заман редакторлары өстәлеп китә.

Кереш дәресне менә шушындый чын-чыннан кызыксынырлык, горурланырлык фактлар белән кабызып җибәрәм дә, кырт туктап, уйга калам. Моның сәбәбен әйтеп, студентларымны да уйларга мәҗбүр итәм: итекченең итеге юк, дим, мең елдан озаграк тарихы булган редакторлык эше, татар редакторлары турында бер саллы китап-хезмәт юк, дим. Шунда ук эш тә тәкъдим итәм – менә егерме ел инде бу курсны тәмамлаганда һәр студент бер редакторны, аның эшчәнлеген өйрәнеп, реферат яза, курс, диплом эшләре башкаручылар да табылып тора. Инде шактый материал тупланды, үзенә бер мәҗмуга була алырлык. Бу хакта җәмәгатьчелеккә, беренче чиратта, нәшриятләрнең , матбугат әһелләренең үзләренә белеп тору кирәктер.

Шул ук вакытта бүген безнең алда татар редакторлык тарихының борыңгы-башлангыч дәверләрен, бай тәҗрибәсен төпле өйрәнү бурычы да тора. Дөрес, бу темага фән бөтенләй кагылмаган дию дөрес булмас. Халык язмышында, милләт тәрәккыятендә мәдәният зур әһәмияткә ия булганга, мөхәррирлек эшчәнлеген барлау-өйрәнү кыйбласына Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин кебек үзләре бөек мөхәррирләр, библиографлар йөз тоткан. Аларның хезмәтләрендә татарның кулъязма китап хәзинәсе, беренче басмалар, аларның авторлары һәм дә редакторлары турында бай мәгълүмат табарга була. Ризаэтдин Фәхретдиннең күп томлы “Асәр” хезмәте генә дә ни тора!

Үзебез шаһит булган чорда инде редакторлык, нәшрият эшчәнлеге белән кызыксынучы, максатчан юнәлешләр – әдәби тәнкыйть, библиографиянең үз белгечләре бөреләнде, кайбер фәнни, фәнни-журналистик хезмәтләр барлыкка килде. Академик Әбрар Кәримуллин, профессорлар Ибраһим Нуруллин, Миркасыйм Госманов татар мәдәниятенең һәм әдәбиятенең йөзен билгеләүче мөхәррир-редакторларыбыз Хөсәен Фәезханов, Фатыйх Әмирхан, Габдулла Тукай турында документаль әсәрләр язуга ирештеләр.

Сизәмсез, элгәрге редакторларыбыз турында иң дөрес хакыйкатьне, реаль тасвирны үзләре дә әдип-язучы, бергә-бергә иҗат иткән каләмдәше, яисә мөхәррир-редактор язып калдырган. Әйтик, язучы һәм шагыйрь Зариф Бәширинең мемуар язма-истәлекләре бүген дә кызыксынып укыла, чөнки ул үзе дә Казанда, Уфада, Оренбурда төрледән-төрле әдипләр, мөхәррирләр белән аралашып, күп кенә газет редакцияләрендә эшли. Ул Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Шәһит Әхмәдиев, Мөхәммәтҗан Сәйдәшев кебек шәхесләрне нәiъ менә редакция шартларында, иҗади, редакторлык эше хәләтендә, мохитендә күзәтә алган.

Мондый чын тормышчан факт, детальләргә бай, тасвирлы язмаларны безгә Исмәгыйль Рәмиев, Мөхәммәт Мәһдиев, Рәис Даутов кебек үзләре дә күренекле язучы-журналистлар, мәшһүр редакторларыбыз да калдырды. Аларның хезмәтләрен әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе, гыйбрәтле тәҗрибәсен эшебездә кулланасы да кулланасы. Үзләре чын үрнәк. Мөхәммәт Мәһдевнең: "Элекке татар матбугатын Рәфыйк Нәфыйговтан кала минем кадәр укыган кеше юктыр", дигәне истә калган. Бу, чыннан да, шулай. Югыйсә, ул атаклы редакторлар Фатыйх Кәрими, Фатыйх Әмирханнарның чын асыл иҗади йөзен шулай ачык, тасвирлы итеп ачып бирә алыр идемени! Галиәсгар Камал турындагы язмасын зур җаваплылык белән махсус "Г.Камал – журналист " дип шулай төгәл атарга җөрьят итә алыр идемени!

Гомерләрен нәшрият-китап дөньясын өйрәнүгә, матбугат тарихына биргән Альберт Фәтхи, Үзбәк Гыймадиев, Рашат Гайнанов, Розалина Нуруллина, Мөнҗия Мәрдиева, Рәиф Мәрданов һәм башка тикшеренүчеләребез татар редакторлары темасына шактый бай хәзинә туплауга ирештеләр. Бу иҗади чыганаклар белән танышкач, татар редакторы энциклопедиясен чыгарырга да вакыт җиткән икән, дигән фикергә киләсең.

Шәхсән үземдә мондый фикер менә быел, аерым алганда март аенда, өч сәбәптән тагын да беректе: татарларның ике олпат газеты "Кызыл таң" белән "Ватаным Татарстан"ның оешуына 90 ел тулды, киң җәмәгатьчелек катнашында фәнни-гамәли хисаплар, зур тантаналар булды, әле дә бара. Күз алдына китерегез: бер гасыр диярлек чор! Ике газетыбыз өчен дә күпме сынаулар. Халык, милләт башыннан узган нинди генә вакыйгалар аларның битләрендә теркәлмәгән дә, шул язмышны журналистлар үзләре дә башларыннан үткәрмәгән. Шуңа күрә дә татар халкы ике газетны да ярата, хөрмәт итә, аны оештыручыларны, мөхәррир-редакторларын онытмый.

Ике газетта да җәмгысе 14 ел журналист булып эшләвем, редакторлык эшен иҗатымның беренче көннәреннән үк өйрәнүем миңа аларның дистәләрчә редактор-хезмәткәрләрен күзәтергә, бүген алар турында язарга алынырга мөмкинлек тә, хокук та бирәдер. Шунысы аеруча әһәмиятледер, юбилей чаралары, бигрәк тә, фәнни-гамәли конференцияләр редакторлык эшен фәнни тикшеренүләр юнәлешендә дә бай материал калдыра. Бер генә фактка аерым тукталу зарурдыр: юбилей уңаеннан татар газетлары арасында беренче тапкыр "Кызыл таң"ның кыскача энциклопедиясе басылып чыкты. Анда татар матбугаты тарихына, редакторлык эшчәнлегенә, 350 мөхәррир-редакторның тәрҗемәи хәленә һәм иҗат эшенә караган ифрат мул материал тупланган. Боларга бу язмада аерып тукталып тормыйбыз – матбугатта махсус рецензия-бәяләмә бастырып чыгардык (Мәдәни җомга, 2008, 31 окт.).

"Ватаным Татарстан"га да шушындый мәгълумати басма әзерләп чыгарырга вакыттыр. Заманында редакциянең үз хезмәткәрләре һәм

ветераннар башлангычында редакциянең, дөресрәге, газетның бик бай фондлы музее булдырылган иде. Тик ниндидер сәбәпләр аркасында аның эшчәнлеге пассивлашты, күз уңыннан төшеп китте. Торгызырга, эшчәнлеген җанландырырга кирәк иде – ул бит бер редакциянең генә түгел, барлык укучыларның тарихи хәзинәсе.

"Ватаным..."ның фаразый энциклопедиясен күз алдына китерәм дә инде. Анда һичшиксез аның башлангычы "Эш"не оештырып җибәргән Камил Якуб, Вәли Шәфигуллин кебек җәмәгать эшлеклеләре – татарның беренче журналист-редакторлары беренче рәттә булыр. Беренче сәхифәләрен Фатыйх Әмирхан, Галиәсгар Камал, Фәтхи Бурнаш, Галимҗан Нигъмәти, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Гадел Кутуй, Муса Җәлил, Гомәр Бәширев, Мирсәй Әмир, Мөхәммәт Садрый, Габдрахман Минский, Шәрәф Мөдәррис һәм башкаларның исемнәре бизәр. Инде саналган "классиклар"ның кайберләрен үзем дә күреп белеп, аларның редакция шартларында, нәкъ менә редактор буларак ничек эшләүләрен, безгә – автор, яшъ журналистларга мөнәсәбәтен, эш алымнарын үземдә дә тоярга, киңәшләрен, таләпләрен үтәргә туры килде.

Ә инде Шәмси Хамматов, Рәис Сабиров, Мөнир Әһлиуллин кебек баш редакторлар, Флорид Әгъзәмев, Рафак Тимергалин, Гарәф Шәрәфетдинев кебек баш редактор урынбасарлары белән, Мәрьям Дибаева, Шәех Зәбирев, Зәйдулла Шәфигуллин, Марат Әмирханов, Рәшит Зәкиев, Ислам Әхмәтҗанов, Хәлим Гайнуллин, Касыйм Тәхау, Рәшит Гарипов, Дамир Шәрәфетдинев кебек күренекле журналистлар белән редакциядә алты ел янәшә утырып, бәхәсләшә-киңәшләшә иҗат эше башкарырга туры килде... Аннан соң да инде энциклопедиядә лаеклы урын алырлык күренекле редактор-журналистлар каләм чарлый-чарлый җитлекте. Алар белән инде каләмдәш буларак та, остаз буларак та аралашырга, бергә-бергә иҗат итәргә туры килде: Миңназыйм Сәфәрев, Илсөяр Хәйруллина, Габделбәр Ризванов, Люция Фаршатова...

Татар редакторлары турында уйланып, бу язмага тотынуымның өченче сәбәбе– ул шулай ук бер юбилей, ул да булса, татарның тагын бер атаклы мөхәррир-редакторы, иң төгәле, редакторларның "атасы" Рәис Нәүшербан улы Даутовның март аенда (2008 ел) тууына 80 ел тулуны билгеләп үттек. Нәшрият "казанын": китапны басарга әзерләү, текстны төзәтү, аны төрле экстралингвистика, полиграфия чаралары белән тулыландыру, бизәү, авторлар белән эш итү технологиясенең чын белгече, боларны нәзәри яктан төшендерүче, ярты мең китапны үз кулы белән эшкәртеп-төзәтеп бастырган, өстәвенә йөзләрчә кулъязманы төзәтергә авторларына булышкан, дистәләрчә редакторларны эшкә өйрәткән, бихисап авторны язарга, язганын төзәтергә күнектергән, чын мәгънәсендә энциклопедик белемле, эрудиция иясе, галим-мөгаллим иде. Без Татарстан китап нәшриятендә унбер ел бергә эшләдек. Аның редакторлык эшчәнлеге чын-чыннан олы бер мәктәп иде.

Редактор төшенчәсе, Рәис Даутов аңлавынча, бик гади дә, шул ук вакытта иң кирәкле, алыштыргысыз, катлаулы да бер вазыйфа. “Редактор ул китапның сәнгати эчтәлеге, техник эшләнеше, бизәлеше ягыннан мөмкин кадәр югары дәрәҗәдә сыйфатлы, культуралы итеп басылуын тәэмин итүче. Бу мәгънәдә редактор – чыннан да язучының, авторның беренче ярдәмчесе...”. Ягъни редактор, бер караганда, гадәти хезмәткәр кебек, баксаң, аннан башка, аның катнашыннан башка китап кадәр китаптан алып, газет та, газеттагы гап-гади мәкалә дә дөнья күрә алмый, укучысына барып җитә алмый икән. Юкка гына китапның азагындагы чыгарылыш мәгълүматында автор белән бергә аның “атасы-анасы”– редакторның да исем-фамилиясе куелмыйдыр. Газетта да баш редакторның, ә кайберләрендә бүлек редакторларының исем-фамилияләре куела-куелуын, тик язманың, әйткәнебезчә, автор белән бер дәрәҗәдә җаваплы, көч салган редакторы күрсәтелми; бу гаделсезлекне төзәтергә кирәк, дигән тәкъдим бер генә тапкыр әйтелмәде инде.

Рәис Даутов шулай ук тәҗрибәле, нәшрият эшенә күп көч куйган Наис Гамбаров белән интервьюсендә (“Эш турында “эшчән керпе” белән сөйләшү”, Казан утлары, 1998, №3,151–167 б.) редакторның җәмгыятькә кирәкле белгеч икәнен бик гади мисаллар белән төшендереп бирә: “... соңгы вакытларда төрле вак нәшриятләрдә редакторсыз, яисә тәҗрибәсез редактор кул астында чыккан китапларга, бигрәк тә дини басмаларга күз салсаң, сүзләр язылышында, җөмләләр төзелешендә, хәтта тыныш билгеләре куелышындагы бихисап хаталарны, чатаклыкларны күреп, чәчләр үрә тора!”. Шунда ук әйтелгән янә бер фикере бүген бик әһәмиятле: “Бу әле нәшрияттә шулай. Газет-журналлардагы киткән хаталар турында әйтеп тә тормыйм. Димәк, нәширнең эшен җайга салу, редакцияләү принципларын системалаштыру өчен фәнни үзәкне булдыру якындагы төп бурычларның берсе булып кала бирә” . (Шунда ук, 162 б.).

Рәис Даутов тарихка редакторлык эше принципларын, технологиясен фәнни һәм гамәли нигездә төшендереп бирүче, редакторлар тәрбияләү һәм өйрәтү мәктәбен озак еллар эшләтүче булуы өстенә үзенең мәшһүр остазларын, гомумән дә, татар мөхәррир-редакторларын, шулар рәтендә атаклы һәм гади автор-әдипләрне дә барлаучы, алар турында белешмәләр төзеп чыгаручы энциклопедик библиограф буларак та кереп калды. Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары турында биобиблиографик мәҗмуганы әзерләгәндә аның 300 дән күбрәк әгъзасының тәрҗемәи хәле, иҗат казанышлары турында ифрат бай мәгълүмат туплады . Гомеренең соңгы елларында Татар энциклопедиясе институтында эшләгәндә, “Татар энциклопедия сүзлеге”нең әдәби эшкәртү буенча баш мөхәррире буларак, тарихи әһәмиятле бу академик чыганакны шул хәзинәсе белән бик нык баетты.

Аннары, ул күренекле журналист һәм библиограф Исмәгыйль Рәмиевнең татарның нәшер эшчәнлеге, матбугат тарихыннан, редактор-мөхәррирләр дөньясыннан бай мәгълүмат җыеп төзегән, әмма озак еллар буе көтеп тә,

үзе исән чагында аны бастырып чыгара алмаган “Әдәби сүзлеген”, ниһаять, редакцияләп, үзенең дә гомер буе җыйган мәгълүмәтен өстәп, 2001 елда бастырып чыгаруга ирешә. Бу тупланма татар редакторлык эшчәнлеге турында бүген бик кирәкле энциклопедияне төзү өчен җитди, фәнни нигез ташларының берсе була алыр иде.

Язмабызның үзәк соравына да (башисемгә кара) тәмам якынайдык шикелле. Менә әле бәян ителгәннәрдән татар мөхәррир-редакторлары, аларның тәҗрибәсе турында моңарчыгы эзләнү, күзәтү нәтиҗәләренә таянып, аларның кайсы сыйфатларын яшь редакторларны тәрбияләү, укыту өчен тәкъдим итү зарур? Әлбәттә, бу төп сыйфатларның һәркайсы – үзенә аерым зур тема, киләчәк эше. Бүгенгә тезислап кына барлап китик:

– татар редакторы буыннан-буынга милләт баласы, халык хезмәтчесе, аның белән бер сулышта, бер язмышта яшәүче булды. Халыкка кыен – аңа да рәхәт түгел; милләт алгарышта – ул да яңача фикерли, хөр атлый; киресенчә, илдә демократия кысыла башладымы, иң әүвәл китапка, газетка – киртә, богау; редакторның авызы томалана, кулы бәйләнә; эштән шул куыла. Аеруча милли, дини матбугат беренче чиратта эзәрлекләнә. Инкыйлабый борылышлар, репрессияләр кәсәфәтендә, сугышларда кырылган татар редакторының саны әле барлап та бетерелмәгән. Әле телгә алган бер “Кызыл таң”ның гына да өч баш редакторы – утыз җиденче ел корбаны. “Ватаным...”ныкылар да дистәгә тула. Аның беренче баш редакторы (“Эш” газетын оештыручы, аңарчы Мулланур Вахитов белән бергә “Кызыл байрак” газетын чыгарган, “Татарстан хәбәрләре”нең дә баш редакторы булган, егерме бишенче елларда Нәшрият комбинатын оештырып җибәргән) Вәли Шәфигуллинның – чорының иң көчле сәясәтчесе, журналисты, үзе үк текст төзәтүче, үзе үк текст өстендә эшләүчеләрнең җитәкчесе – менә шушындый зат та авторитар режимның корбаны.

Бөек Ватан сугышы кырларыннан күпме редактор кайтмаган: шагыйрь-редактор Муса Җәлил, нәшрият редакторлары-шагыйрьләр Фатыйх Кәрим, Нур Баян, Гадел Кутуй... Бер язмада исемнәрен санап та бетереп булмаслык корбаннар. Аларның күпчелеге бит әле редакторлык эшен фронт шартларында, алгы сызыкта да дәвам иттергән – татар фронт газетларының фидәкарьлеге турында әле бик тә аз телгә алына, аларны әле өйрәнергә дә өйрәнергә...;

– халык баласы булуы, язмышын милләте белән аерылгысыз бәйләве татар редакторының яңа сыйфатларын барлыкка китергән. Аерым алганда, безнең мөхәррир-редакторлар ул халык җанлы, аның мәнфәгатен үзенекеннән өстен күреп, өстен куеп яшәүче. Безнең аңда “автор белән эшләү” дигән, бер караганда үтә рәсми, асылында исә чын мәгънәсендә халыкчанлыкны, редактор эшенең эчке хәсиятен ачык чагылдырган төшенчә яши. Һәр редакциядә автор, аның хаты изге санала.

Хәтерлим, Никита Хрущев җитәкчелек иткән заманда бервакыт халыкның җитәкчелеккә мөрәҗәгатьләрен санга сукмау, битарафлык көчәеп китте, хәтта "аноним хатларны – кәрзингә!" дигән күрсәтмә бирүгә кадәр барып җиттеләр. Бу хәл кайбер төбәкләрдә, мәсәлән, Урта Азия республикаларында, бәгъзе редакцияләрдә укучы хатларына карата карашны үзгәртүгә китерде. Кәсәфәте дә озак көттермәде – укучылар ваз кичеп, кайбер газетлар ябылуга дучар булды.

Шөкер, татар матбугаты мондый казага тарымады. Бүген дә күпчелек газетның "төп азыгы" – ул хатлар. Атнага бер махсус хатлар бите туплап чыгару һәр газетның диярлек гадәтенә кергән. Ә бит һәр сәхифә – ул аны оештыручы журналист-редакторның көче-хезмәте нәтиҗәсе, иҗат җимеше. Шул оештыручыларның исемнәрен ара-тирә булса да күрсәтеп, фотоларын урнаштырып, кайбер басмалар бик дөрес эшли.

Ә хатка, анда белдерелгән фикер-тәкъдимнәргә игътибар, аның авторын санга сугу дигән сүз. Хат йөзендә тере адәм баласы тора – бу татар редакторының канында. Безгә ул Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Галимҗан Ибраһимовлардан күчә килгән. Йөзләрчә халыкчан мөхәррирләребездән нигә нәкъ менә шушыларны әйттем әле дисәк, үзе дә күренекле редактор булган Зариф Бәширинең бу остазлары турындагы хәтирәләрен күз алдына китердем. Аның күп санлы күзәтүләреннән бер генә фактны тәкърарлап китим: "Бер көнне без, Хәбиб Исхакый белән "Әльислах" газетына бардык... Бераздан Вафа Бәхтиярев, аннан соң Габдулла Тукай килеп керделәр...". Исәнләшү, хәл белешүләр. Иҗат турында гәп китә. Хәбиб Тукайга бер шигырен бирә дә: "вакытыгыз булса, менә шуны укып, җитешсез җирләрен күрсәтсәгез, яхшы булыр иде, Габдулла әфәнде", диде.

"Тукай мондый нәрсәләрне беркайчан да өстен генә карап үткәрми. Ул аны бөтен игътибарын салып, кабат-кабат укып чыга, аңлашылмаганрак җирләрен авторның үзеннән кайта-кайта сорый, мактарлык җирен мактап, җитешсез җирләрен күрсәтеп, ничек кирәклеген төшендереп бирә. Бара-тора ул Хәбиб Исхакыйга да шактый зур әһәмият биреп, аның әсәрләренә каты гына тәнкыйтьләр ясый башлады. Шул ук вакытта ул яшь шагыйрьгә материаль ярдәм итү юлларын да табарга тырыша иде. Татар телендә чыга торган газет-журналларда бик сирәк кешеләргә генә гонорар бирелә, күтәрелеп кенә килә торган яшь язучылар гонорар алу дигән нәрсәне уйлап та карамыйлар иде..." ("Замандашларым белән очрашу", Казан, 1968, 210 бит. Сүз уңаеннан: бу китап та Рәис Даутов редакторлыгында чыккан).

Күпчелек редакторларымның кешелек сыйфатларын автор буларак та, редакция хезмәткәре буларак та шәхсән үзем дә шактый тойдым. "Кызыл таң" газетының атаклы редакторы Таһир Исмәгыйль улы Ахунҗановның ул сыйфатлары турында хезмәттәшләренең сөйләгәнен еш ишетергә туры килә. Дәлилләр үземдә дә җитәрлек: яшәү шартларын кайгыртуы дисеңме; хезмәткәргә эшне сәләтенә карап куша белүе дисеңме (иң катгый штат расписаниесен үзгәрттереп булса да, ул "редакторның махсус хәбәрчесе"

диган урын “табуга” ирешеп, редакциядә очерк бүлеге булдырды – җитәкчесе итеп мине билгеләде); иҗади хезмәтне гадел бәяләргә тырышуы дисеңме (бервакыт иҗат казанышы саналырлык бер язмамны летучкада хуплаганнар иде, ә гонорарны секретарь абзый гадәттәгечә “тигезләп” куйганга игътибар итеп, язылган сумманы кызыл калын карандашы белән сызып, шактый зур суммага үзгәртеп язганы хәтердә калган).

“Ватаным Татарстан” газетының баш редакторы Шәмси Хәбибулла улы Хамматовның кешелеклелек, олы җанлылык сыйфаты турында газетның 80 еллыгын билгеләп үткәндә “Олы булсаң, кече була бел” дигән язма да бастырган идем ( В.Т., 1998, 11 март). Республиканың бүген дә күренекле җәмәгать эшлеклеләре – редакторлар, галимнәр, оешма җитәкчеләре, журналистлар – күпчелеге “Ватаным...”да эшләгән, Шәмси абый Хамматов кайгыртуы аркасында үсеп киткән шәхесләрнең барысы да аның кешенең киләчәген уйлый белүен, беренче чиратта, аның белемен даими үстерү өчен кайгырту сәләтен билгеләмичә калмый. Аның шәкертләренең күпчелеге Мәскәү, Ленинград югары уку йортларында, Академияләрдә өстәмә белем алды; ул аларны илкүләм югары уку курсларында системалы укыту гадәтен кертте.

Шулай бер елны, гади хезмәткәр булсам да, ул мине дә Куйбышевта эшләп килгән югары курсларга чираттагы укуга җибәрде. Шунда укып ятканда бервакыт курслар җитәкчесе һәм минем исемгә телеграмма килеп төшмәсенме: мине партия өлкә комитетында редакциянең бүлек мөдире итеп раслаганнар икән. Әлбәттә, бу вакыйга белән редактор мине кайткач та котлый алган булыр иде, юк, бит, үз хезмәткәрен бүтән өлкә-республика журналистлары алдында да күрсәтеп, күтәреп җибәрү мөмкинлегеннән файдаланган. Телеграмманы барлык курсантлар алдында укып, котладылар. Иҗат кешесен үсендереп, илһамландырып җибәрергә күп кирәк мени! Моны тойган, белгән җитәкче чыннан да олы җанлы, кешелекле инде ул!

– татар редакторының янә бер әһәмиятле сыйфаты – ул үз эшенә мөкиббән китеп, халык, милләт алдында җаваплылык тоеп, тирәнтен белеп, яратып, ихластан башкаруы. Бу, иң әүвәл, халыкта, татар телендә “мөхәррир”, “редактор” сүзләренең уңай эчтәлекле булуы белән дә дәлилләнә бугай. Гәрчә аларда мәгънә төсмерләре берникадәр аерылса да. Мөхәррир – ул халык яшәешен кайгыртып, аны үзгәртүгә-яхшыртуга юнәлдерелгән үз фикере-идеясе булган, шуны тормышка ашырырга омтылып, иҗтимагый-сәяси эшчәнлек башкарган, шул идеясен үзе язып, редакцияләп, үзе үк җәмгыятькә җиткерү чараларын күргән абруйлы шәхес. Менә кем ул халык аңында мөхәррир! Ризаэтдин Фәхретдинне, Фатыйх Әмирханны, Фатыйх Кәримине, Галимҗан Ибраһимовны, Гаяз Исхакыйны мин бернинди икеләнүсез “Мөхәррир” дип атыйм. Бу төшенчәне Габдулла Тукай, Гомәр Бәширев, Хәсән Сарьян шулай аңлаганнар һәм шулай язганнар да. Габдулла Тукайның Гаяз Исхакыйга багышлап язган

“Мөхәрриргә” дигән шигыре бу төшенчәнең бөтен асыл сыйфатларын ачып бирә дә.

Күренә ки, бүгенге “редактор” төшенчәсе “мөхәррир”гә нәкъ тәңгәл килми, аерма бар – аларны бер мәгънәле дип санау дөрес түгел; һәркайсын үз урынында кулланырга кирәк. Бүгенге редакторлар арасында да мөхәррирләр бар, тик вазыйфа башкаручы һәр редакторны мөхәррир дип атап булмый, аны халык кына билгели ала.

Ничек кенә булмасын, иң әһәмиятлесе, ике төшенчәнең дә уртак үзәге – ул бу шәхесләрнең халык җанлы, милләтпәрвәр булулары, иң белемле-грамоталы-эрудицияле дип танылуларында. Укытучы-мөгаллимнәрне “Сез иң галим кеше икәнсез!” дип күтәргән шагыйрьгә охшатып, горурланып, мин дә редакторларны “Сез иң белемле, иң галим кеше икәнсез!” дим.

Редакторлар да – төрле иҗтимагый-сәяси шартларда, төрле мохиттә, киң колачлы эш алып барырга сәләтле, талантлы сәнгати иҗат кешеләре. Тарихи шәхесләрдән мисалларны күп китердек. Бүген дә үзе язучы-шагыйрь, үзе үк текст язуны-төзәтүне-басуны оештыручы, үзе үк шул эшләрне башкаручы да белгечләребез аз түгел. Бу бит чын мәгънәсендә табигый талант, күп акыл көче һәм физик гайрәт сорый торган эшчәнлек. Өстәвенә әле заман таләпләре дә үзгәрә-өстәлә тора: безнең күпчелек редакторларыбыз матбугат белгечләре генә түгел, нәшриаттә, радио-телевидениедә, шулар белән бәйле фәнни, җәмәгать, җитәкче оешмаларда эшләргә сәләтле.

Халыкның игътибары һәм ихтирамы редакторга аның авыр, җаваплы хезмәтендә илһам, көч бирә (Милли матбугат: хәзергесе һәм киләчәге. “Ватаным татарстан” газетасының 90 еллыгы уңаеннан оештырылган фәнни-гамәли конференциядәясалган чыгышлар. – Казан: Идел-Пресс, 2008.–62–88 б.).

Мондый озын керештән соң, теманың асылына күчик.

**Редактор укуы**

Редактор укуы – профессиональ төшенчә. Бу инде гадәти укучының үзен рухи канәгатьләндерү өчен укыла торган көнкүреш шөгыле түгел, бу – кирәк булганга, хезмәт бурычы үтәү өчен уку. Бурыч – иҗтимагый кирәкле продукция чыгару. Редактор, гадәти укучы кебек, әсәрне аңлау һәм эчтәлеген үзләштерү белән генә чикләнә алмый. Бәлки аны бөтен яклап, төрле аспектта таркатып, профессиональ җентекле анализ үткәреп бәяләргә тиеш.

Уку өч тапкыр кабатлана: танышу өчен уку; җентекләп (таркатып), тирәнтен уку; эшкәртә-эшкәртә җыеп уку;

Әлбәттә, уку саны текстны күргәнче үк аның эчтәлеген белү дәрәҗәсенә бәйле. Әгәр редактор әсәрнең идеясен дә үзе табып, авторын да тәгаенләп, материалны үзе оештырган икән, бу очракта танышыр өчен укуның ихтыяҗы, әлбәттә, юктыр.

Укуның һәр баскычы редакторның яңача психологик хәләтен таләп итә. Әйтик, җентекле уку барышында редактор текстны ни дәрәҗәдә аңлавын үз-үзенә ачыклау өчен укыган өлешен сөйләп карарга тәкъдим ителә (Мильчин, 60–62 б.).

**Җентекләп, таркатып уку** инде әсәрне анализлап бәя бирүне һәм алда торган әдәби эшкәртү процессын күз алдына китерүне максат итеп куя.

Беренче тапкыр укыганда текст, гадәттә, төзәтелми, әсәргә тулаем бәя бирү өчен кирәкле, күзгә ташланып торган сыйфат, билгеләргә генә тамга куеп барыла, типик хаталарга, аңлашылмый торган, икеле-микеле мәгънәле урыннарга диккать ителә. Хатаның төп төрләренә карап (мантыйкый, фактик, композицион, тел, иллюстрация һ.б.) төрле төстәге каләм-карандаш белән билгеләп бару уңайлы.

Икенче кат укыганда инде тирәнрәк күзәтү ясала – фикер агышына (мантыйкый кимчелекләргә), әсәр төзелешенең эчтәлек белән бәйләнеш нисбәтенә караган урыннарга аерым диккать ителә. Шул ук вакытта әдәби эшкәртү башлана (сүзләрне мәгънәсенә карап алыштыру һ.б.) баш исеме турында, композициянең бүлекләренең нисбәте, аларның баш исемнәре, кереш, төп өлеш, йомгакның эчтәлек һәм форма бердәйлеге һ.б. Башлыча икенче тапкыр уку – әсәрне тәмам таркатып бетерү максатын күздә тота.

Өченче тапкыр уку  ул әсәрне җыю, тулаем күзаллау өчен башкарыла.

Болардан тыш сайлап алып уку була. Аеруча катлаулы урыннар (таблица, сводка, формулалар, төрле шрифт белән җыела торган нәзәри нигезләмә, фәнни билгеләмә, искәрмәләр һ.б.) кире кайтып, яисә ике кеше катнашында чагыштырып-кычкырып укыла.

Анализ өчен укыганда редактор текст кырыена (поля) яисә аерым кәгазь битенә искәрмәләр теркәп бара. Озын әсәрдә ул бит саен яисә бүлекчә, параграф, пункт саен аерым кәгазьгә теркәлә. Редакторның бу билгеләмә-искәрмәләре – аның йөзе, эш алымы чагылышы. Аларда аның һөнәри кыйбласы, кешелек сыйфатлары да, белеме, тәҗрибәсе дә чагыла. Вак-төяккә бәйләнмәскә, ә төп теманың ачылышы, проблеманың чишелеш, аны хәл итү юлларын ачыклый бара. Шулардан редактор өчен дә, автор өчен дә эш планы төзелә.

Барлык искәрмә, замечаниеләрнең дә ачык, төгәл булуы зарур. Сорау рәвешендә калмаска тиеш. Автордан нәрсә таләп итүең үзеңә томанлы булмаска тиеш. Кимчелекне күрсәтеп, таләп итеп кенә канәгатьләнү җитми, сәбәбен төшендереп, ничек төзәтү юлларын да тәкъдим итү зарур.

Авторның шәхси үзенчәлекләрен ачыклау мөһим. Әйтик, тәҗрибәле язучы яисә журналист текстын анализлау белән белгеч агроном яисә яшь инженер текстын анализлау, аларга кимчелекләрен төшендерү. әлбәттә, бер үк түгел.

Монда авторлык хокукларын саклау, авторны кайгырту, бигрәк тә яшъ авторларга игътибарлы, кайгыртучан булу аеруча әһәмиятле.

Редактор укуы барышында максатчан рәвештә редактор анализына  да керешелә.

**Редактор анализы**

Редактор анализы – ул, тулаем алганда, кульъязманың чынбарлыктагы эчтәлеге белән бу әсәрнең иҗтимагый кирәкле эчтәлеген чагыштыру, ягъни алдан күрү, фаразлау процессы.

Анализга керешер алдыннан текстны анализлауның һәм төзәтү (дөресләүнең) кайбер психологик үзенчәлекләрен искә төшереп китү урынлыдыр. Текстны аңларга һәм аңа бәя бирергә үзең теләп керешү зарур. Моның өчен теманы алдан хәстәрләү, ошаганын сайлап алу мөмкинлеген эзләргә кирәк, авторның хезмәтенә, үзеңнең эшеңә аңлы рәвештә карау кирәк. Сөйләм процессы буларак барлыкка килгән текстның объектив дөреслегенә ирешү өчен иң беренче шарт – контроль. Аны автор тормышка ашырырга тиеш. Автор текстын беренче укучы буларак, редактор аңарга менә шул контрольне гамәлгә ашырырга булыша.

Редактор психологиясе бер яктан авторныкы белән, икенче яктан укучыныкы белән бәйләнгән. Автор өчен ул кульъязманы барысыннан да җентекләбрәк, уяурак укучы кеше, ә укучыга ул аның мәнфәгатен яклаучы кеше. Гомерләрен әдәби редакцияләү эшенә биргән берничә белгечнең фикеренә колак салыйк әле: “Мәкаләне редакцияләгәндә редактор һәрвакыт үзен укучы урынында дип сизәргә тиеш” (А.В.Луначарский); “Редактор ул берникадәр язучыны да өйрәтә, тәрбияли” (М.Горький); “Редактор ул һәрвакыт үзе язарга әзер кеше “ (В.И.Ленин).

Күренә ки, редакторның психологик урыны катлаулы, ул автордаш–иҗатташ дигән үзгә бер төшенчә белән бәйле. Бу – өч кешенең психологик хәлэтенең суммасы дип түгел, бәлки катлаулы бер бөтен күренеш итеп күзаллана.

Текстны төзәтү – объектив ихтыяҗ булырга тиеш. Ул, һичшиксез, аны яхшыртуга хезмәт итә. Төзәтү – мәҗбүри куелган эш түгел. Беренчедән, текст әзерләнгәнче үк иҗат процессында катнашып, редактор җитди төзәтүләрдән котыла, икенчедән, авторга, аның иҗат алымнарына сак булып, үзенең субъектив зәвыгыннан котылып, артыгын бәйләнми. Кызганычка каршы, кирәккә дә, кирәкмәгәнгә дә текст эченә керү, аны төзәтү, дөресе, җимерү, вату белән мәшгульлек әле күп редакторга, аеруча яшьләргә хас. Заманында “Журналист” журналында әсәрләре кителгән, кыскартылып зәгыйфьләнгән авторларның зар-шикаятьләре еш басыла иде (Журналист, 1974, №3 һ.б.).

Күренә ки, **автор белән редактор мөнәсәбәте** һәрвакыт катлаулы, аңа җавапсыз, җиңел карарга ярамый. Авторны, аның иҗат алымнарын, үзенчәлеген аңларга тырышып, редактор үзен аның урынына куеп карый, шул ук вакытта ул үзенең редактор икәнен, бу процесста мөстәкыйль иҗатчы икәнен беркайчан да онытырга тиеш түгел.

Бәя бирү өчен өйрәнгәндә редактор текстны физик өлешләргә һәм элементларга да, мантыйкый һәм сөйләм берәмлеге өлешләренә дә тарката-тарката анализлый.

Бу төшенчә белән бәйле янә берничә термин: анализ предметы, механизмы, структурасы.

Әйтик, **анализның предметы** – ул кульязма басып чыгарырга яраклымы-түгелме дип бәя бирү. Бәя күп яссылыкны колачларга тиеш. Төп критерий табар өчен редактор бәясенең предметын ачыкларга кирәк. Ул: әсәрнең иҗтимагый кирәклеге (яраклылыгы) белән аның хәзерге, реаль хәленең тәңгәл килүе, ягъни әсәр үзенең хәзерге эчтәлеге һәм формасы белән тиешле иҗтимагый яраклылык таләпләренә туры килергә тиеш.

**Анализның механизмы,** дигәндә текстны төрле элементларга таркатып тикшерү. Әйе, ул аны бүлгәләп анализлый. Шул ук вакытта бүлгәләү, таркату үзмаксат та түгел, ул аны "ремонтлаганнан соң" кабат камил итеп, төзәтеп ялгау өчен эшли. Бу таркату да синтезлау процесы, чөнки редактор таркалган өлешне инде таркатылганнарыннан аерып карамый, киресенчә, барысын берләштереп, бербөтен итү максатын күздә тота. Текст өстендә эшләү, икенче төрле әйткәндә, мәгълүм бер корылма-конструкцияне сүтеп, аның аерым кисәк-өлешләрен үзгәртеп-яңартыпмы, әллә конструкциянең үзен үк үзгәртеп-яңартыпмы, кабат җыюдан гыйбарәт.

Нәрсә ул текст? соравына алда җентеклерәк тукталырбыз. Аны аңлау өчен төп тезисларны гына хәтерләп калыйк: текст – катлаулы күренеш: текст – ул фиксацияләнгән, беркетелгән сөйләм (сүз, сүзтезмә, җөмлә, фраза, контекст); текст – ул беркетелгән, басылган фикер (төшенчә, тезис, дәлил, нәтиҗә, ягъни мантыйк берәмлекләре); текст – ул композиция, сюжет төрендәге корылышлы әдәби берәмлек, жанр төре; текст – ул эчтәлекне рубрикалап, бүлемләп бәян итү (бүлек, бүлекчә, параграф, пункт, кызыл юллар һ.б.).

Бу дүрт төрле берәмлек кушылып та китә. Төшенү һәм төзәтү сүздән фразага таба бара. Фраза әле бөтен әсәр түгел. Фразадан гына бөтен әсәрне бәяләп булмый. Ярамый да. Тик гамәлдә кайвакыт әсәрне, аеруча тәрҗемә әсәрен, аерым өзекләренә карап кына бәяләүгә юлыгабыз.

Текст бер бөтен дип күзалланырга тиеш. Шул ук вакытта ул чагыштырмача мөстәкыйль өлешләрдән тора. Әйтик, Галимҗан Ибраһимовның 8 томлык Сайланма әсәрләре. Сигез томны берләштергән күптомлык — аерым бер том — шул том (китапта) бер роман (пьеса, хикәя һ.б.) — әсәрнең бер кисәге — кисәкнең бер бүлеге — бүлекчәсе — параграфы — пункты (статьясы) — бер микротексты (кызыл юлы, фразасы) — бер җөмләсе — бер сүзтезмәсе — бер сүзе — иҗеге — хәрефе (авазы). Һәркайсы үзенә мөстәкыйль бөтеннәр һәм шул ук вакытта үзләреннән эрерәк бөтеннең бер өлешен хасил итәләр.

Текст төрле яклап, аспектта анализлана. Төрле фән, иҗтимагый кыйбла кагыйдәләре критерийлары белән анализлана. Күренә ки, нәтиҗә, бәянең төрле, хәтта бәхәсле-каршылыклы эчтәлектә дә чыгарылуы ихтимал икән. Әйтик, текстта сүзләр, җөмләләр мәгънә ягыннан да, җөмләдәге урыны белән дә норма-кагыйдәләргә туры килә, дөрес, ә менә мантыйкый яктан каршылыклы, кабатлаулы яисә бүтән төрле кимчелекле булып кала. Шуңа

күрә дә төрле яклы (аспектлы) анализ таләп ителә. Гадәттә эчтәлек анализы, форма анализы, теле һәм стиле анализы була.

Эчтәлек анализында факторлар системасы һәм идеяләр системасы аерып анализлана, ә әсәрнең төзелеше (формасы, композициясе) материалны оештыру системасы һәм материалны укучыга җиткерү чаралары системасын анализлау белән аерыла, ә тел, стиль чараларын анализлаганда аерым-аерым лексик чараларга һәм синтаксик чараларга игътибар ителә.

**Эчтәлекне анализлаганда** игътибар ителергә тиешле моментлар: әсәрнең иҗтимагый максатын, кемгә адреслануын ачык күзалларга; темага бәя бирү (актуальме, иҗтимагый әһәмияте ни дәрәҗәдә, колачлымы; мәсәлән, бер язмада ашламадан агуланып үлгән бер кошны тасвирлаганнан соң, нәтиҗә ашламаның зарары турында гына ясала, экология мәсьәләләре табигатьнең матурлыгына гына кайтарып калдырыла); теманың тулы ачылуына бәя бирү, идея эчтәлеген ачыклап бетерү, фактик материалны бәяләү. Принципларның үтәлүенә бәя бирү.

Теманың хәл ителүе, ачылышына бәя биргәндә: мәгълүмат тулы бирелгәнме, җитәрлекме, үтемле бәян ителгәнме? Моны тәмам ачыклар өчен редакторга булган белеменә өстәп, шушы темага кагылган махсус фәнни мәгълүмат алырга, консультантларга мөрәҗәгать итәргә, махсус әдәбият укырга кирәк була.

Идея эчтәлегенә, фактик эчтәлеккә аерым игътибар бирелә. Әйтик, факт белән эш итү зур осталык, тәҗрибә сорый. Фактларның тулы, төгәл, дөрес , яңа булуы, бер-берсенә һәм башка детальләр белән аерылгысыз бәйле булуы зарур. Фактның кайдан алынуына, авторның аны кайсы чыганакларга таянып раславы бик мөһим. Чын оригиналларга таяну мәҗбүри (“Татар энциклопедиясе” һ.б.). Тәрҗемә әсәрләренә, шикле басмаларга, икенчел чыганакларга, имеш-мимешкә сизгерлек күрсәтү.

Идея эчтәлегенә бәя бирүнең кыенлыгы хәзерге шартларда янә дә раслана. Иң инанылган идеология чыганаклары да шик астында. Мондый шартларда редакцияләү принципларына таяну (инану, фәнни дөреслек, халыкчанлык, чын тормыш белән бәйләнеш һ.б.) бердәнбер чара булып кала.

**Формасын анализлаганда** игътибар ителергә тиешле төп моментлар: композиция өлешләренең ачыклыгына, тулылыгына, төгәллегенә бәя бирү, рубрикалау кимчелекләре юкмы икәнен ачыклау. Текстның бөтенлегендә хилафлык юкмы, барлык өлешләр дә бәйләнеп барамы? Иншалау төрләре нисбәте ни хәлдә: хәбәр итү, мөрәҗәгать итү, хикәяләү, үгетләү, ышандыру чаралары нисбәте саклanaмы. Тасвир чаралары тәэсирлеме.

Ике төп юнәлеш белән анализлана: композиция (сюжет) + тел, стиль чаралары. Композиция – ул бер-берсенә аерылгысыз бәйләнеп барылган тематик фикер фрагментлары, кисәкләре. Алар төрле юллар белән: а) рубрикалау, ә) эчтәлектән аңлашылган бүлемләү юлы белән теркәлә. Рубрикалау төгәл схема белән бара: кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф, пунк,

матдә. Алар йә башисем белән, йә нумерлап тәгаен ителә. Һәр очракта редактор фикер кисәкләренең бер-берсенә бәйләнешен, нисбәтен, бөтенлеген истә тотарга, “үлчәп барырга” тиеш.

Текст төзелеше янә аның нинди ысул белән бәян ителүенә – хәбәр ителепме, хикәяләпме, тасвирлапмы бәян ителүенә дә бәйле. Хәбәр итү тоны үгет-нәсихәт, бәхәс яисә күрсәтмә бирү тонынннан аерыла бит. Әйтмә сөйләм белән язма сөйләм үзенчәлекләрен, жанр аермаларын тоемлау бу кыенлыкларны җиңәргә булышыр. Әлегә еш кына жанр үзенчәлекләрен тоемлап бетермәү очракларына юлыгып торабыз. Нигәдер тәнкыйди материалда тасвирлау чараларының нисбәте бозылу яисә интервьюда язма элементларның өстенлек итүе кимчелек дип кабул ителми.

**Тәэсир чараларына анализ.** Тел һәм стиль чаралары белән тәэсир итү. Эчтәлек, темага, иншалау рәвешенә тәңгәл тасвир чаралары сайланамы. Фонетик, морфологик, лексик, синтаксик чаралар. Тел нормасына һәм сөйләм нормасына җавап бирү. Сөйләмгә мотивларга бәрәбәр тел чаралары сайлап алыну мәсьәләсе. Сүзнең, тезмәнең мәгънәви урыны һәм синтаксик урыны. Орфография, орфопия кагыйдәләрен үтәүне бәяләү.

Укуы барышында редактор текст эчтәлеген дә тирәнтен анализлый бара. Бу – әсәргә бәя бирүнең, аны кимчелекләрдән арындыруның нигезе. Бөтен әйтелгәнгә шикләнеп карап, барлык нәтиҗәләрне тәнкыйди күзаллап, редактор шуның нәтиҗәсендә әсәргә бәя бирергә тиеш. Шуңа күрә дә ул әсәрдә сүз барган әйбер-предмет, күренеш, вакыйганы төпле белергә, аларның әсәрдәге, ул җиткерергә тиешле максаттагы урынын, асылын, нечкәлекләрен ачык күзалларга, тарихын-бүгенгесеннән яхшы мәгълүматлы булырга тиеш.

Тәнкыйтьчел анализ редактор эшен иҗади, сәнгати итә дә инде – һәр әсәргә ул мөстәкыйль дип, аерым-аерым карый (бер күч итеп түгел), аны шаблон-калыпка салмый, кәсепчелек алымнары белән эш итми.

Шушындый анализ нәтиҗәләренә нигезләнеп, редактор ике җитди документ – автор белән эшләү планын һәм редактор бәяләмәсен әзерли.

Редактор бәяләмәсе (редакторский отзыв) – халыкара авторлык хокукы даирәсенә караган (түгәрәк эченә алынган “С” – с (copyright сүзенең – инглизчәдән “воспроизводить право”) беренче хәрефеннән алынган, шуңа аны копирайт дип тә йөртәләр), аның актларына таянган рәсми документ. Аны төзү, тутыру, гамәлгә кую тәртибе Халыкара авторлык хокукы оешмасының рәсми документы белән расланган. Дүрт өлештән тора: 1) эчтәлеккә бәя, 2) структурасы-төзелешенә бәя, 3) тәэсир чараларына – тел, стиленә бәя, 4) нәтиҗәдә (йомгакта) өч вариантның бары берсе ясала: 1) нәшрияткә (басмага, тапшыруга) кабул итәргә, 2) шундый-шундый кимчелекләре аркасында (кимчелекләр аерым-аерым санап чыгыла) кабул ителми, 3) шундый-шундый кимчелекләре (берәм-берәм санап чыгыла) бетерелгәч, басмага кабул итәргә;

Редактор, асылда, тәнкыйтьче ул; тәнкыйтьче генә дә түгел, ул кулъязманың киләчәк язмышын ахырынача хәл итүне үз өстенә алган нәшир дә. Тәнкыйтьче ул басылып чыккан китапка бәя бирә, ә редактор начар кулъязмага юл яба. Тәнкыйтьче авторның иҗади процессына кысыла алмый, ә редактор бу хезмәтнең автордашы буларак эш итә.

**Редакцияләүнең югары сыйфатына һәм нәтиҗәлелегенә ирешүнең төп шартлары:**

– текст эчтәлегенең редактор өчен тормышчан мәгънәсе, кирәклеге, әһәмияте булырга тиеш;

– текст өстендә эшләгәндә фикерләү, акыл процессының актив булуы, редакцияләү алымнарын, тәҗрибәдә иҗади үзләштергән булуы, шуларны куллана алуы зарур;

– текстны тәнкыйди анализлау өчен махсус күнегү чараларының күп, төрле-төрле булуы кирәк;

– булачак укучысын яхшы белүе, аның белән бәхәскә әзер торуы;

– авторның шәхси сыйфатларын, мөмкинлекләрен белү, аларның үзеңнең психологик ягың белеп чагыштырып карау осталыгы, шәхси карашыңның җиңә алу-алмау куәсе;

– редакцияләгән тема йә ситуацияне яхшы белүе, аның перспективасын чамалавы, бу темага кагылган әдәбиятне, чыганакларын, белгечләрен яхшы белүе;

– редактор үз эшчәнлегенең иҗтимагый эшчәнлек икәнлеген аңлап, аның мотивларын тоеп эш итәргә тиеш. Әгәр редакцияләү вазыйфа, көндәлек эш (һөнәр) бурычы гына икән, редактор эшчәнлегенең мәгънәсе, димәк, нәтиҗәсе бер төрле була, әгәр ул бөтен гомерен, бөтен яшәү максатын шуңа бирә икән, әгәр шушы әсәрне укырга тиешле кешенең хәленә кереп, китап, йә матбугат әсәре аңарга ни дәрәҗәдә кирәк икәнен җаны-тәне белән аңлап, шул дәрәҗәгә җиткерү өчен тырыша икән – бу эшнең мәгънәсе дә, нәтиҗәсе дә икенчерәк була. Тормышчан мотивларга нигезләнгәндә генә редакцияләү процессы иҗатка әверелә. Моңа берничә шарт булганда ирешелә:

– редактор эшен иҗтимагый хезмәт дип санаганда, инану принцибына таянып эшләгәндә; Бу шарт редакторның акыл эшчәнлегенең актив булуын, анализ күнекмәләренең көндәлек шөгыльгә әйләнүен кирәк дип белә. Редактор текст өстендә бирелеп, актив эшләргә тиеш;

– акыл эшчәнлеге булмыйча торып, редактор уңышка ирешә алмый;

– тормышчан, кызыксындырган материал өстендә эшләгәндә генә редактор актив акыл процессы күрсәтә ала. Менә ни өчен без редактор үзе дә темаларны авторларга тәкъдим итәргә, авторны үзе эзләргә, табарга тиеш дип саныйбыз, тематик җыентыкларның төзүчесе булуын хуплыйбыз. Максаты итеп әзерләнгән текст кына аның иҗади активлыгын көчәйтә ала;

– укучыны, авторларны һәм үзеңне яхшы белү, үзаңыңны тәрбияләү, камилләштерүдә даими эшләү сорала.

Гомумиләштереп әйткәндә, бу таләпләрнең үтәлү максаты бер ноктага төенләнә: **текстта хата җибәрелмәскә тиеш**. Хата теләсә кайсы китапның, газетның, радио, телевидение тапшыруының сыйфатын, тәэсир көчен төшерә, кулланучыда ризасызлык тудыра. Кәефе кырылган укучы иң беренче чиратта моңа җаваплы кешене эзли. Ә ул кеше иң әвәле – редактор.

Чыннан да, редактор – ул дәүләткүләм җаваплы шәхес. Аның җаваплылыгына тәфсилләбрәк тукталыйк. Редактор нәрсәгә җавап бирә?

– газет-журнал, китапны чыгаруны фәнни нигездә, дөрес планлаштыру өчен, ягъни тема табу, авторын билгеләп, аны табу һәм кирәкле басманы әзерләргә социаль заказ бирү. Димәк, редактор әдәби хезмәткәр, текст төзәтүче генә түгел, ә оештыручы, белгеч һәм сәяси-иҗтимагый эшлекле дә;

– кулъязманың китап булып чыгарга яраклымы-юкмы икәнлеген хәл итә; халыкка, дәүләткә зыян китерерлек әсәрләрнең чыгуына юл куймый; укучыга кирәк булмаган урта кул әсәрләрнең чыгуын тоткарлый, нәшрияткә кабул ителгән кулъязмаларны җентекле анализлап, аларны фәнни нигезле, дәлилле, гадел тәнкыйтькә ала; димәк, авторга әсәрен төрле яклап яхшыртырга булыша;

– кулъязманың китап булып җитешү процессында турыдан-туры катнашып, авторга булыша, бу эштә катнашкан башка барлык кешеләрне туплый, килештерә, китапның бөтен фәнни һәм ярдәмче аппаратын оештыра, җиренә җиткерә;

– редактор догматизм, хәрефкә ябышып яту, цитатчылык кебек чирләр белән аяусыз көрәшә;

– идея хезмәтчесе буларак редактор җәмгыятькә каршы идеологияләр белән (көчләү, сугыш, экстремизм, расачылык, милли-дини котыртулар һ.б.), дошманлыклар белән, искелек, катып калганлык, гомумкешелек сыйфатларына янау һ.б. бозыклыклар белән аяусыз көрәшергә тиеш;

– үзе редакцияли торган өлкәне (сәнәгать, фән, мәдәният, сәнгать, мәгариф һ.б.), белгечлекләрне төпле белергә, киң мәгълүмәтле, хәбәрдәр булырга тиеш;

– әлбәттә инде, газет һәм нәшрият эшен, радио, телевидение үзенчәлекләрен, аларның халыкка барып җитү юлларын, полиграфия техникасын, яңа технологияләрне, компьютер һәм интернет өлкәсен яхшы белергә тиеш. Шул очракта гына ул китап, газет басу эше мәсьәләләрен белеп, төпле хәл итә алачак, аларны халыкка җиткерү срокларын кыскарту, сыйфатын яхшырту һәм бәясен арзанайтуга өлеш кертә алачак.

## *Дүртенче тема:* Текст. Төрләренә карап төзәтү

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Текстның катлаулы күренеш, эш объекты булуы: текст – жанр төренә бәйле әдәби әсәр; текст – фикер белдергән төшенчә буларак мантыйкый (логик) берәмлек; текст – рубрика, кисәк, бүлекләрдән һ.б. өлешләрдән торган мөстәкыйль композицион төзелмә; текст – төшенчәне белдерүче тел берәмлекләреннән (сүз, сүзтезмә, җөмлә, хәбәрләмә һ.б.) торган сөйләм берәмлеге.

Текстның эчтәлек, структура тел, стиль (өслүб) бөтенлеген саклау. Текст – язма әсәр, шулай ук әйтмә һәм күрсәтмә сөйләм үзенчәлекләре дә булган әсәр.

Иншалау алымына карап текстның төрләре: бәян итү, хикәяләү, тасвирлау, дәлилләү, билгеләмә бирү һ.б. сөйләм рәвешләре. Катнаш сөйләм. Бу төр текстларны, катнаш текстларны төзәтү алымнары.

Әдәбиятнең төрләре (матур әдәбият, журналистик-публицистик, фәнни, рәсми, тәрҗемә һ.б.), аларның жанрлары турында гомуми мәгълүмат. Әдәбият, жанр төренә карап редакцияләү үзенчәлеге. Редакторның махсуслашуы.

Текстны оештыру, төзәтү, басарга әзерләү буыннарыннан торган эшне бербөтен итеп күзаллау, эзлекле башкару күнекмәләренең зарурлыгы.

Авторның кульязма текстына эчтәлек, төзелеш ягыннан дәүләт стандарты таләпләре. Нәшрияттә кульязма хәрәкәтенең кагыйдә, тәртипләре.

**Текст төшенчәсе**нең һәм терминының ни икәнен без инде икрар иткән идек, кыскача гына кабатлап алыйк. Текст – катлаулы күренеш: текст – ул фиксацияләнгән, беркетелгән сөйләм (сүз, сүзтезмә, җөмлә, фраза, контекст); текст – ул беркетелгән, басылган фикер (төшенчә, тезис, дәлил, нәтиҗә, ягъни мантыйк берәмлекләре); текст – ул композиция, сюжет төрендәге корылышлы әдәби берәмлек, жанр төре; текст – ул эчтәлекне рубрикалап, бүлемләп бәян итү (бүлек, бүлекчә, параграф, пункт, матдә, кызыл юл һ.б.).

Бу дүрт төрле берәмлек кушылып та китә. Төшенү һәм төзәтү сүздән фразага таба бара. Фраза әле бөтен әсәр түгел. Фразадан гына бөтен әсәрне бәяләп булмый. Ярамый да. Тик гамәлдә кайвакыт әсәрне, аеруча тәрҗемә әсәрен, аерым өзекләренә карап кына бәяләүгә юлыгабыз.

Текст бер бөтен дип күзалланырга тиеш. Шул ук вакытта ул чагыштырмача мөстәкыйль өлешләрдән тора. Әйтик, Галимҗан Ибраһимовның 8 томлык “Сайланма әсәрләре”. Сигез томны берләштергән *күптомлык* — аерым бер *том* — шул томда (китапта) аерым бер *әсәр* (роман, пьеса, хикәя һ.б.) — әсәрнең бер *кисәге* — кисәкнең бер *бүлеге* — *бүлекчәсе* — *параграфы* — *пункты (статьясы)* — бер өлеше (микротекст,

кызыл юл, фраза) — бер *җөмләсе* — бер *сүзтезмәсе (синтагма)* — бер *сүзе — иҗеге — хәрефе (авазы).* Һәркайсы үзенә мөстәкыйль бөтеннәр һәм шул ук вакытта үзләреннән эрерәк бөтеннең бер өлешен хасил итәләр.

Текст турында нәзәри нигезләмәләр әле тәмам өйрәнелеп бетмәгән. Элегрәк ул әдәбият теориясе белемендә өйрәнелеп, әдәбият төшенчәсе буларак күбрәк анализлана иде, без аны мәктәптән әдәби текст дип, жанрга бәйле дип белә идек.

Ә бит текст иң әүвәле тел белән, тел ярдәмендә барлыкка килгән берәмлек. Соңгы елларда тел фәне дә текстка үз объекты дип карый башлады, аның белән хәзер телчеләр дә кызыксына.Махсус хезмәтләр барлыкка килде. Татарча өч хезмәткә игътибар итегез: Ф.Сафиуллина "Текст төзелеше", В.Гарифуллин "Газет тексты төзелеше", И.Низамов "Уем – тел очында// Татар сөйләме нигезләре" (Икенче кисәк).

Әйтик, синтаксис җөмләләрне генә түгел фикерне белдерә торган эрерәк берәмлекләргә (урысча сверхфразовое единство, татарча синтаксик бөтен яисә микротекст) төшенчәләрен өйрәнүгә игътибарны көчәйткәннән-көчәйтә бара. Алай гына да түгел текстны хәзер тел белеме берәмлегеннән дә бигрәк сөйләмият берәмлеге дип өйрәнүгә юнәлеш тотыла башлады. Без дә бу курсны үткәндә редакцияләү эшенең сөйләм эшчәнлеге дип, ә текстны сөйләм берәмлеге дип карауны фәнни дип, гамәли әһәмиятле дип исбат итәргә тырышырбыз, моңа махсус бер бүлек багышларбыз. Ә әлегә гомумиләштереп, шушыны әйтик: текст – ул мәгънәви яктан тикшерелергә тиешле берәмлек. Аның асылы грамматик структура, ягъни төзелеше белән билгеләнә, ул психология, мантыйк фәннәре белән турыдан-туры бәйләнешкә керә, дөресрәге, ул соңгы вакытта мөстәкыйльлек алган психолингвистика, социолингвистика фәннәре белән дә категоия буларак эш итә. Бу яссылыкта аның кайсы сыйфатларына игътибар итү сорала? объект буларак конкретлашкан булуына; мәгълүм бер тамга (язу) системасы белән тәгаенләнүе; бер-берсенә аерылгысыз бәйләнгән өлеш-кисәкләрдән торуы. бербөтенлек хәсиятенә ия булуына.

Тел системасында һәм сөйләм системасында карала алу мөмкинлеге аның яңа закончалыкларын барларга юл ача: тел һәм аң (фикер) бердәмлеге (бу гомуми күренеш); фикер һәм сөйләм – бу инде конкрет процесс; текст – конкрет күренеш. Димәк ки, текст турыдан-туры сөйләм һәм фикерләү процессы белән, ә алар аша тел һәм аң (акыл) белән бәйле.

Текст – бөтен, әмма ул җыелма бөтен. Текст сүзе үзе үк (латинча textum) бәйләү, тукыманы аңлата. "Әсәрнең тукымасы" дигән төшенчәнең булуы юкка түгел, күрәсең.

Бу – уйланырга мәҗбүр итә торган ачыклау. Тукыма, бәйләнгән әйбер шундый органик, эзлекле бәйләнгән, теркәлгән була ки, аның бер җебенә тәэсир итү бөтен тукымага тәэсир итми калмый. Шушы сүзне, шушы җөмләне төзәтә, дөресли башлар алдыннан аның бөтен текстка, бөтен әсәргә ничек тәэсир итәрен уйларга, алдан күрергә кирәк була.

Текст – язма бөтен. Гади сөйләү әле текст түгел, текст – оештырылган, уйланган язма продукт. Бу – тулаем редакторлык эшен китереп чыгарган закончалык. Моның нигезендә “автор – укучы” бердәйлеген күздә тоткан коммуникатив максат ята. Шунсыз текст була алмый. Шул ук вакытта сөйләм берәмлекләренең һәм язма берәмлекләренең (морфема, лексема, синтагма, фразема-хәбәрләмә һ.б.) үзенчәлекләрен яхшы күзаллау зарур. Дөрес, язма текстта да мәгънә, фикер төсмерләрен чагылдыра торган кызыл юл, иллюстрация, шрифт чараларын редактор истә тотарга тиеш. Аеруча катлаулы язма формалар бар: формула, сызым, сурәт, таблица, сводка, графика һ.б. Аларны укучының кабул итүе дә үзенчәлекле икәнен истә тоту сорала. Баш хәреф, юл хәрефе, кызыл юл тамгасы һәм башка символ-тамгалар бары язу белән генә бәйле, аларны сөйләм берәмлеге дип санаган очракта да әйтү, ишеттерү проблемалы булып кала. Бу өлкәдә әле кимчелекләр дә җитәрлек, фәнни өйрәнү өчен алар да нигез була ала. Әйтик, “Чаян”да еш кына аерым текстлар тәнкыйть ителә. Тик аларның күпчелеге бөтен текст үзе түгел, ә бөтен тексттан өзеп, кисеп алынган өзекләр; аларга төп сөйләм берәмлегеннән аерып алып бәяләү – уңаймы ул бәя, тискәреме – барыбер, дөрес түгел – уңай нәтиҗә бирми.

Шулай да текстны сөйләм берәмлеге буларак күзаллау, аеруча теле,-радио текстларын редакцияләү барышында бик әһәмиятле.

Текстны иншалау төренә карап аеру да әһәмияткә ия. Мондый күзәтү-анализлау башлыча жанр төрләренә бәйләп бәяләүгә кайтып кала. Шулай да иншалауның төп рәвешләрен редактор тоемларга, аларның буталуына тискәре фикер белдерергә тиеш. Төп иншалау рәвешләре болар:

– фикер йөртүне бәян итү (рассуждение) – ул хәлне яки предмет тикшергән, аларның эчке билге, үзенчәлекләрен ачкан, нинди дә булса нигезләмәләр, кыйбланамәләр исбат ителгән текст була;

– тасвирлау (описание) – ул предметның, хәлнең шушы вакыйга булган төп билгеләрен, үзенчәлекләрен сөйләп, санап чыгу, сурәтләп, тасвирлап, сынландырып, гәүдәләндереп бәян итү;

– хикәяләү (повествование) – ул вакыйга, хәлләрне вакыт ягыннан эзлекле итеп сөйләп, санап чыгу.

Элекке риториклар болай өйрәткән: хикәяләү хәрәкәтне, тасвирлау – предметны, ә фикер йөртү предмет белән хәрәкәт арасындагы мөнәсәбәтне белдерә. Хикәяләү – хәтер җимеше, тасвирлау – тышкы хис нәтиҗәсе, ә фикер йөртү – ул акыл белән хисләр бердәмлеге нәтиҗәсе.

Чип-чиста хәлендә иншалау төрләре аерым-аерым очрамый диярлек. Шулай да редактор текстны таркатып карап анализларга бурычлы булганга иншалауның шундый төрләрен тоемларга, аларның нәкъ шушы урында шушылай дөрес, урынлы булуын бәяли белергә тиеш. Бу редактордан шулай ук жанр төрләренең, сөйләм төрләренең нечкәлекләрен белүне дә таләп итә.

Әдәбият (проза, шигърият, фәнни, рәсми әсәрләр, драматургия, публицистика) төрләрен аеру, шуларның сөйләм үзенчәлекләренә бәйле рәвештә төзәтү нечкәлекләре махсус өйрәнүне, күнегүләр үтүне сорый.

## *Бишенче тема:* Төзәтү алымнары һәм төрләре

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Төзәтү нәрсә ул? Максаты, бурычлары. Автор белән элемтә. Төзәтүнең төрләре. Аларның әдәбият, жанр төренә карап үзгәрүе.

***Чагыштырып төзәтү.*** Классик язучыларның әсәрләрен, рәсми документларны, фәнни, тарихи һ.б. язмаларны кабат бастырып чыгару. Бу төр текстларны редакцияләү үзенчәлеге. Элек киткән хаталарны төзәтү, яңаларын җибәрмәү алымнары. Редактор укуы белән корректор укуы арасында аерма. Текстны тулаем һәм цитатлап чагыштыру.

***Кыскартып төзәтү.*** Максаты. Текстны кыскарту ихтыяҗы, сәбәпләре, төрләре. Кыскартуның һәм редакцияләүнең китап, газет, радио, телевидение текстына карап аерымлыклары. Типик хаталар, аларны җибәрмәү юллары. Автор белән эшләү алымнары.

***Эшкәртеп төзәтү.*** Эшкәртүнең текст буена эзлеклелеге. Әдәбият, жанр төренә карап үзенчәлеге. Эшкәртүнең һәр очракта акланган булуы, авторның ризалыгы. Эшкәртеп төзәткәндә яңа хаталарга юл куймау алымнары.

***Кабат язып төзәтү.*** Текстны кабат язуның сәбәпләре, методикасы. Әдәби эшкәртү. Әдәби язу. Һәр ике очракта автор белән эшләү үзенчәлеге. Редакторның иҗади мөстәкыйльлеге. Автор хокукы.

***Тәрҗемә текстын редакцияләү - төзәтү.*** Максаты, бурычлары, методикасы. Оригиналны, тәрҗемә текстын уку, анализлау үзенчәлеге. Тәңгәллеккә ирешүне бәяләү. Хата табу, төзәтү алымнары. Үзең тәрҗемә иткән, бүтән кеше тәрҗемә иткән текстны редакцияләү үзенчәлеге. Әдәбиятнең, жанрның төренә карап тәрҗемә текстын төзәтүдә аерымлыклар.

Газет, радио, телевидениедә редакторның автор хатларын төзәтү методикасы, психологиясе.

Төзәтүнең әлеге төрләрен катнаш куллану очраклары. Редактор игътибарының эзлеклелеген, зиһененең текст буена бөтенлеген саклау күнекмәләре.

Текстны төзәткәндә кулланыла торган тамгалар системасы: кульязманы төзәтү тамгалары; корректураны төзәтү тамгалары. Дәүләт стандартлары, аларны үтәү методикасы.

Текстны техник редакцияләү, басмаханәгә озатырга әзерлек барышы.

Бүгенге татар редакторы менә бу төр редакцияләү эшчәнлегенә җәлеп ителә:

– үзе язып, үзе редакцияли – бу, гадәттә, газет- журнал, радио, телевидение редакцияләрендә шулай; бу очракта да редактор берничә кат укырга тиеш була: язганнан соң, компьютердан соң, корректурада, кыскарту ихтыяҗы туса һ.б;

– автор материалын редакцияләү: аның берничә төре бар. Мәсәлән, чагыштырып төзәтү (эчтәлеген һәм формасын үзгәртмичә; текстны берникадәр үзгәртү (кыскарту, өстәмә, комментар бирү; үзгәртүләр белән кабат язып һ.б.);

– тәрҗемә текстын редакцияләү (үзең тәрҗемә иткән текстны редакцияләү, бүтән тәрҗемәче текстын төзәтү; чагыштырып төзәтү, автор һәм тәрҗемәче кабат эшләгәннән соң төзәтү һ.б.).

Темасы дөрес сайланган, җиренә җиткерелеп башкарып, бер кат эшкәрткәннән соң автор редактор күрсәтмәләрен үтәгәннән соң текст нинди була? Ул ничек төзәтелә, нинди алымнар белән? Тулаем алганда әзер текстны төзәтү менә нинди максатларны куя:

– автор эшкәртеп китергәннән соң да калган хата, буталчыклык, кытыршылыкларны бетерү;

– барлык фикер, билгеләмәләрнең дә ачык, төгәл, аһәңле булуына ирешү;

– фактик материалны тикшереп, аларның дөреслегенә шик калдырмау;

тел һәм стиль кытыршылыкларын бетерү;

– кулъязманы редакцион-техник яктан типографиягә озатырга әзерләү;

Текстны төзәткәндә һичшиксез үтәлергә тиешле берничә кагыйдә бар:

– төзәтүнең кирәклеге исбат ителгән, дәлилләнгән булырга тиеш;

– төзәтү бер-бер артлы, эзлекле (баскычлы-баскычлы) булырга тиеш.

Төзәтү алымнары берничә, дидек, башлыча менә болар: чагыштырып төзәтү, кыскартып төзәтү, эшкәртү, яңадан язу, тәрҗемә текстын төзәтү.

### Хата нәрсә ул? Аны нигә төзәтергә?

Башта бүлекчәгә кереш урынына тәҗрибәле редакторыбызның истәлекләреннән бер гыйбрәтле өзек:

“Бу хәлне мәрхүм Нурулла абый Габитов бик тә яратып сөйли торган иде. (Татарстан китап нәшриятендә озак еллар баш редактор урынбасары булып эшләде). Англиядә энциклопедияне бер хатасыз чыгармакчы булалар. Моның өчен иң шәп корректорлар җәлеп ителә, кат-кат уку кертелә, күп акча сарыф ителә. Чыннан да эчтә хата табылмый. Ә менә тышлыкта ат башы хәтле хәрефләр белән “Энциклопудия “дип язылган була...

Ерак утраудан үзебезнең Казанга, шул ук Китап нәшриятенә әйләнеп кайткач, кылт итеп, мәрхүм Рим Шириязданов искә төште. Бу тәҗрибәле редактор бер кульязманы кат-кат бик җентекләп укый да, корректор халкына тантаналы төстә игълан итә, хата тапкан кешегә шоколод

бирәчәкмен, ди. Менә кульязма дәфтәре тотып (зур кульязманы корректорлар бүлешеп укый) бер корректор килеп керә. Аның артыннан – икенчесе, өченчесе, дүртенчесе, бишенчесе. Печтек кенә акча алып эшләгән ханымнар һәм туташларның авызы татлы тәгангә тиенә!

Алла саклады, мин җитди хаталар җибәрмәдем. Бер тапкыр тимер юл вокзалы янындагы “Волга” кунакханәсен 2 катлы дип язганмын. Ә ул 4 катлы икән (Тагын ялгышмыйм микән инде, Ходаем?). Тәбәнәк тоелган да, хәтер шуннан китереп чыгарган, күрәсең. Нәтиҗә ясадым: хәтергә таянырга ярамый! Шуннан соң салкын суны да өреп каптым: үзем эшләгән нәшрият турында язарга кирәк булгач, этажын урамга чыгып санадым.

Җиллерәк сабак алу да насыйп булды. “Т.Я.”да өч кеше укый иде: редактор, корректор һәм сафбаш, ягъни дежур журналист (хата, кимчелекләрне шәп тотсын өчен эшкә полосалар өлгергәч кенә – башы саф хәлдә килә). Мин, сафбаш, уяулык күрсәттем: бер сугыш ветераны атаган елга исемен картадан эзләп таптым. Редакторыбыз янына кош тоткан кебек кереп, хатаны төзәттердем: “Сиреть” түгел икән бит, “Сереть” икән теге елга! Шуннан соң бер атна үттеме-юкмы, географик атлас актарырга туры килде. Шаккаттым: атамалар исемлегендә “Сереть” дигән елга да, “Сиреть” дигән елга да бар икән. Димәк, мин ветеранны каны тамып калган елга ярыннан ул бөтенләй белмәгән җиргә күчереп сугыштырганмын!

Ничек кенә тикшермә, журналист хатадан хали түгел. Кайбер хата чуртаннары әллә ничә пар күз һәм күзлек салган җәтмәдән маймыч кебек кенә үтеп китә. Хәзерге компьютер заманында алар, язмыш шаяртуы кебек, һич көтмәгән яктан да йөзеп чыга ала икән.

Ләбиб Леронга “Идел” өчен эпиграммалар язарга заказ бирдем. Рәдиф Гаташ исемен атагач, ипләбрәк яз, ул юмор мәсьәләсендә нәзберек дип кисәттем. Ару гына килеп чыкты эпиграмма. Менә санның (2004, №10) сигнал нөсхәсе кулга керде. Өйдә, диванда, бар дөньямны онытып, ләззәт кичереп шуны карап ятам. Чү, ни бу? Ничек болай була ала? Миңа хәзер чыгырдан чыгарга, ярсырга кирәк. Мин исә тыела алмыйча көләм. 62 нче биттәге “Безне авыл саклап калырмы?” дигән мәкалә башын компьютер 35 биткә китереп сылаган. Кая диген әле, Гаташ эпиграммасының азагына, нәкъ шундый шрифт белән – эпиграмманың дәвамы итеп! Юкса укыган идек бит инде, корректурада бар да үз урынында иде... Ярый Рәдиф үпкәләмәде тагы. Ә менә башларның анысы түгел, “Этләр дә мәрхәмәтлерәк” дигәне ялгап куелган булса?..”.

**Чагыштырып төзәтү (правка-вычетка)**

Нинди текстлар бу төр редакцияләүгә җәлеп ителә?

– Рәсми документлар (Россия Федерациясе, Татарстан республикасы Конституцияләре, башка Закон, Карар, Указлар һ.б.);

– тарихи шәхесләрнең, дәүләт җитәкчеләренең хезмәтләрен яңадан бастырып чыгару;

– классик язучыларның әсәрләрен кабат бастырып чыгару.

Бу төр әдәбиятне чагыштырып бастырып чыгару тәртип, методикасы менә бу ике документта билгеләнә; аларга әле дә таяныырга мөмкин: 1) “Правила издания исторических документов “, М., 1956; 2) “Правила издания документов советского периода”, М., 1960. Аларда андый текстларның төрләре ачыклана, аларны сайлап алу принциплары күрсәтелә, басарга әзерләгәндә нинди фәнни-белешмә аппарат белән тәэмин итәргә кирәклеге бәян ителә һ.б.

Чагыштырып редакцияләүнең максаты, иң беренче чиратта, редакцияләнә торган текст рәсми оригинал белән тәңгәл булырга тиеш.

Бу текстка редактор нинди үзгәртү, төзәтү кертә ала?

– рәсми документка рәсми рәвештә үзгәреш кертелгән булып та, (мәсәлән, Татарстан Конституциясенә Татарстан Дәүләт Советы тарафыннан үзгәреш кертелеп) текстка ул кертелмәгән булса;

– беренче басмасына рәсми үзгәрешләр игълан ителгән булып та алар үзвакытында кертелмәгән булса;

– беренче басмасында төзәтүләр бирелгән булса;

– беренче басмасында, хәреф, пунктуация хаталары җибәрелеп тә, алар төзәтелмәгән булса.

Мондый хаталар мәгънәгә өстәмә төсмер бирелмәслек булганда гына бернинди аңлатмасыз-искәрмәсез төзәтелә. Әгәр икемәгънәлелек, буталчыклык килеп чыга икән, аңа искәрмә бирелә. Мәсәлән, “Г.Тукай турында хатирәләр” җыентыгында (Казан, 1976) С.Сүнчәләй хаты бирелгән. “Мәрхүмне бик яратсам да, аның хакында мөгаттәәсеф киң мәгълүмат бирә алмыйм, чөнки библиограф куәсе миндә юк... Төзүчеләр биргән битасты искәрмәсендә: “Библиограф” сүзе “биограф” сүзе урынына ялгыш кулланылган”, диелгән.

Чыганакта нинди дә булса сүз, кисәк төшеп калып, мәгънәне аңлау авырайса яисә аңлашылмаса, бу төшенчәне өстәргә кирәк; әгәр кыскартылган булып, шулай ук начар аңлашылса, аны да кире кайтарырга кирәк. Өстәлгән, төзәтелгән яисә аңлатылган сүз (өлеш) квадрат җәяләр эченә алына;

– чыганакның тексты кулланыштагы орфография һәм пунктуация кагыйдәләре нигезендә редакцияләнә, аңлаешсыз сүзләргә (тамгаларга) искәрмә бирелә, шул ук вакытта стилистик (яисә автор чалымнары) үзенчәлекләр төгәл саклана;

– чыганакта, аеруча документларда сүз яисә билгеләр ачык язылмаган, аңлаешсыз булса, алар урынына өч нокта куела, искәрмәдә моның сәбәбе аңлатыла (мәсәлән, “текстта берничә сүз танылмый”).

Китапның тышына, титул битенә, алардагы сан, нумер, даталарга игътибар ителә, еллары төзәтелә. Эчтәлектә бүлек, параграф исемнәре, нумерлары текст белән чагыштырыла, элекке тексттагы басма мәгълүматлары (выходные данные) сызылып, яңасы языла. Иске эчтәлек

белән яңа эчтәлекне чагыштыруга аеруча диккать итәргә кирәк. (Шәхсән үзем катнашында җибәрелгән бер хата турында әңгәмә).

Кыскасы, чагыштырып редакцияләү дә иҗади эш. Ул чагыштырып укучы корректор эшеннән нык аерыла. Монда күбрәк акыл хезмәте, иҗтимагый сизгерлек, тәҗрибә зур роль уйный.

**Күнегү максатында куен дәфтәренә ике мисал:**

**Классикны... "редакцияләү"**

1 мартта Казан телевидениесе татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулу датасы якынлашу уңаеннан әдипнең "Йөз ел элек" хикәясен тапшырды. Әсәрне Фирдәвес Җәмилов укыды.

Күптән яхшы таныш, әмма һичбер күңел кайтармый, тешне камаштырмый торган хикәяне йотлыгып тыңлый башладым. Башкаручының яттан укуына дәгъвам юк диярлек, җитенкерәмәгән яклары режиссер намусына калсын. Мәгәр классик әдибебезнең язганнарын, йомшак итеп әйткәндә, "редакцияләү", ә турысын әйткәндә ботарлауга битараф калып булмый. Хикәяне баштарак текст белән чагыштырмый тыңладым. Сизәм: Галимҗан Ибраһимовча ук түгел, "туп-турыдан тут пошел" җөмләләр китте. Классик язучының әлеге хикәясе басылган томны кулыма алдым һәм, тыңлау ләззәтен җуеп булса да, текстны башкаручы сүзләре белән чагыштырып барырга карар иттем.

Классик язучыны "редакцияләү" мисалларының берничәсе:

"Энем Әбүбәкер, *ялганлап* ике гөнаһка батма" дигәнне актер, ни өчендер, "*ялган сөйләп"* дип үзгәртә.

"Кара мәлгуньне, кара урыс башын" дигәндә нәфис сүз остасы *"кара әле син мәлгуньне, кара әле син урыс башын*" дип "тулыландыра".

"Соңрак шаһитләрдән *сорадылар*" дип яттан укый актер. Г.Ибраһимовта исә "Соңрак шаһитләрдән *соралды*" диелгән. Сизәмсез, нинди төсмер, мәгънә нюансы югала?

"Алдыйлар, хәзрәт, мин үз йомышым белән кергән идем". Бу – авторча. Ә башкаручы "мин *бары тик* үз йомышым белән кергән идем" дип "тулыландыру"ны хәерле күрә.

Авторда: "Халык капыл *җанланып китте*. Артист: "Халык капыл *җанланды*", ди.

*"...Күпчелек* бу сүздән бөтенләй җенләнде" диясе урынга зәңгәр экрандагы башкаручы: *"күбесе"* дип үзгәртә...

Кайда, кайчан, кем рөхсәт биргән әле мондый башбаштаклыкка? Андый юлга басалар икән, кирәкми, ятламасыннар артистлар текстны. Китаптан укысыннар! Галимҗан Ибраһимовча текст кадерле безгә. Аның моңы, аның аһәңе кадерле.

Барлас Камалов (С.Т., 1987, 7 март).

(Язма эчендә бер әһәмиятле искәрмә бар: Җәяләр эчендә бер факт белән килешүемне әйтим: китапта сноскаларда аңлатма бирелгән иске сүзләр бүгенге телебездәгечә алынган. Әйтик, фәүкыльгадә – гадәттән тыш, могтәбәран – күренекле, олы һ.б.).

**Редактор Рәис Даутов белән әңгәмәдән**

**– Рәис абый, Сез инде 35 елга якын Татарстан китап нәшриятында эшлисез. Г.Тукай, Г.Камал. Г.Ибраһимовларның күптомлыклары басмага Сезнең турыдан-туры катнашыгыз белән әзерләнделәр. Гомумән, китапны редакцияләү нәрсәдән гыйбарәт? Ул бөек әдипләрнең әсәрләре дистәләгән мәртәбәләр басылган. Аны күчереп кенә басып булмыймыни?**

– Моны бер-ике сүз белән генә аңлату кыен, шулай да батырчылык итеп карыйм. Төрле елларда ул әсәрләр төрле кешеләр тарафыннан бастырып чыгарылганнар. Кайберләре аңлы рәвештә, кайберләре аңламаганнан төрлечә "төзәтелгәннәр", "эшкәртелгәннәр", "шомартылганнар". Безгә хәзер шуларны чагыштырып, әсәрнең асылына кайтарырга кирәк. Әдипнең үз вариантларына кайтырга, әгәр ул чыганак булмаса, шуңа якынын сайлап алырга кирәк.

Инде борыңгы әдәби ядкарьләребезгә килсәк, монда мәсьәлә тагын да катлаулырак. Менә без Кол Галинең мәшһүр "Кыйссаи Йосыф" поэмасын бастырып чыгардык. Йөзләгән вариантлар бар. Гасырларны кичә-кичә, төрле төбәкләрдә төрле хаттатлар ( китап күчерүчеләр) тарафыннан күчерелеп, бик күп вариантлар барлыкка килгән. Галимнәр әнә шулардан уртак текст булдырдылар. Шуннан соң ул безнең өстәлгә керде. Һәрбер сүзне, һәрбер җөмләне аерым барлап чыгарга кирәк. Аңлатмалар бирергә кирәк. Галимнәр үзләре дә төрлесе төрле фикердә. Уртак фикергә килгәнче эзләнергә, бәхәсләшергә туры килә... Әнә шулай айлар, еллар үтә шуннан соң гына китап сезнең кулга килеп җитә. Утыз Имәни әл-Болгари, Акмулла әсәрләре белән дә шулай эшләдек.

(**Мөдәррис Әгъләмов** белән **Рәис Даутов** әңгәмәсеннән. Яшь ленинчы, 1988, 12 март).

**Кыскартып төзәтү (правка-сокращение)**

Текстны төзәтү берничә максаттан була: материалны конкрет бер тема, бер ситуация кысаларына сыйдыру өчен; текстның кимчелеген бетерү өчен; билгеләнгән, планлаштырылган күләмгә сыю өчен һ.б.

Һәр очракта да текстның эчтәлегенә, аның аңлаешлылыгына зыян килмәскә тиеш, кыскарту зыян чыганагы, сәбәбе булмаска тиеш.

Газетта кыскарту аның битләр саны, урын күләме белән чикләнгәнлегеннән килә. Китапта исә планга кайтып кала. һәр очракта редактор регламентация таләпләренә буйсынырга мәҗбүр. Монда да уйлап, төрле рационал чаралар табарга омтылып, җаваплылыкны үз өстенә алып, иҗади эш итәргә күнегергә туры килә.

– иң әһәмиятле фактлар төшеп калмаска тиеш; фикер агышында (мантыйк) өзеклек, кытыршылыклар, икеле-микеллелек барлыкка килмәсен. Андый кимчелекләрне текст кабат укылып чыкканда гына "тотып" була;

– физик кыскарту, урынны саклау чараларын эзләргә, табарга кирәк. Бу юлда энциклопедияләрне, календарьларны төзү, редакцияләү, бастырып чыгару тәҗрибәсе әһәмиятле. Татар календаренда без *кг, кубм.* кебек кыскартуларга, эчтәлегенә карап шрифт, кегль белән көйләүгә күнеккәнбез.

Хрестоматияләр төзегәндә, документлар җыентыгын туплаганда темага, ситуациягә буйсындырып кыскарту еш кулланыла. Мисалга журналистика фәннәре буенча төзелгән мәҗмугаларны күзәтергә кирәк (мәсәлән, "Ялкынлы еллар авазы" һ.б. җыентыклар). Аларда, гадәттә, кыскартылган өлеш квадрат җәяләр белән күрсәтелә (< ... >), кыскарту искәртелә.

Кыскарту кульязманы кабатланган, бертөрле фикер, төшенчәләрдән, бер типтагы, тавтологик фактлар, теманы төгәл ачарга ярдәм итми торган вак деталь, күренешләрдән, төп мәгънә, темадан ерак торган кереш өлешләрдән, урынсыз чигенешләрдән арындыру өчен дә ярап куя.

Барлык кыскартулар да автор белән килештерелә. Дөресрәге, редактор тәкъдим иткәннәрне автор үзе кыскартып китерергә тиеш.

**Эшкәртеп төзәтү (правка-обработка)**

Еш кулланыла торган төзәтү төре. Фикернең мантыйкый эзлеклелегенә, төзеклегенә ирешү өчен редактор сүзләрнең, гыйбарәләрнең, тропларның төгәл мәгънәсе нәкъ шушы сүз, гыйбарә булуына, җөмләдә нәкъ шушы урында булуына ирешә.

Шул ук вакытта авторның тел, стиль үзенчәлекләрен дә сакларга тырыша. Аның белән килештереп эшли. һәрхәлдә кимчелекне, аны төзәтү сәбәбен һәм чарасын фәнни нигезли һәм дәлилли. Авторның үзенең иҗади эзләнүләрен таләп итә. Яңа вариантларны да анализлый.

Бер үк вакытта чагыштыру, кыскарту алымнарын да куллана. Автордан фактик материалның, цитатларның чыганакларының дөреслеген язмача раслата.

**Яңадан язып төзәтү (правка-переделка)**

Бу алым вакытлы матбугатта, радио, телевидениедә, язу тәҗрибәсе җитәрлек булмаган авторлар белән кечерәк күләмле әсәрләр язып бастырганда кулланыла. Материал бар, әмма ул әле мәкалә, хат яисә башка рәсми жанрлар таләпләренә туры килеп бетми. Аны әдәби яктан, нигездә, өр-яңадан язып эшкәртәсе бар. Тема нәшрият өчен кирәкле, аннары аңа бу автор белән киләчәктә дә иҗат итү ихтыяҗы туды бар. Шуңа күрә ул бу язмасын җиренә җиткерә алмаган очракта кульязманы төзәтүне редактор үз өстенә ала яисә бу теманы яхшы белгән автордаш табарга булыша, эшне үз контроленә ала.

Бу төр редакцияләү әдәби язу дип, һәм әдәби эшкәртү дип атала. Авторлык мәсъәләсе, автордашларга ничек түләү мәсьәләсе шартнамә белән килешенә, бу хакта басмада аерым күрсәтелә, чөнки түләү шартлары да төрлечә.

Әдәби язучы (кабат язучы дип тә атала) авторның үзенчәлеген хөрмәт итәргә, сакларга тиеш. Шунсыз укучы игътибарын җәлеп итәрлек, үзенчәлекле әсәр туа алмый. Берара Татарстан китап нәшриятендә "Яшьләр белән әңгәмә" сериясендә бер төркем күренекле шәхесләр белән әңгәмә нигезендә, аларның үзләре исеменнән (авторлыгында) китапчыклар бастырылган иде. Халыкка ошады. Алар яратып укылды. Андый басмалар хакында күренекле язучы һәм редактор Дмитрий Фурманов заманында: "... азрак кытыршырак та булса булсын, азрак "тырнасын" да ди, аның каруы автор үзе "тере" булып күз алдына киләчәк", дигән иде.

**Тәрҗемә текстын төзәтү**

Гамәлдә ике төре кулланыла:

– үзең тәрҗемә иткәнне төзәтү. Нәшриятләрдә дә, матбугатта да тәрҗемә иҗаты татар журналистларының өстәмә бер иҗади юнәлеше санала. Теләсә кайсы чорны алсак та матбугатта (радио, телевидениедә дә) тәрҗемә текстының нисбәте төзәтелә торган текстларга карата үзгәрешсез яши бирә (гадәттә ул бермә-бер нисбәтендә саклана). Тәрҗемә ителгән матур әдәбият китаплары санының һәм тиражының соңгы егерме елда кимүе күзәтелә;

– махсус тәрҗемәче текстын төзәтү.

Урысчадан тәрҗемәдә бездә элек-электән килгән бер куркыныч күренеш яши бирә, ул да булса механик тәрҗемә, икенче төрле әйткәндә, хәрефкә хәреф үк булмаса да сүзгә сүз тәрҗемә итү чире. Тәрҗемә текстын төзәтергә алынган һәр редактор иң әүвәл менә шуңа игътибар итәргә, үзен дә, авторны да текстны нәкъ менә шул кимчелектән котылу юнәлешендә эш итәргә тырышырга тиеш. Фикергә фикер тәңгәллегенә ирешү – төп максат. Моны гамәлгә ашырыр өчен:

– бөтен текстның оригиналын тулысы белән укып чыгарга, тәмам аңлап бетерергә; фикернең иң дөрес чагылырга тиешле, ягъни икеле-микелелек, буталчыклык, эзлексезлек –мантыйкый хилафлык китү ихтималы булган урыннарны билгеләп барырга. Әсәрнең кайсы әдәбият төренә (матур әдәбият, балалар әдәбияте, фәнни, рәсми, публицистик әдәбият һ.б.), кайсы жанр төренә, нинди иншалау стиленә каравын ачыкларга;

– редакцияләргә керешкәч, башта ук эчтәлеккә эчтәлек кыйбласын тотарга, форма йогынтысына бирешмәскә, форма белән эчтәлекнең органик синтезына ирешү чараларын эзлекле саклый барырга. Дөресме? соравына дәлилне киредән урысчага тәрҗемә итеп, җөмләгә җөмлә тәрҗемә итеп китермәскә;

– тәрҗемә тәңгәллегенә, дөреслегенә татар теле чаралары белән ирешелә. Оригиналдагы теләсә нинди төшенчәне, фикерне татар теле чаралары

белән белдереп була. Шуңа ирешергә кирәк. Шул ук вакытта тәңгәллеккә ике телнең дә җөмлә, сөйләм төзелешен, ягъни синтаксисы мәсьәләләрен яхшы белеп тә ирешеп була. Һәр сүз җөмләдә нәкъ үз урынында булырга тиеш.

## *Алтынчы тема*: Редакцияләүнең мантыйкый (логик) нигезләре

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Текстның фикри агышына (иншалауга) төп таләпләр. Фикернең ачык, аңлаешлы, тоткарлыксыз, эзлекле, дәлилле булырга тиешлеге. Текст өстендә эшләгәндә мантыйкның (логиканың) төп законнарын куллану ихтыяҗы, аларның гамәли әһәмияте.

***Бердәйлек законы.*** Төшенчәнең, фикернең бөтен текст буена бер мәгънәле, төгәл булу зарурлыгы. Төп темадан, төп фикердән, планнан тайпылу очраклары. Төшенчәнең алмаштырылуы. Термин, синоним куллану нормаларының бозылуы. Тезисларның алмаштырылуы. Бу төр кимчелек, хаталарга юл куймау алымнары.

***Каршылык булмаска тиешлек законы.*** Фикер агышының каршылыклы, икеле-микеле, буталчык булмавы өчен автор кыйбласының, максатының ачык, төгәл булырга тиешлеге. Фикердә нисбәт бозылуы. Урынсыз чагыштырулар. Өтек, буталчык нәтиҗә. Каршылыклы фикер агышы тудырган аптырау, ризасызлык, шик кебек кимчелекләрне бетерү юллары.

***Өченченең юклыгы законы.*** Капма-каршы фикерләр килеп туганда хакыйкатьне ачыклау таләбе. Фикер агышының каршылыксыз, нәтиҗәләрнең төгәл, бермәгънәле булырга, сорауга җавапның бердән-бер, төгәл булырга тиешлеге. Икеле-микелелеккә, буталчыклыкка юл куймау. Бу законны редакторлык эшендә эзлекле куллану мөмкинлекләре, күнекмәләре.

***Җитәрлек нигез законы.*** Фикернең ышанычлы, шиксез булуы. Бәяләмә, билгеләмә, нәтиҗәләрнең мәҗбүри дәлилләнүе. Исбатланган аргументлар белән генә эш итү. Нигезсез нәтиҗәләр каян килә? Алардан котылу күнекмәләре.

Мантыйк законнарына таянып чыгарылган кагыйдәләр, аларны үтәүнең гамәли әһәмияте, үтәү алымнары, күнекмәләре.

Мантыйкый хилафлык аркасында китә торган башка җитешсезлекләр: мәгънәви хаталар (төшенчәдә мәгънә күләменең артык йә ким булуы; ялгыш логик басым; урынсыз интонация; сүз урыны, грамматик форма бозылу һ.б. аркасында буталчыклык, өтеклек, томанлык һ.б. кимчелекләр); техник хаталар (күз хаталары, орфографик, пунктуация һ.б. кимчелекләр). Ике төр хаталарны да сиземләү, бетерү юллары, күнекмәләре.

Текстта иншалау мантыйкый (логик) фикерләү нигезендә оеша. Бу – фикернең агышы **аңлаешлы, анык, тоткарлыксыз, эзлекле, дәлилле** бара дигән сүз. Хәер, фикернең мантыйкый булырга тиешлеге тел белән аралашуның, ягъни сөйләм оештыруның гомуми кануны икәнлеге һәркемгә аңлашыладыр кебек. Фикерләү менә шундый мантыйкый нигездә булмаганда кеше эштә дисеңме, көнкүрештә дисеңме бүтәннәр белән юньле-башлы аңлаша-аралаша алмас иде. Сәламәт акыллы һәркем нәкъ шундый фикерләүгә күнеккән дә. Ул моның өчен нинди дә булса фәннең нинди дә булса закон, кагыйдәләрен белү кирәк, дип уйламый да.

Мондый гадәти караштан редактор булырга ниятләгән белгеч һичшиксез котылырга тиеш. Ә бу җиңел бирелми. Еш кына калын гына кульязманы редакцияләп чыгасың, фикер шундый да табигый, шома гына ага ки, дөньяда ниндидер фикер хилафлыгы буладыр, дип уйлап та карамыйсың. Менә бу инде бик тә куркыныч, хәтәр нәрсә. Редактор теләсә нинди фикер агышын – шул исәптән мантыйк ягыннан дөрес, кимчелексез агышны да эчтән күзәтеп, сизгер тоемлап, бәяләп барырга тиеш. Бу текст ни өчен каршылыксыз, шома укыла, ул ни өчен мантыйкка ярашлы, дөрес, әгәр хаталы булса, анда ялгышлык булса, ул кимчелек нидән гыйбарәт булырга тиеш иде, дип фаразлап укырга тиеш. Менә шундый "уңай" текстны укыйк әле:

*"Безгә тормыш итү тәртибе борын-борыннан шулай көйләнгән булган: яшь буында әхлак тәрбияләүгә өлкән буынның җаваплылыгы әвәл заманнардан бирле ата-баба әманәте булып килгән. Тик әманәткә хыянәт иткән шикелле, без шул изге кагыйдәне үтәүгә җавапсыз караганбыз. Нәкъ шуның нәтиҗәсе булып күп кенә күркәм гореф-гадәтебез юкка чыкты. Әхлаксызлыкның җәмгыятьне нинди һәлакәткә китереп җиткерүен үз күзләребез белән күреп торабыз. Ул имансызлык, денсезлек, шәфкатьсезлек, кансызлык, кешелексезлек дисеңме, моңарчы колак ишетмәгән әллә нинди бозыклыклар һәм яман чирләр. Санап чыга торган да түгел..."* (Г.Шәрәфетдинев. С.Т., 1991, 28 май).

Кабат укып чыгыйк. Сөйләмнең тоткарлыксыз, эзлекле агышының, фикер өлешләренең бер-берсенә тыгыз бәйләнүләренең сәбәбен-чарасын ачыклап барыйк: санау интонациясенең эзлекле булып, тонның аһәңле, ятышлы агышы, *тик* кисәкчәсенең, *шулай, шуның* алмашлыгының, *нәкъ, түгел, ул* мөнәсәбәтле сүзләрнең, һ.б. чараларның урынлы кулланылуына игътибар итик.

Шушылай анализлап, тоемлап укып барырга күнеккәндә иң "хәтәр" яшеренгән **хата**ны да "тотарга", ачыкларга күнегелә.

Нәрсә ул **хата**? Редакцияләү эшчәнлегенең асылын тәшкил иткән бу төшенчә белән кереш дәрестә дә, үткән дәресләрдә дә берникадәр танышкан идек инде. Күзаллауны дәвам иттерик. Текстларда, аеруча мәгълүмат чаралары өчен әзерләнә торган текстларда хата әле күп очрый. Чөнки:

– матбугат текстлары авторлар тарафыннан да, журналистлар тарафыннан да ашыгыч әзерләнә;

– авторларның гомуми белеме, беренче чиратта, ана телен куллана белүе, язу осталыгы, тәҗрибә дәрәҗәсе төрле. Башка сәбәпләр; текстны уку барышында тап булган хаталарның һәркайсы анализлана, ачыклана барырга тиеш. Искәртик: бу кулланмада мисалга, анализга очраклы текстлар түгел, ә бәлки басма матбугатта, радио,-телевидение, интернет текстларында юл куелган конкрет хаталар китерелә, ягъни инде редакцияләнгән, шулай да төрле сәбәпләр аркасында хаталардан арындырылмаган язмалардан алынган мисаллар.

Текстны уку барышында редактор һәр очракта “хата китмәгәнме? “дип шик белдереп укый, мантыйкый эзлеклелекне эчтән күзәтә бара. Гомумән алганда, хатаны тотуның, аны төзәтүнең тәртип-методика-механизмын болаерак күз алдына китерергә була:

–фикер аңлаешлымы, каршылыклы түгелме, эзлеклеме, нигезле-дәлиллеме дип шик белдереп укып-уйлап барганда бер кимчелек-китеклеккә, хилафлыкка килеп төртеләсәң;

– аның нинди кимчелек икәнен ачыклыйсың, анализлыйсың, хата буларак асылын төшенәсең, хатаның без санап киткән, гомумән хата дип күпчелек тарафыннан, фәнни кабул ителгән кимчелеккә каравын тәгаенлисең;

– ни сәбәптән килеп чыкканын үзеңә, аннары авторга төшендерәсең;

– ничек, нинди алым-чаралар белән төзәтергә кирәклеген хәл итәсең;

Гадәттә менә бу методик процесс уйланып кына калынмый, ә бәлки язмача теркәп тә куела. Бу схема-тәртип редактор бәяләмәсе язар һәм автор белән эшләр өчен план төзү максатында кирәк икәнлеген кисәткән идек.

Бу анализ барышында редактор тоя: теләсә нинди кимчелекне дә ул ана теле ярдәмендә төзәтә алачак. Мантыйкый кимчелекне тоемлау, аны төзәтү юлын эзләү, моның өчен телнең кайсы-кайсы чараларын кулланырга икәнен эзләү белән бергә бара. Менә ни өчен миннән: “Кем ул талантлы, оста, тәҗрибәле редактор? дигән сорауга “Мантыйкый фикерләүгә һәм телне тоемлауга сәләтле зирәк редактор”, дип җавап бирәм.

Фикер агышына бәйле, ягъни мантыйкый хаталар нидән гыйбарәт?

– фикер, аның агышында ясалган тезис, нәтиҗә чынбарлыкка, реаль тормышка туры килми; чын хәл ничек булган шулай бәян ителми, ә бүтәнчә, ялгыш җиткерелә; иҗтимагый текстларда җибәрелә торган мондый хаталарның зарары аеруча зур булганга, аларны сәяси хата дип йөртәләр. Мисалга Конституция проекты текстында “Безнең илдә хатын-кызлар ирләр белән тигез хокуклы” дигән статьяда юл куелган мантыйкый хатаны ачыклыйк әле. Хатын-кызның тигез хокуклылыгын дәлилләү өчен аларны ир-ат белән чагыштыру мантыйкка сыямы соң? Дөресе: *хатын-кыз белән ир-ат тигез хокуклы* түгелме?

Иҗтимагый-сәяси хаталар, башлыча, менә мондый сәбәпләр аркасында китә: авторның иҗтимагый-сәяси аң дәрәҗәсе түбән булу, иҗтимагый активлыгы җитмәү; шушы теманы, әңгәмә объектыңны белеп бетермәү, бу өлкәдәге яңалыклар белән таныш булмау, мәгълүматың җитешмәү һ.б. Әлбәттә инде, фикер агышын төгәл җиткерү, мәгънәгә тәңгәл тел берәмлекләре табу өчен тел байлыгың җитешле булмау – төп сәбәпләрнең берсе. Монда сөйләм оештыру закончалыкларын, ягъни мотивларга бәрабәр тел чаралары табу осталыгы җитмәү, аларны редакцияләү эшендә куллана белмәү кимчелеге дә өстәлә.

Татарча текстларда иҗтимагый-сәяси хаталар, гадәттә, тәрҗемә текстларында китүчән. Монда тәрҗемәченең темага очраклы алынуы (үзе теләп түгел, кушканга) бу темага муафыйк белеме, эрудициясе, кызыксынуы, аң-фикер дәрәҗәсе җитмәве, теманы фәнни нигездә төпле белмәве, белемен тулыландыру өчен белешмә-кулланмаларга мөрәҗәгать итәргә вакыты булмавы, җаваплылык җитмәү, ваемсызлану сәбәп була. Редактор да мондый төр ялгышуларга сизгерлеген югалта, авторга карата таләпчәнлек күрсәтми.

Өстәвенә, тәрҗемә текстына җиңел эш дип карап, редакторның үзенең дә ана телен белү, аеруча аны куллану, ягъни сөйләм оештыру закончалык-тәртипләрен, редакцияләү процессында куллану үзенчәлек-закончалыкларын белмәве нык сиздерә.

Редакторның ана телен нечкә тоемлавының хата төзәтү өчен төп коралы икәнен раслаган берничә дәлил китерү урынлы булыр. Телне оста белгәндә ул текстның кытыршылыкларын бетереп кенә калмый, ә гомумән эчтәлекнең чын асылын, нечкәлекләрен бирүгә ирешә. Мәсәлән, урысчадан татарчага тәрҗемә текстында смена капитализма, крушение колониализма формасындагы әйләнмәләр гадәттә *капитализмның алышынуы, колониализмның бетүе* кебек формада, *образование, развитие белем бирү, үсүе (үсеше)* сыйфатында, ягъни пассив берәмлекләр белән тәрҗемә ителә. *Татарстан нефть сәнәгатенең үсүе* дип. Ә бит татар теленең агглютинатив тел буларак актив төсмерне бирергә дә мөмкинлеге мулдан. Сәнәгать үзе үсми бит, ягъни, дөрес тәрҗемә: *Татарстанның нефть сәнәгатен үстерү.*

## Мантыйк законнарына тугрылык

**Бердәйлек законы**: мәгълүм бер фикер йөртүдә**,** бәхәстә, дискуссиядә бер төшенчә бер үк мәгънәдә кулланылырга, үзгәрмәскә, төшенчә белдергән берәмлек текст буена бер мәгънәле килеш дәвам итәргә тиеш. Мәгънә төсмере өстәлгән синоним (контекстуаль синоним) куллану хупланмый. Колачлырак итеп әйткәндә, закон фикернең бер тәртип белән белдерелүен таләп итә. Фикер төп бер мәгълүм эчтәлекле булырга тиеш. Язманың, чыгышның буеннан-буена фикернең предметы бер була, сәбәпсез икенче предметка күчү аңлаешлылыкны киметә. Мәсәлән, мәктәп

директоры яңа уку елы башында беренче чиректәниләр эшләргә кирәклекне аңлатырга алына да сүз сөрешендә укучыларның җәй көне ниләр эшләвенә күчеп китә; төп предмет "онытыла", чыгышның максаты үтәлми.

Кыскасы, фикер, аның предметы һәр конкрет очракта чыгышның, язманың буеннан-буена эзлекле булырга тиеш.

Бу закон шулай ук билгеләмә, кагыйдәнамәләрнең төгәллегенә ирешүдә нигез була. Л.Н.Толстой: төшенчәләрне төгәл билгеләү һәм бертөрле куллану гына оратор белән тыңлаучы арасында тыгыз бәйләнеш булдырырга, гомумән дә, кешеләрнең дөрес аралашуын булдырырга мөмкинлек бирә, дигән.

Ә бит һәр мәгънә, төшенчә сүз белән тәгаенләнә, ә сүз күп мәгънәле, димәк, бер үк текстта, бер үк чыгышта бер мәгънәнең берничә сүз белән белдерү куркынычы бар. Чынбарлыкта шундый хәл еш күзәтелә. *Экономика – икътыйсат, шифаханә – хастаханә, квартир – фатир, тамырдан үзгәрешләр – сыйфат үзгәрешләре* һәм башка күп кенә терминның бер текстта төрлечә кулланылуы аңлашылмаучылык, буталчыклык, икелле-микелелек китереп чыгара.

**Күнегү**

Менә бу мисалларда ни өчен бердәйлек законының бозылуын аңлатып бирегез, сүз бердәйлеге булганда гына фикер бердәйлегенә ирешеп буласына тагын да мисаллар китерегез. Мәсәлән:

Җәйләүгә чыкканнан соң һәр сыердан алынган көнлек уртача *сөт* 2 килограммга гына арткан. *Продукция* узган елгыдан 1әр килограммга ким җитештерелә (Җиңү байрагы, 1900, 1 июнь);

Күптән түгел генә авылга шефлык ярдәме күрсәтү *сезонлы нигездә генә* алып барыла иде, бүген исә бу да *планлы нигездә* алып барыла (Радио, 1984, апр.). Бу мисалларда сүзләрнең синонимлыгына шик туа, кире кайтып уйланырга, ачыкларга мәҗбүр буласың;

Станциянең 500 автомашинаны газ белән тәэмин итәрлек мөмкинлекләре бар. Әмма бүгенге көндә газга эшләүче машиналар бик аз – 25–30 процент кына (Район газетыннан);

Йосыф бәк тимеркүк кара айгырын болдыр каршына ук туктатты (М.Хәбибуллин. Мирас, 1992, №6, 121 б.);

...Измә-бетон узелы узган елның октябрендә эшли башлады. Аңарчы газ-компрессор станцияләре урнашкан җирдә 2 кубометр измә-бетон ясауга ярты сәгать вакыт кирәк булса, хәзер бер автомашина измә биш минутта төяләә (Район газетыннан).

**Каршылык булмаска тиешлек законы:** бер үк предмет турындагы ике капма-каршы фикер икесе дә бер үк вакытта һәм бер үк нисбәттә дөрес була алмый. Балалар газетында бер язманың исеме: "Балалар урман һәм кыр байлыкларын саклыйлар". Ә язманың эчендә менә мондый фикер әйтелә: "Ләкин, гомумән алганда, лагерьларда табигатьне саклау эше

тиешле югарылыкта алып барылмый”. Каршылык – күз алдында. Янә икенче бер газеттан мисал: бер язма болай башланып китә: “Биредә оннан экономияле файдалануга зур әһәмият бирелә. Узган ел, мәсәлән, 130 центнер онга экономия ясала. Бу – икмәк продуктларын пешерү процессында югалтуларны һәм бракны булдырмау өчен күрелгән чараларның нәтиҗәсе...”. Шуннан соң өч кызыл юлдан ук: ”... Әмма заводта без кимчелекләргә дә тап булдык. Биредә алдынгыларның эш тәҗрибәсен пропагандалауга, технологик процесларны камилләштерүгә җитәрлек игътибар бирелми әле. Бракка юл куела (Газеттан); Мондый очракларда:

– фикернең тулы каршылыклы һәм өлешчә каршылыклы булуы ихтимал. Мәсәлән, “Туган тел дәресләрен алып баручыларның барысын да бер нәрсә борчый: методик әсбаплар юк, булса да бик аз” (Газеттан); “Нәрсәгә барып тотынсаң да, акча кирәк, диләр. Мин моның белән килешәм дә, килешмим дә” (Радиода чыгыштан);

– каршылыклы фикер еш кына уйлап җиткермәү, фикер агышын күзәтмәү, сөйләм оештыруга җавапсызлык аркасында килеп чыга: “Азнакай вокзалында ач яңаклары эчкә баткан, тешләре дә инде берән-сәрән генә калган бер бик матур әбекәй утыра. Өс-башлары традицион: башында йомшак мамык шәл, өстендә плюш жакет. Аягында тирән эчле галошлар. Урта бармагында алтын балдагы да ялтырый...” (А.Хәсәнев. С.Т., 1991, 25 июнь); “Җитезләрнең дә җитезләре гер күтәрүдә, турникта күтәрелүдә, аркан тартуда ярыша алалар” (Газеттан);

– каршылыклы фикер үзмаксат белән, ягъни кимчелекне ничек тә “яшерү” ниятеннән дә туарга мөмкин. “Колхозда быел югалтулар юк диярлек” (Газеттан); “Бу район быел түбән уңышларга ирешкән” (Телевидение тапшыруыннан).

**Күнегү**

Менә бу мисалларда фикер каршылыгын ачыклагыз, сәбәпләрен аңлатыгыз, ана теле чаралары белән төзәтү юлларын билгеләгез – фикер агышында һәр факт бер-берсенә мантыйкка ярашлы рәвештә, каршылыксыз бәйләнгән булсын:

“ Бакчада яшь үсентеләрне утырту вакыты җитте. Алмагачның ике еллыгын утыртканда әйбәтрәк. Утырту урынын алдан билгеләп, анда *кечкенә казык кагып куегыз*. Казыкның *һәркайсына* (?) бау бәйләгез, ә бауның бер очына чөй яки нык таяк беркетегез”... (С.Т., 1983, 9 май). Ничә казык соң?;

“Ул вакытта кызым тәпи дә йөрми иде әле,– ди Рәйханә,– репетициягә аны күтәреп алып барам. *Уйнап йөри-йөри дә* балакаем йоклап китә. Тулай торакка алып кайтып, аны йокларга салгач, өй эшләренә тотынам” (Газеттан);

“Шундый ямьсез хәлләр турында язган өчен укучыдан гафу үтенәм, чөнки бу татар авылларында яшәүче татар хатын-кызларына хас нәрсә

түгел. Әмма юк-юк та мондый һәм шуңа охшаш хәлләрне һәркемнең ишеткәне-күргәне бардыр. Исереклек, наркомания, тирән рухи кризис чорында, нишлисең, тормышның шундый ямьсез яклары да күбрәк ачыла шул. 70 ел буена атеистик рухта тәрбияләнгән ата-аналардан алласызлар тумыйча кем тусын? Хәзерге балалардан, оныклардан, бернинди көч-тәрбия куймыйча, югары әхлак, әдәплелек көтү биле сынган атны чабышка җибәрү кебегрәк булыр иде.

Мин еш кына өлкән буын кешеләренең узган чорны – алтмыш-җитмеш-сиксәненче елларны сагынып искә алуларын күзәтәм. Чыннан да ул елларда кешеләр рухи яктан да, матди яктан да баерак яшиләр иде. Күңелләре ачык, эчке дөньялары бай, уен-көлке күп иде”(Мәдәни җомга, 2001, 28 сент.).

**Өченченең юклыгы законы:** әгәр ике фикер бер-берсенә каршы килә икән, ике каршы хөкемнең һәрвакыт берсе дөрес, икенчесе ялган була, ә өченче хөкем булырга мөмкин түгел.

Бу закон каршы хөкемнәргә генә карый. Каршы хөкемнәр ул берсе нәрсәне булса да раслый, ә икенчесе шул ук нәрсәне инкарь итә торган каршылыклы хөкемнәр була. “Бу группа студентларының барысы да дүрт-бишкә генә укый”; “Студентларның бу группасында дүрт-бишкә генә укымаучылар да бар”. Шушы ике фикернең бары берсе дөрес була, өченче хөкемнең булуы мөмкин түгел. Өченченең юклыгы законы татарның ”Ул тумаса кыз тумый хәле юк”, дигән мәкалендә биек ачык чагыла. Өченчесе берничек тә була алмый.

Каршылыклы хөкемнәр һәрвакыт альтернативаны, ягъни берсе икенчесен инкарьли торган ике генә ихтималны күздә тота. Әгәр хөкемнәрдә альтернатива булмаса, алар каршылыклы булмый, димәк, аларга карата өченченең юклыгы законы кулланыла алмый.

Каршы фикерләрнең берсенең дөрес икәнлеге исбатланган икән, аңа каршы фикернең ялган икәне дә исбатланган дигән сүз. Киресенчә, бер фикернең ялган икәне расланса, каршысы дөрес була.

Өченченең юклыгы законы фикер йөртүдә эзлексезлеккә, сорауга җавап биргәндә икеле-микелелеккә, боргалануларга, бәхәстә принципсызлыкка каршы корал була ала.

**Күнегү**

“Һава торышы... Явым-төшем булмый диярлек” (Яңа гасыр радиосы, 2010, 11 окт.). Йә була, йә юк. Өченчесе (диярлеге) була алмый;

Сәясмәннәрнең, депутатлыкка кандидатларның сайлау алды компаниясендә барган дебатларын кабаттан укып чыгып, текстлардагы каршылыкларга игътибар итегез, мантыйкый хаталарны анализлагыз, каршылыкка китергән сәбәпләрне ачыкларга тырышыгыз.

**Җитәрлек нигез (дәлил) законы:** һәрбер дөрес фикер нигезләнгән (дәлилләнгән) булырга тиеш.

Безнең яшәештә бер генә күренеш, вакыйга да, бер генә гамәл дә сәбәпсез булмый. “Урамда сулар катып, боз пәйда булды, чөнки һаваның температурасы төште”. Нигезләнмәгән хөкемгә ышанырга ярамый, һәртөрле хорафатларга, уйдырмаларга ышану зарарлы – закон шуны кисәтә. Аралашу барышында “бу фикер дөрес, хакыйкый!” дип коры тәкърарлау җитми, һәр фикер дәлилләнгән булырга тиеш. Иң ышанычлы дәлилләр ул:

– кешелек үз яшәешендә гасырлар буена туплаган, яшәештә сыналган закон, закончалыклар, кагыйдә, нигезләмәләр (положениеләр) (алар “аксиома” дип атала: мәсәлән, суның минуслы температурада туңуы – исбатлауны таләп итми);

– үзең күргән, ишеткән, үз әгъзаларың белән тойган мәгълүмәт (“алар тугыз катлы йортның дүртенче катында яши”; “ зур бүлмәләрендә өч тәрәзә” һ.б.);

– тормыш тәҗрибәсе белән сыналып гомумиләштерелгән фикер, хөкемнәр. Алар аеруча мәкаль, әйтемнәрдә, канатлы гыйбарәләрдә тупланган була. “Киңәшле эш таркалмас”; “Атың ашамсак булса, уңдың”;

– фактлар; Аерым факт кына җитми, фактлар системасы кирәк. Сөйләүченең һәм тыңлаучының үзләренә турыдан-туры караган, алар белән аралашкан кешеләргә, коллективларга караган фактлар аеруча тәэсирле, ышандыргыч;

– фәнни мәгълүмат, кагыйдә, кануннар, принциплар;

– тормышта бай тәҗрибә туплаган тарихи шәхесләрнең (галим, әдип, сәяхәтче, җәмәгать эшлеклеләре һ.б.), алар тарафыннан популярлаштырылган герой, персонажларның хакыйкый гыйбарә, әйтемнәре, бәяләмә, билгеләмәләреннән өзекләр һ.б.

Дәлилгә мисал: “Бөтен аппарат баштанаяк үзләре кулында булганга, алар бөтен сыйныфлары белән мәмләкәтнең байлыгын суырып, һәр эшне үзләре теләгәнчә йөртүләре дә һичбер эшченең, һичбер крәстияннең хәтереннән чыкмагандыр әле. Картлар:*–Батыр белән көрәшмә, бай белән даулашма!–* ди торганнар иде.

*Чынлап та,* ул заманнарда бай белән даулашудан ни файда: мәхкәмәсе, казыйлары, чиновниклары һәммәсе алар кулында (Г.Ибраһимов. “Сарайларга сугыш... 7 т., 189 б.) (Ассызык безнеке. Ышандырыр өчен кешегә дәлил кирәк шул –таяныч нигез. Ул – абруйлы шәхес, халык, аның фикере, мәкаль, әйтеме, тәҗрибәсе; закон, кагыйдә, стандарт һ.б.– *Н.И.*)

**Күнегү**

Менә бу мисалларда фикернең ничек дәлилләнүен анализлагыз.Алар исбатлау өчен җитәрлекме; кайсы төрдән? Үзегез бу хөкемне (тезисны) ничек дәлилләр идегез?

“Концертның икенче бүлегендә бер генә (!) татар җыры да, биюе дә булмады! Менә, программа буенча санап китәм: ирланд халык биюе, япон җыры “Акатомбо”, аргентин җыры, “Боливия кичләре” исемле бию, итальян җыры, грек биюе, “Шәрык риваяте”, “Джентльментнар” биюләре, испан фламенгосы, мексика халык җыры, аргентина көтүчеләре биюе, негрларның спиричуэлы һәм концерт америка авыл биюе белән тәмамланды. Янәшәмдәге бер абый:

– Арада бер-ике чит халык биюе, җыры булганда аңлашыла әле, ләкин бу нәрсә соң инде?–дип аптырап утырды ...” (Газеттан);

“Мин Р.Фәизов фикере белән килешмим, чөнки ул фикер Карл Маркс, Ленининнардан калган...” (Радио тапшыруыннан);

“Аерылганны аю ашар”, ди халык. Бу мәкаль хәзер кулланыштан чыга башлады. Зур колхозлардан аерылып чыккан авыллар артканан-арта бара...” (Язма эштән);

“Быел кыш колхозның бәрәңгесе күп череде, чөнки узган көз явымлы булган иде (Газеттан);

“Быел юбилей елы булмаса да ветераннарны хөрмәтләячәкбез, чөнки аларның саны кимегәннән-кими бар”(Татарстан радиосы, 1999, 20 окт.).

“Моннан егерме еллар элек башкорт теленнән кергән “тәүге” сүзе әдәби телебездә сеңеп калган, чөнки безнең телебездә нәкъ шул мәгънәне аңлатучы сүз юк иде...” (Г.Хәмиди. Т.я., 1992, 22 май). “Тәүге” – татар сүзе (“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”н кара). Законның бозылуы наданлыктан.

“Быел Эстония белән Швециягә генә барулар булмаган – бу илләргә виза алу *четерекле* чөнки.” (Т.я.,2007, 22 сент.). Нәрсә ул “четерекле”; бу нинди дәлил?

“Әстерхан ягы талантларга бик бай – без бит Сөембикә ягы (Радио, 2007, 18 март). Тезисны тулысынча ышандырырлык дәлил җитәрлек түгел– дәлилләр системасы сорала.

Мантыйкта истишһад дигән төшенчә бар: 1) шаһит булуны таләп итү, шаһит итеп китерү, шаһит ясау, 2) исбат өчен дәлилләр, цитаталар китерү.

Латин графикасына кире кайту турында бәхәсләрдә, мәсәлән, дәлилләр күп китерелде (төрки телләр бердәйлеге һ.б.), тик төп дәлил читтә калдырылды – татар теленең асылына, аның законнарына ярашлы булу-булмавы;

Дәлилне көчәйтә торган чаралар: *“Сүз дә юк”, “Шуны да искәртәбез”, “Шулай булгач”* һ.б. (“Телевидение тәрбияләргә тиеш” язмасында. В.Т., 2001, 15 сент.).

*Күренгәнчә*, мәктәп тормышына кагылышлы әлеге мәкалә күпләрне битараф калдырмаган. *Димәк*, анда бүгенге көндә бик актуаль булган мәсьәләләр күтәрелгән. (Т.я., 1990, 29 март). Ассызыкланган чараларның урынлымы-юкмы икәнен ачыклагыз;

Тексттан тезисларның җитәрлек дәлилләнмәгән булуына мисаллар китерегез:

“ Кайбер югары уку йортларында имтихан бәяләре 3 меңнән 18 меңгә хәтле менә. Әнә инженер һөнәрен үзләштереп йөргән Илнар бирә алмый чыккан имтиханын 12 меңгә сатып алган. “Үзем эшләп алган акчам (?) булгач, жәл түгел инде. Укыйсы килми бит. Укымыйча да булмый , диплом кирәк. Хәзер имтихан сатып алмаган студент юктыр инде ул. Булса да йә ул бер “ботаник”, йә блатлы студенттыр. Гомумән, минем дусларымның да күбесе ришвәт белән дус. Бүген ансыз дөнья бармый”, ди ул.

Чыннан да, бүгенге көндә укуның күп өлеше ришвәткә корылган. Зачет кенәгәңне яхшы билгеләр белән бизәр өчен белем түгел, акча кирәк. Эшләп табасыңмы, әниеңнән аласыңмы, кеше талыйсыңмы – укытучының анда эше юк. Студент.” (Т.я., 2007, 29 сент.)

“Кызлары белән бер апа безнең подъезддагы танышларына кереп бара. Почта әрҗәсенә карады да әйтте: газетлары алынган, димәк, өйдәләр.” Ай-яй, хатын-кыз мантыйгы– бүген бит ял көне, почта килми; аннары, сәгать унике, ә бездә почтаны иртүк алмасаң, караклар алып китә...

Софизмнар турында уйланыр өчен мисал:

“Судья дәгъвачыга: –Гаепләнүче сезне шыр тиле дип атады – шул дөресме? Дәгъвачы: – дөрес. Судья: Дөрес булгач, нигә кешене тиңтерәтәсез? (Т.я., Көлдергечләр).

**Исбатлау кагыйдәләре**

1) Тезис ачык мәгълүм тезис булырга тиеш;

2) Исбатлауның яисә текстның бөтен дәвамында тезис бердәй булып калырга тиеш (Сезонлы – планлы мисалы);

3) Тезисны раслау өчен китерелгән дәлилләр (аргументлар, нигезләмәләр) шик калдырмый торган, дөрес булырга тиеш (Казыклар мисалы);

4) Дәлилләр (аргументлар) тезис өчен җитәрлек нигез булырга тиеш;

5) Дәлилләр – дөреслеге мәстәкыйль рәвештә, тезиска бәйсез рәвештә исбатланган хөкемнәр булырга тиеш (Бәрәңге черү мисалы).

Дәлилләү, дәлилләнү белән бәйле янә кайбер закончалыклар:

– дәлилләк аеруча билгеләмә, кагыйдәләрне бәян иткәндә, төшенчә-терминнарны аңлатканда көчле, ышанычлы булырга тиеш. Тискәре мисал: “Китап – ул каты тыш белән беркетелгән мәгълүм бер кәгазь битләре. Брошюра – ул йомшак тышлы китап яисә журнал”. Брошюра китап булып чыга, ә бит, китап каты тышлы, дидек;

– дәлилләр белән тезис арасында буталчыклыклар, аңлашылмаучылыклар: ышандырмый торган, шик калдыра торган аргумент, фактлар (“Бөтенләй юк диярлек”);

– дәлилгә берничә факт китерелә дә исбатлаганда, нәтиҗә ясаганда берсенә генә нигезләнә;

– берничә факт, дәлил бирелгәндә алар үзара мәгънәви тәңгәл булмый; сорау, ризасызлык туа;

– дәлил яисә фактның эчтәлеге сүз сөрешендә үзгәрә, хәтта кире кагыла – каршылык барлыкка килә;

– сәбәп –максат мөнәсәбәте буталчык була, ярашмый;

– каршы куюю дөрес булмый: Коммунист Мөхәммәтев ат үрчетү белән генә шөгыльләнми, ул әле уңган партия һәм җәмәгать эшлеклесе дә;

– дәлил яисә факт әйтеп бетерелми, аңлашылыр дип уйланыла. Яисә мәгънәви тулы булмаган, өтек факт, дәлил китерелә; Әйтеп бетермәү; мәгънәне өлешчә генә белдерү (Дербышкида бер реклам: *сату* үзәге дип аталган, сүз бит *сәүдә* турында бара);

– бөтен белән өлеш нисбәте сакланмый;

– сүзгә басым дөрес төшми;

– сүз (җөмлә кисәге) җөмләдә үз урынында түгел;

– текстта мәгънәдәш берәмлекләр эзлеклелеге сакланмый. Бу таләп, гадәттә, сүзләргә генә карый дип күнегелгән. Барлык берәмлекләргә дә (иҗекләргә, сүзтезмәләргә, контекстуаль синонимнарга да карарга тиеш). "КПСС тарихы"н тәрҗемә итеп чыгарганда аны берничә тәрҗемәче редакцияләгән иде: китапның беренче өлешендә фигыльләрнең үткән заман рәвеше *-ды/-де,* икенче өлеше *-ган/-гән* кушымчасы белән тәгаенләнгән иде. Китапны өр-яңадан редакцияләп чыгарга туры килде. Сайлау компаниясе вакытында матбугатта бер газет *сайлау* дип дөрес язып, башкалары *сайлаулар* дип ялгыш язып укучысының башын катыра; *каникул* дип тә, *каникуллар* дип тә язуга күпме бала аптырый икән!

– бәйләү чараларының урынлы булмавы да еш кына мантыйксызлыкка китерә.

**Мантыйкый анализ алымнары**

– анализның башка төрләре кебек үк мантыйкый анализ да ике операциядән тора: 1) текстны өлешләргә бүлергә һәм бүлекләрнең бер-берсенә ничек, нинди чаралар белән бәйләнүен, ягъни сөйләм берәмлекләренең (фикер берәмлеге дип тә атарга була) бер-берсенә һәм текст эчендәге, шулай ук текст тышындагы төшенчәләр белән бәйләнешен ачыкларга;

Бу бәйләнеш менә киләрдән гыйбарәт:

– янәшә фикер өлеше белән; – ерактагы фикер өлеше белән бәйләнеш; чаралары – бәйлекләр, мөнәсәбәтле берәмлекләр (*шуңа күрә, шунлыктан, димәк, кыскача, йомгаклап әйткәндә, менә ни өчен, күрәбез ки, минемчә, ләкин* һ.б.), интонация, тыныш билгеләре һ.б.;

– текстны тулаем бер бөтен итеп күз алдында тотарга кирәк. Бер аерым өлештә фикер агышы тыгыз бәйләнештә булып та, икенчесендә, бигрәк тә соңгы (азакгы) өлешләрдә бәйләнешнең таркаулануы ихтимал, хәтта юньләп бәйләнмәгән таркау өзекләргә әверелү куркынычы бар. Ерагайган

фикер өлешләрен “якынайту” чаралары да табыла: *бая әйтелгәнгә кире кайтабыз; кире кайтып әйткәндә* һ.б.

Текстта фикер агышы бөтеннән өлешкә яисә өлештән бөтенгә таба бара. Һәр тезис катгый дәлилләнгән, бәхәсле тезислар исбатланган булырга, азактан дәлилле нәтиҗә ясалырга тиеш.

**Тулаем текст төзелеше белән бәйле мантыйкый кимчелекләр**

–текст агышында сөйләмдә эзлеклелек җитмәү: игътибар өзелә, сорау, аптырау, ризасызлык туа;

– фикер башлана да, бүлгәләнә, очына чыкмыйча ташлана, чөнки төп темага үтемле чара белән бәйләнеп бармый; тема эчендә фикер өлешләре очы очка ялганып бармый, каршылык, буталчыклык, икеле-микелелек хасил була;

– композиция кимчелекләре аркасында фикер эзлеклеге бозыла: фикер өлешләре күнегелгән чаралар белән бәйләнми, ят, ясалма бәйләгечләр фикер агышын өзгәли (*Миңа калса*; *Әмма дә ләкин*; *әйтергә кирәк таптым әле* һ.б.; Яисә текст агышы озакка сузылачак чигенешләр белән өзгәләнә *(“Чигенеш ясыйбыз; туктап, шуны искәртик; Ә-ә-ә, искә төште бит әле һ.б.*). Дөрес, текст агышында өзеклек *(“Бүленгән идек”, “Хәтерлисездер”, “Түбәндә (югарыда) әйткәнебезчә* һ.б.) төрле искәрмәләр белән ялганып китә ала, тик мондый искә төшерүләр “онытыла”, сирәк була. Шуңа күрә фикер агышы өзелә, туктап, уйларга, кире кайтып укырга мәҗбүр буласың. Ярый ла текст язмача булса. Ә радиода...;

– фикер өлешләре эчтәлеге ягыннан да, төзелеше (композициясе) ягыннан да бер күләмлерәк, бер типтагырак буыннардан торырга тиеш.

Менә бу мисалларда **гомуми белән өлеш (бөтен – өлеш) нисбәтен** күзәтик.

*Тышта яз. Язгы кыр эшләренә хәзерлекнең иң җаваплы көннәре. Механизаторлар кар сулары тотуга кереште...”.* Автор эчтән торып күзәтә кебек: *“тышта яз”* – өлеш. Ә язгы эшләр барысы да тышта бара, димәк, төп эчтәлек – гомуми (Октябрь юлы, 1982, 20 март);

*Быел алтынчы классны тәмамлаган төпчекләре – Әмин икән бу. Хәзер йорт аның кулында* (гомуми). Көтүдән мал-туарны каршылау, каз бәпкәләрен карау *да* (өлеш) аңа йөкләнгән. Әле әнисенә булышырга *да* (өлеш) вакыт таба. Аның өчен каравылда *да* (өлеш) тора”. (Т.я., 1989, 28 июль). Ә кайда соң гомуми? Гомумине белдергән тезис дәлилләнмәде бит.

Иген кырларында *комбайннар* һәм *машиналар* гөрелтесе яңгырый (Алга, 1989, 20 июнь).

**Эчтәлек белән бәйле мантыйкый кимчелекләр**

Башлыча ике төр төп кимчелекне төркемләргә була: **мәгънәви төшенчә белән бәйле кимчелекләр һәм фикер агышы белән бәйле кимчелекләр.**

**Төшенчә белән бәйле кимчелекләр**

– Мәгънә белдергән төшенчә аңлашылып бетми яисә авыр аңлашыла; озак, кабат-кабат укып, уйлаганнан соң гына аңлашыла, мәгънә төсмерләре ачык булмаганга, буталчыклык, икеле-микелелек, артыклык (тавтология), томанлык килеп чыга**.** Сәбәпләре: а) нәкъ фикерләнгән мәгънәгә тәңгәл төшенчә үзе дә, шуны ачык күзалланган тел чарасы да (аваз, иҗек-кушымча, сүз, сүзтезмә) эзләп табылмаган. Мәгънә белдерә торган төшенчәне без гадәттә сүз дип күнеккәнбез. Дөрес үк түгел. Мәгънә (морф) белдерүче берәмлекне **аваз, иҗек**ләрдән үк башларга кирәк: "Буяган мыек*лы*ларга ышану кыен икән" (Җырдан). Дөресе: *мыекларга. Әтнәләр, Казаннар, Чишмәләр ...*– мәгънә төгәллегендә бернинди шик юк. Г.Тукай: "Тотса мәскәү*ләр* якаң"...;

*-лар/-ләр, -лы-/-ле* кушымчаларының агрессив тавтологиясе, уртаклык кушымчасы *-ыш/-еш*нең һ.б. кушымчаларның урынлы-урынсыз кулланылуы хаталарга еш китерә: тапшыру азагына якын*лаш*ты (*якынайды* урынына), *аңа* (*аңарга* урынына) ничә яшь *микән (икән* урынына): Көрәш*тә* катнашу (көрәш*кә); Кәримулла*га бурычка кирәргә туры килде (Кем кемгә бурычка керде?); Сизмәс, немец шпионы эләктергән Хәлим диләр аны! (Кем кемне эләктергән): "Казанның Северный бистәсендә яшәүче бер ир-атны эт (*этне*ме?*)* җәберләгәне өчен хөкем итәчәкләр (Т.я., 2009, 22 сент.); Биредә туй күлмәк*ләре* кигән 50 хатын-кызны күрергә мөмкин иде (Шунда ук); Аңлашылмау, буталчыклык бер аваз (хәреф), иҗек аркасында!

**Күнегү**

Мәгънә төгәлсезлегенә сәбәп булган кушымчаларның урынсыз кулланылуына игътибар итегез: "Үзебез дә эштә хәзер көннәр буе күрше кабинетларда утыручы хезмәттәшләребезне күрмәскә мөмкин*без* (Шунда ук). Күрмәвебез ихтимал мәгънәсендәдер; " ...Ә пенсионерлар һәрбер тиен*нәр*ен санарга мәҗбүр*ләр*" (Т.я., 2010, 29 май); "Кызыбыз Зөлфиягә өч яшь. Ул һәмма балалар кебек рәсем ясарга ярата. Бүген песи төшергән. Песие өч кенә аяклы.

– Бер аягы *кая*? –дип сорыйм аңардан.–Дүртенче аягы юк бит!... (Айдар Хәлим. Т.я., 2007, 8 сент.). *Кайда* урынына. Бәлки "кая киткән?" дип язгандыр да редакция хезмәткәре ялгыш кыскарткандыр, дип авторны аклыйсы, наданлыгына күз йомасы килә.

"Нәрсә мәҗбүр итә безне урла*шырга*?" ("Татарстан" радиосы, 2009, 3 март). Дөресе: *урларга;* Ялгыз картны үлгәч 10 көннән соң гына җирлиләр. Мондый битарафлык факты белән алар (милиционерлар) әле беренче тапкыр гына очра*ша* (В.Т., 2001, 27 окт.); Сезне кайчан күрергә мөмкин *микән*? (Студентның зачет куярга рөхсәт сорау язуы).

"Агрессив" кушымчалардан тагын: *-лык/-лек (*вакыт *аралыгында*).

Уйланыр өчен сорау: Күпиҗеклелек – уңай күренешме? *машиналаштырылды; индустрияләштердегезме; көрәштәшләребезнең; котылгысызмыни; кешелеклелек* (Мисаллар В.Хангилдиннан, 39 б.).

Күплек кушымчасының парлы сүзләргә (эчтәлегендә үк күплек мәгънәсе салынган сүзләргә) өстәлү бөтенләй гайре табигый: явым-төшем*нәр* *(*Радио, 2010, 2 май); *Азык-төлек* кими барган саен илгә күбрәк сугыш кирәк-ярак*лар*ы таләп итељ (Т.я., 2007, 22 сент.). Бу төр хата аеруча еш кабатлана. Күплек кушымчасын куллануга махсус күнегү үткәрик әле.

Сөйләм берәмлегендә (җөмләдә) күплек төшенчәсен белдергән бер берәмлек булса, башка берәмлекләргә ул мәгънә төсмерен белдерә торган кушымча ялгау мәҗбүри түгел, өстәлгән очракта ул мантыйкый хатага санала: Кайбер ведомство*лар*ның һәм предприятие*ләр*нең җитәкчеләре катнашты (Радио, 1992, 26 сент.). *Кайбер*гә – берничә мәгънәсе салынган бит инде!

Шул ук вакытта күплек чарасын урынлы куллану очрагын тоемларга күнегергә кирәк: Өй түбәләрен хәзер күбесенчә шифер, калай белән яба*лар*, яңа йортларны берничә бүлмәле, алты почмаклы итеп сала*лар*, тәрәзәләрне зур итеп уя*лар*. Монда -*лар* күплек мәгънәсен бирер өчен түгел, гомуми фактны хәбәр итү чарасы (*ябыла, салына* мәгънәсендә).

“Тик сөенечләре көенечкә әверелде. Инде юлга чыгарга тәмам җыенып беткәч, Сәвия ханым кырт кисеп, әлеге уеннан кире кайтты, билгеләнгән көнне юлга кузгалмады*лар”* (ия билгеле булмаганга, дөресе, грамматик белдерелмәгәнгә күрә хәбәр күплектә; әгәр ия *алар* яисә *гаилә* дип белдерелгән булса, хәбәрдә күплек булмас иде. Мирхәт Хөснимәрдәнев аны гына тоя торган журналист иде (С.Т.,1990, 30 март).

Шулай да -*лар*га бихисап өстәмә мәгънә (хәтта хис-тойгы) төсмере салына:

– өстәмә факт, мәгълүмат төсмере бирә:– Әйдә, кызым, үзебезгә кайтыйк, абыең*нар* аргандыр, йокласыннар, диде Рәхилә. Димәк, абыйсы үзе генә түгел, аның белән тагын кемдер бар;

– гадәттә артык -*лар* ныгыган берәмлекләрдә әйтелми, ә ирекле берәмлекләрдә, бигрәк тә спонтан әйтмә сөйләмдә “өстәлә”: ... Бозау*лар* һәм сыер*лар* торак*лар*ын төзүдә... (“Татарстан” радиосы, 1983, 18 май). Язуда инде ул “*бозау һәм сыер тораклары”* булыр иде;

– тыңдаш кисәкләрдә мәгънәви кабатлау фикер агышында ук кисәтелә: Шулай инде, дөньяның, мәсәлән, кош*лар*ыннан вә хәшәрәтеннән генә дә акыллы кешегә гыйбрәт алырга мөмкин (Г.Тукай, 181 б.).

– “ия күплек булып, хәбәр гаиб өчен булса, хәбәрнең күплек тә, берлек тә булып килүе ярый: Былчыракта яңгыр артыннан бала*лар* йөгерешә, кычкыра*лар*: “Җиргә, дип, алтын төшә, алтын төшә”. (Г.Ибраһимов).

Күплек кушымчасының хис-тойгы белдерү чарасы буларак кулланылуын күзәтергә, нәтиҗәләр ясарга күнегергә кирәк. Бу очракта да төрледән-төрле төсмерләр күзәтелә. Кайсы сүз төркеменә бәйләнүе дә әһәмияткә ия:

– гаҗәпләнү хисе: Атның акылына, этнең зиһененә, мәченең үткенлегенә шак*лар* катабыз (Т.я., 1922, 30 гыйнв.); тантана, пафос: “ Шул ук вакытта дин*нәр*ен һәм исем*нәр*ен алыштырган йөз меңнәрчә татар*лар* арасыннан

бөек кеше*ләр* үсеп чыкты*лар* (Р.Хисмәтуллин. Таң йолдызы, 1990, 27 февр.); әрнү, борчылу: Әрнемәче йөрәккәем, бер генә минут*лар*га (Җырдан); Савиново сазлыгында яшәүчеләрнең череп беткән насыйпушкаларын күргәч, утырып елыйсы*лар* килә (Аваз, 1990, №1-2); Соклану: "Менә сиңа мә! Тукай иҗатының тарихилыгы әлеге шигырьнең һәр строфасында ярылып*лар* ята! (М.Мәһдиев. Мәгърифәт, 1993, 20 ноябрь); Хисси нечкәреп китү: Ә Семен бигрәк*ләр* дә күңел*ләр*не айкап, иң нечкә кыл*лар*ны тибрәндерерлек итеп уйный инде (Коммунистик хезмәт өчен, 1990, 8 март); Конкретлаштыру: "Ике илнең җитәкче*ләр*е кабат очрашты*лар* ("Татарстан" радиосы, 1991, 17 апр.). Иядә күплекнең мәҗбүрилеге, рәсмилеге хәбәрдә дә кабатлауны сорый; "Хатны почта аша йөртмибез, озак йөри, аннан ачып укырга да мөмкин*нәр*. Без хатны икебез генә белә торган урынга, *алар*ның бакча башындагы багана куышына куябыз" (Т.я., 1991, 3 окт.); Төрттерү: Күрше егет*ләр*е кергән икән, күрми дә торам... (күршенең бәләкәй малае кергәч);

– "сөйләү телендә фигыльне күплек формада алу эш яки хәлнең артык күп яки артык еш кабатлану очрагында күренә (Х.Курбатов): Бала (йөгереп керә): Апа, әнкәй хәзер кайтсын, диде, өебезгә атлы казаклар керде*ләр*.

– рифма, ритм максатында: Әгәр шатлык, бәхет килсә//Хәзер*ләр*сез бүләргә сез (Г.Тукай)

"Мусаның шигырьләре дә, гомер узган саен, заман сулышы белән чыныккан саен, тагын да көчлерәк яңгырый*лар*, шагыйрьнең мәңге сүрелмәс кайнар хисләре, шигырь юлларына тезелгән ялкынлы сүзләр булып, тагын да яктырак балкый*лар*" Урынлыдыр, чөнки ия хәбәрдән ерагая, арага башка бөтен бер кисәкләр керә;

"Әти-әни*ләр*гә булышабыз". Парлы сүзләр күплекне белдерә, аларга күплек кушымчасы ялганмый, дисәк тә монда бер гаилә "күплеге" генә түгел, бөтен-әти-әниләр дә гомумиләштерү мәгънәсе салына.

"Авыл халкы малын көтүгә чыгармый" ("Авыл кешеләре" диелгәндә бала һичшиксез чыгармыйлар, дияр иде. Ә бит мәгънә үзгәрмәде. Сан белән белдергәндә -*лар* бөтенләй соралмый бит (мең кеше, йөз бала), димәк ки, күплек кушымчасы ул эчтәлекне белдерми, форманы гына. Шулай да татар фикерләвендә төгәллек таләп ителгәнгә, шуңа күнегелгәнгә -*лар* өстәлергә генә тора: мантыйк форманы "җиңә": "Аларның һәркайсы аккордион*нар* белән бүләкләнде" (Радио, 1993, 30 дек.)– барысына бер аккордион биргәннәр дип уйлап хаталанмасыннар дип мәгънәви тавтологиягә дә риза татар. Бу бигрәк тә рәсми фикерләүдә (документальлек өстен торган) күзәтелә: "Депутат*лар* күп санлы сорау*лар*га җавап*лар* бирде*ләр*.

## Күнегү

Менә бу очракларда күплек кушымчасының урынлымы-түгелме икәненә анализ ясагыз:

–Борыңгы әби-бабаларыбыз казны бик яраткан*нар* (Календарьдан);

–Әле кайчан гына гипнозчы*лар*га, сихер-тылсымчы*лар*га шик белән карый идек. Ә бүген инде аларны могъҗизачы*лар* итеп саныйбыз.

Тиңдәш кисәкләрдә кушымчалар кабатланмый: Узган дүшәмбедә муниципаль район башлыгы З.Гарәфиев производство бүлекчә*ләре* җитәкче*ләре*, шәһәр һәм авыл җирлек*ләре* башлык*лары* белән киңәйтелгән киңәшмә үткәрде (Идел таңнары, 2009, 11 сент.); "...Сыраны да ларек һәм киоскларда сатуны тыярга мөмкин*нәр* (Т.я., 2009, 22 сент.);

Кушымчалардан кала мөнәсәбәтле сүзләр, аерым алганда ярдәмче фигыльләр, дә мәгънә төгәлсезлегенә сәбәпче була: "Барлас Камалов үзенең очеркында чыннан да анкетадан ерак *китә,* Зөфәр Садретдиновның кабинетыннан *чыга алмаган* " (Ш.Бикчурин. К.у., 1978, №3, 156 б.); "Соңгы тапкыр күрешкәндә Барый ага бераз авырып *киткән* иде "(Алга, 1987, 22 сент.).

Минеке *бул гына* (Җырдан). "Минеке генә бул"дыр?

**Мәгънә төгәллегенә ирешү өчен сүзләрне дөрес куллану**

– Каршылык төсмере сизелә: Новгород сазлыгында үлемен *тапкан* солдатлар... *Эзләгәндә* генә табып була. Солдатлар үлемне, әлбәттә, эзләмәгән ("Татарстан" радиосы, 1990, 14 май); Сугышка ул 41нең җәендә үк китә. Бөек җиңү көнен Кенигсберг шәһәрендә *каршылый* (Т.я., 1984, 28 июль);

– нәкъ шушы сүз табылмаган: " Безгә тагын да активрак булырга кирәк әле,–ди Лилия.

–Ә кибет булырмы соң?– дип сорыйм *аннан* (Җиңү байрагы, 1989, март). Беренчедән, мәгънә артыклыгы – сорау интонациясе (тынышы) булгач, "сорыйм" сүзе артык – мәгънәви тавтология; Икенчедән, "аннан" сүзе омоним (ике мәгънәле) берәмлек булганга, аңлашылмаучылык тудыра: "аңардан" (кешегә карата "аннан" шулай әйтелә) дип тә, "аннан соң" дип тә аңларга була; Каурыйлары җиргә ява//Җыям каз мамыкларын (Җырдан). Нәрсә җыя каурыймы, мамыкмы – икесе ике нәрсә бит; "Өзәм сиңа *гөл*ләрнең матурларын" (Җырдан). Гөлне өзмиләр, гөлнең *чәчәген* генә өзәргә ярый.

Барлык ишек алдын шартлатып, хатыны кер *юа* (Т.я., 2007, 22 сент.). *Уа.*

*Спектакль – театр* (Иртәләрен – репетиция, кичләрен *театр*) (Яңа гасыр радиосы, 2009); *Образ – персонаж* (Күп төрле *образларда* уйнаган кеше (Яңа гасыр радиосы, 2009); *Мәктәпне бетерде – тәмамлады* (Мисаллар И.Фәйзрахманов күзәтүләреннән); *Вокзал – станция:* Питрәч районының да шактый гына хуҗалыклары Краснодар краеннан салам җыйды. Хәзер шул тюкларны машина белән тимер юл *вокзалына* – вагоннарга ташырга кирәк". *Станциягә*дер? (газеттан);

– телдә мәгънәгә тәңгәл берәмлек табу җиңел эш түгел, чөнки мәгънәдәш берәмлекләр (синонимнар) бихисап, мәгънә төсмерләренә бәрабәрен генә сайлап алу зур осталык таләп итә. Әйтик, әдәби берәмлек урынына диалектизм берәмлек куллануның да мәгнә төрлелеге китереп чыгаруы ихтимал. “Бәрәңге ипие бик тәмле, искерми һәм *тазартмый* (әдәби сөйләмдә – *симертми)* (Календарь, 1985, 21 март); “Әбиемнең булган байлыгы берәрдән артмый: бер кәҗәсе, бер эте, бер мәчесе, күп булса бер капчык *игене* булыр” (Яшь ленинчы, 1988, 17 февр.). Бу контекстта әдәби сөйләмдә – *ашлык яисә бөртек*;

Әлеге төгәлсезлекләрнең сәбәбе: шушы контекстта уйланган төшенчәгә тәңгәл берәмлек табылмаган - автор бу төшенчәне бер сүз (берәмлек) белән, ә укучы икенче сүз белән уйлый; Яисә автор төшенчәнең мәгънә төсмерен белеп бетерми: “Ара-тирә Мөхәррәм абыйга күз салам. Сөйләшкәндә маңгаендагы сырлар ул үткән авыр тормыш тарихын сөйләгәндәй *чокырланып* китәләр” (С.Т., 1984, 10 июнь);. Сыр сызык рәвешендә, озын яисә кыска, ә чокыр түгәрәк;

– мәгънәдәш берәмлекләр (синонимнар) арасында нәкъ тәңгәле – саф татарчасы табылмаган: Яулык *киеп* йөрүче кызлар (дөресе: *бәйләп, бөркәнеп, ябынып)* (“Татарстан” радиосы, 2010, 15 сент.); Бакалыда һәр җирдә хуҗасыз йөргән этләрне очратырга була, алар берәмләп тә, *кумәк* тә йөриләр (*өерләп, өер белән)* (Коммунизм байрагы, 1989, 1 авг.);

– татарча берәмлек урынына калька (ярым калька) кулланыла: Мин яңа форматта чыгучы “Сөембикә”нең яшь хатын-кызларны күбрәк җәлеп итүен, бүген гаиләне, җәмгыятьне борчыган мәсьәләләр турында ачыктан-ачык сөйләвен *теләр идем*. (Дөресе: *телим).* (Сөмбел Галиева. Сөембикә, 2009, №9, 10 б.); “Элек зират булган әлеге паркны мондый ташландык хәлдә тотмаслар, чистартырлар дип *өметләнәсе килә* (дөресе: *өметләнәм*) (Т.я., 2009, 15 окт.); “Хәзрәткә менә мондый сорау *бирәсем килә*” (“Татарстан” радиосы, 2010, 12 июнь). Кичә яисә моңарчы сорау бирәсе килгәндер, ә бу мәлдә ул инде сорауны *бирә*. Шул ук тапшыруда, шул ук мизгелдә хәзрәт тә: менә нәрсә *әйтәсем килә,* ди. Үзе инде *әйтә*. “Алга китеп булса да шуны да *әйтәсем килә,* гадәттә, ир-егетләр сәхнәгә менәргә бик атлыгып тормыйлар”.

Авторның авторитетлы булуы еш кына редакторның сизгерлеген томалый. Менә Илсөяр Хәйруллина текстында киткән калькалар: *Бүгенге көндә*; Заман таләпләреннән *чыгып;* Әлегә кадәр РАО-ЕЭС белән үз арасында беркадәр ара*лык* калдырган... (В.Т., 2008, 28 июнь).

“Татмедиа” материалларында калькалар аеруча еш очрый: *Зур боздан* башка булмый; Европага *тәрәзә уйдык* һ.б. (Әтнә таңы, 2009, 9 окт.).

Кабат-кабат кисәтелгән калькалар да кабатланып тора: Дәү әниләрнең беренче оныклары. Барлык туганнарны, дусларны диярлек олы *табын артына* (дөресе: *табынга*) җыеп, Яшел Үзәндә бик зурлап туй үткәрделәр (Т.я., 2007, 29 дек. Н.Сафиуллина); Җитмәсә, инде *алда ук әйткәнемчә,* “шаккатаризмнар” да бар иде (Т.я., 2008, 19 гыйнв.). Үткән заман *артта*

була, ә *алда* түгел; “хезмәт *баскычында үсеш*”: “Зуррак *баскычка* күтәрелү”; “югарырак *баскычка* үрмәләү” (Т.я., 2007, 29 дек.); “түгәрәк дата” – “түгәрәк бәйрәм” (Шунда ук); фәлсәфи *күзлектән карый* белүче; *акча күзлеге аша карарга* өйрәтүче (М.Сәфәрев. В.Т., 2007, 10 окт); инфляция күләмен шул яңа бәяләрдән *чыгып* исәпли башлыйлар (Т.я., 2007, 29 дек,); Күчерелмә мәгънәле берәмлекләрдән дә калькалар ясала: *портфель бүләләр; бәяләр кинәт сикерде; түбә белән тәэмин итү; йомшак итеп әйткәндә*; усалрак *“тешләүгә”* кайтып кала (М.җ., 2007, 28 дек.).

Пароним, омоним, антонимнарны урынсыз куллану да төгәлсезлеккә, мәгънә китеклегенә сәбәп була: *Кече – кечкенә* (Сөйгәне үзеннән 8 яшькә *кечкенәрәк)* (Т.я., 2007, 22 сент.) Дөресе: *кече.*

– омонимнар белән язганда һәм әйткәндә “колак торырга тиешле” сүзләрдән, мәсәлән, *бер*: “Ә монда кичке җиделәрдә басуда *бер* трактор да калмый (Коммунизмга, 1977, 3 сент.). Биредә *бер* сүзе сан түгел, киресенчә, гомумилекне көчәйтү чарасы (бу очракта *бөтенләй* мәгънәсендә);

Төгәллеккә ирешүдә **алмашлыкларның** төсмерләрен нечкә тоемлау әһәмиятле: “Безнең Теләче Тамак урта мәктәбендә дә укыту-тәрбия эшендә техник чаралар кулланыны камилләштерү укытуны кабинет системасына күчерү белән бергә алып барылды. *Анда* 19 кабинет бар...” (Календарь, 1985, 17 авг.). *Монда* алмашлыгы төгәлрәк булыр иде.

Аеруча **атамаларның, терминнарның бермәгънәле булырга тиешлеген** истән чыгармаска кирәк. Терминнарның синонимы булырга тиеш түгел: “Олы яшьтәге бер ана үзенең шатлыгы белән дә уртаклашмыйча түзә алмады:

– Сез безнең хатын-кызлар турында языгыз. Алар арасында тракторчылар да, *металлны эретеп ябыштыручы һәм кисүчеләр* дә бар” (С.Т., 1979, 18 дек.). Кемнәр болар? Терминнар рәсми кабул ителгәнчә түгел, җитмәсә әле туры сөйләм эчендә. Гайре табигый килеп чыккан, тиз аңлауга комачаулый. (*шифаханә– сырхауханә, квартир–фатир* вариантлары текстта бер үк мәгънәдә кабатлана. Менә дөресе: “Миндә *фатирда* ике кыз тора. Шундый тырышлар, тәртиплеләр” (Т.я., 1989, 17 авг.). Бу ханым үзенең квартирына кызларны фатиргә керткән. Аерма шунда: хуҗа квартир хакын дәүләткә түли, ә кызлар – аңарга, фатир хуҗасына түли; термин белән гомуми (битараф) берәмлек бутала, бер-берсеннән аерылмый (*аш пешерүче – пешекче, сыер савучы – савымчы* һ.б);

– **туры мәгънәле берәмлекнең күчерелмә мәгънәлесе** белән дөрес нисбәттә булмавы, бер-берсен сәбәпсез, урынсыз алмаштырулары: “Киров исемендәге хуҗалыкның Эзмә авылында төзелгән җәйге лагерь ун елга якын инде мул *сөт чишмәсен* хәтерләтеп тора. *Чишмәнең* чыганаклары: мул үлән участоклары, яшел конвейер да якында гына. Өсте ябулы лагерь

терлекләрне көз ахырына кадәр биредә тотарга, ә салкын *чишмә* юлына ясалма сөт суыту урыны... сөтнең сыйфатын сакларга мөмкинлек бирә (Хезмәт байрагы, 1985, 25 июль); “Советлар яңа сайланган депутатларны укытуга, аны тормыш белән, алда торган бурычлар белән бәйләп оештыруга аеруча игътибар итәргә бурычлы (Коммунизмга, 1990, 1 март). Күчерелмә мәгънә берничә баскычта үзгәрә: хосусыйдан – иҗтимагыйлыкка: *бурыч әҗәт* мәгънәсеннән *бурыч – үтәләсе иҗтимагый эш*. Бу мисалда ике *баскыч* очрашкан, аңлашылмаучылык килеп чыккан.

“Күп кенә балалар үзләре теләгән түгәрәккә йөрүдән мәхрүм, шунлыктан яңа Третьяклар, Харламовлар, Дасаевлар калкып чыкмый.” (Т.я., 2009, 20 окт.). Күчерелмә мәгънә әле туры мәгънәдән тәмам ерагаймаган. Баткан очракта гына *калка* дип әйтергә була;

– сөйләмдә әйтелеше, яңгырашы, аһәңе татарча булмаган (басым, сингармонизм законына җавап бирмәгән) берәмлекләр (алынма варваризмнар, шагыйрьләрдә: *о-о-о* һ.б.);

– **язу белән әйтү арасындагы аерманы тоемламау**, орфография һәм орфоэпия кагыйдә, нормаларын сакламау: *Свердловск, Алексеевск* (“Татарстан” радиосы, 2009, 11 сент.); *Икесе генә* калганлыгы билгеле булды (С.Т., 1986, 15 авг. И.Хәйруллина) Төн уртасы узып бара. Берничә хатын-кызның, бөтен урамны ярып, *әче* тавыш белән “Эй мороз, мороз”ны җырлаганы ишетелде (Т.я., 2007, 22 сент.). *Ачы* урынына. Монда сингармонизм законының сакланмавы зарар китерә – фраза аһәңе бозыла.

**Фикер агышына бәйле кимчелекләр**

**– фикер агышы эзлекле түгел:** фикер төртелә; аңлап бетермәү, аптырау туа: Сәбәбе нидә? а) сөйләм барышында төшенчәләр рәтендә мәгънә күләме сөйләм максатына (ниятенә) тәңгәл нисбәттә сакланмый – әйтик, тиңдәш кисәкләр мәгънә күләме ягыннан бер күләмдә булырга тиеш; менә бу мисалда ул сакланмаган: “ Биектау станциясеннән тәүлек буена ерак араларга баручы, шәһәр белән ике арада йөрүче, йөк төягән составлар узып тора” ( Ильич юлы, 1987, 14 гыйнв.). “Йөк төягән составлар” ерак арага да, якынга да йөрүе ихтимал бит; Бер рәт төшенчәләренең нисбәте сакланмавы да шушы төр кимчелеккә карый – без аларга махсус тукталдык; ә) тәртипкә (системага) киная ясалып та, сөйләм барышында **санау тәртибе, эзлеклелеге** сакланмый (онытыла): “...Юл басуны икегә аера. Аның бер ягында көздән чәчелгән арыш...” (К.Кәримев. Якты юл, 1982, 3 июнь) Икенче ягында нәрсә икәне әйтелми; “Татарстанның Актаныш, Башкортстанның Илеш районнары күршеләр, дуслар...” (Календарь, 1985, 16 авг.). Илеш районы уңышлары санала, ә икенче факт –Актаныш “онытыла”; Процессның **вакыт эзлеклелеге** сакланмый: “Ул елны җәй бик коры килде... Каршы тау буендагы кайсыбер чишмәләрнең коруы да шул сәбәптән булды. Сабан ашлыклары тез тиңеннән генә үстеләр һәм башак чыгара башладылар. Арыш та сирәк кенә булып чыкты, үсми калды (С.Т., 1985, 2 авг.). Башта арыш чәчелгәнгә,

санаганда да аны алдан әйтергә кирәктер; ә) җөмләдәге төшенчә сөйләм барышында башта бер төрле мәгънәдә булып, аннары икенче мәгънәгә яисә мәгънә төсмеренә күчә. Бу хилафлык гадәттә синонимның дөрес сайланмавыннан килә. Мәсәлән: “Бригадир хезмәт алдынгылары белән хаклы горурлана. Механизаторлардан И.Нурмиев, Р.Сөнгатуллиннар *тырышлыкларын кызганмыйлар.*И.Сәйфетдинев, С.Зәйнуллин, З.Кадыйров та үзләренә тапшырылган участокларда *зур тырышлык куеп эшлиләр*. Г.Фәхретдинева, А.Кадыйрова, Г.Борһанова һәм башка бик күп уңганнар чөгендердән *мул уңыш үстерәләр* (С.Т., 1985, 30 июль). Синонимнарны сайлауда талымсызлык, тел мөмкинлекләрен ачык күзалламау, сөйләм мотивларын истә тотмау аркасында китә торган хата бихисап. **Синонимның функциональ бурычларын** мәктәптән үк ачык күзалларга күнегергә кирәк. Сөйләм барышында синонимга өч бурычтан мөрәҗәгать ителә: төшенчәгә, иң башта, мәгънә төгәллегенә ирешү, икенче бурыч – төгәллек саклаган хәлдә төшенчәдә хис төсмерен саклау, өченче максат – ул сөйләмдә кабатлауга юл куймау. Соңгы ике максат беренче максат катгый үтәлгәндә, ягъни төшенчә иң төгәл мәгънәгә ия булганда гына куела.

Янә бер мисал: “Күптән түгел генә авылга шефлык ярдәме күрсәтү *сезонлы төстә генә* алып барыла иде, бүген исә бу да *планлы нигездә* алып барыла” (“Татарстан” радиосы, 1984, апр.). Төшенчәләрнең синонимлыгына шик туа, кире кайтып уйланырга, ачыкларга мәҗбүр буласың, ягъни бердәйлек законы үтәлмәгән.

– **Мәгънә өтеклеге. Төгәллек җитми:** Табынга куяр алдыннан винегретны *яшелчә кисәкләре* белән бизәргә мөмкин. (Нинди кисәкләр?); Яшелчәләрне аерым пешерергә кирәк. (Нәрсәдән аерырга? Аерым-аерым пешерергәдер?) (Байрак, 1982, 26 июнь); “*Куанычлы шатлыклар* телибез” “Татарстан” радиосы, 1999, 25 март). Сүз бар – гомуми мәгънә бар, ә конкрет мәгънә юк;

– төшенчәдә мәгънә нисбәте сакланмый: а) артык була, ә) ким була. Мәгънә кимлеге (өтеклек) эчтәлек кимлеге һәм структур (төзелеш) кимлегеннән (кушымча өтеклеге) хасыйл була: Мәхәббәт җепләре белән *мәңге (мәңгегә*-дер*)* бәйләник әле (Җырдан); Төгәллеккә тәңгәл берәмлек табу белән дә, берәмлеккә өстәмә төсмер бирә торган чара өстәп тә ирешеп була: “Гражданнар җыены *урамда яшәүчеләрне* борчыган проблемаларны райсовет башкарма комитетына җиткерергә карар итте (Коммунизм байрагы, 1989, 25 май). *Урамда яшәүчеләр* – гомуми; конкретлаштыру чарасы сорала. *Шушы урамда; фәлән исемдәге урамда* һ.б.

Бу кимчелекнең сәбәпләре: а) **мантыйкый басым дөрес төшерелми:** “Кеше *бер эш* белән генә шөгыльләнми (Якты юл, 1982, 5 июнь); Мондый хаталарны текстны эчтән кычкырып укып төзәтеп була. Бигрәк тә әйтмә сөйләм өчен әзерләнгән текстларны төзәткәндә бу таләп даими үтәлергә

тиеш: “Зөһрә *сиздермичә генә исерә башлаган* Фазылҗановны күзәтте” (Ф.Хөсни хикәясеннән); “*Беренче булып даны* бөтен республикага таралган бозау караучы кыз чыкты (Атилла Расыйх хикәясеннән); “Сөйгән *кызы янына* килә микән соң?” (М.Хәбибуллин әсәреннән); ә) факт төгәл, конкрет түгел; б) грамматика таләбе (нормасы) үтәлмәгән; в) мәгънәгә тәңгәл тел чарасы (кушымча, сүз, сүзтезмә) табылмаган; г) берәмлек (җөмлә кисәге) сөйләм агышында (тонында) **җөмләдә сүз үз урынында түгел** – каршылык барлыкка килә, сорау, аптырау туа: “ *Ачлы-туклы тыл*да интегүчеләр дә, дүртәр ел буена окопларда туңып исән калучылар да соңыннан больницаларга сыймады... (К.т., 1989, 8 ноябрь);

“Ниһаять, былтыргы батыр Илһам энесен аркасына салды” (С.Т., 1982, 15 июнь)”. Берьюлы күпме сорау: былтыргы батыр кем? Илһаммы? Улмы энесен аркага салды? Әллә былтыргы батыр (кемдер) Илһамның энесен аркага салдымы? һ.б.; “Ничек тә шушы командаларны отып, хәзер очко җыю күздә тотыла” (Б.г., 2010, 15 сент.) “Беренче тапкыр шундый дәрәҗәле җырчысына тавыш бирергә теләде” (Матбугат ру, 2008, 25 март).

Сөйләм агышында төшенчәләр эзлексезлеге аркасында төрле мәгънәви хилафлыклар килеп тууына мисаллар: “Күптән түгел безнең теплоходта Саша Алексеевның әнисе улының каберен карарга барды.– ди Женя,– Инде карт, көч-хәл белән генә йөри. Әмма *улы турында сөйләгәндә* яшәреп киткәндәй булды” (Т.я., 1982, 7 авг.) Кем сөйли – анамы, әллә иптәшләреме? Уңыш бик нык күтәрелде. Шикәр чөгендере чәчеләсе җирләрне шулай эшкәртү нәтиҗәсендә башка еллардагыдан 70–80 центнерга күбрәк татлы тамыр җыеп алынды. Ә *күршенекеннән* ул 150 центнерга күбрәк булды” (Маяк, 1984, 15 окт.). Күрше бит берәү генә булмый;

Мәгълүм ки, мантыйкый басым аеруча радио, телевидение сөйләме өчен аеруча әһәмиятле: Менә озак еллар телевидениедә эшләгән журналист Илфат Фәйзрахманов фикере: “А.Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татарстан республикасы фольклор ансамбле чыгышы” дип таныштыра берәү. Мин бу хәбәрне ишеткәнгә кадәр Татарстанның җитәкчесе хөрмәтле Президентыбыз М.Шәймиевне белә идем... Күрәсезме, ялгыш сөйләм чәчне үрә торгыза. Инде басымга, интонациягә тукталып та торган юк. Бер генә мисал: паузаны һәм сүз басымын дөрес куймау аркасында нинди абсурд мәгънәләр килеп чыга: “ Дөрес халык (пауза) аз булды... Димәк, халыкның калганы “дөрес булмаганнар” булып чыга...(Б.г., Матбугат. ру сайты).

Халыкның 72 проценты адәм рәтле *дәвалана*, 60 проценты яхшы *белем ала алмый* (М.җ., 2005, 4 февр. Әхмәт Рәшит). Аңлашылмаучылыкны дөрес пауза, интонация хәл итә.

– **фикер агышы каршылыклы:** башта әйткән белән аннан соң әйткәне тәңгәл түгел;

– тезмәгә каршы мәгънәле берәмлекләр алынганга **фикер каршылыгы** да барлыкка килә: “*Тантана хакимлек* итте” (“Татарстан” радиосы, 1995, 16 гыйнв.). Оксюморон барлыкка килә. Гадәттә сүзләрнең битараф, уңай, тискәре мәгънәле төрләргә бүленүен мәктәптә үк үзләштермәүдән килә. *Авария нәтиҗәсендә, үлүе уңаеннан* кебек оксюмороннар шулай барлыкка килә.

Фикер агышында **өтеклек**:

– Хәзер *аны 3 ел төрмә көтә* (Т.я., 2010, 23 сент.); *Эштән соң* кайтам, шуңа *һәрвакыт язарга* өлгермим; Сезнең *тырышлык белән блог* караучылар саны буенча дүртенче урынга чыкты; Бүген *минем республикада* эшли башлавыма бер ай булган икән (Т.я., 2010, 23 сент. БР Президенты Рөстәм Хәмитевнең блогыннан тәрҗемә текстыннан);

Фикер агышында **“боргалану”**, томанлы булуны авторның максат итеп куюы:

Хәзерге мәҗлесләр, туйлар, юбилейлар, минеке кешенекеннән артыграк булсын дигәндәй, ярыш *формасындарак оештырыла шикеллерәк тоела.* (Т.я., 2010, 30 ноябрь, И.Шакиров);

– **бөтен – өлеш нисбәте бозыла:**

“Ул чакта кибетчеләрнең хезмәте бернинди закон белән дә беркетелмәгән һәм аларның язмышы фәкать хуҗалары – сәүдәгәрләрнең холкы һәм кәефенә генә бәйле була. *Алар* бергәләшеп үз-үзләрен якларга карар кылалар” (Аваз, 1990, №1-2, март). Алар кемнәр – кибетчеләрме, сәүдәгәрләрме? Монда бөтеннән өлешне бик төгәл аеру зарур;

– **бер рәттә булырга тиешле төшенчәләр эзлеклелеге бозыла**: Очты, очты *каргалар, чыпчыклар, самолетлар*, яулыклар, акчалар очты. (Балалар уеныннан). Канатлылар рәтенә канатсызлар да кергән.

Экскурсиядә балалар *нарат, каен, чыршы, имән, чикләвек, усак, зирек агачлары* белән танышты (Укытучы сөйләвеннән);

Парашютчы кызлар Т.Пересыпкина, А.Гурдина, М.Алексеева һәм *Р.Мортазин,* авиамодельче Л.Алдошин*, В.Титлов, В.Гукун* ил, дөнья рекордлары куйдылар (Татар календаре, 1985, 18 авг.) (Болары кем?);

“Ире Мөбәрәкҗан абыйның табигате, гадәте хатыныныкы кебек түгел. Ул тыныч күңелле, ипләп кенә сөйләшүчен, *өлкән кеше”.* (Әтнә таңы, 1991, 16 сент.) Гадәттә “рәт” тиңдәш кисәкләрдән тора, димәк ки, ул кисәкләр чыннан да ”тиң”, ягъни бөтен яклап бер рәттә булырга тиеш;

“Ә бит безнең татар халкы гомер-гомергә Аллага ышанган, намаз укыган, хәер биргән, кешегә ярдәм иткән...“(Туган як, 1991, 8 сент.);

“Кычкырып намаз укый башлаган картлар миңа ничектер серле дә, шул ук вакытта бик динле дә күренделәр” (Игенче даны, 1992, 6 авг.);

**Күнегү:**

*Балык, сарык, халык* – бер рәт төшенчәләре, чөнки тереклек ияләре, көтү (төркем) булып йөрү, яшәү, *-ык* кушымчасы уртак. *Чалыш, куыш, булыш*

бер мантыйкый рәтме? Үзегез чын мантыйкый рәтләрне уйлап табыгыз (ясагыз). Хата китү ихтималы булганнарын барлагыз.

“Төзелешнең салмак баруы гына җитмәгән, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй... әледән-әле *тәртипсезлек, караклык, хулиганлык кылучылар* да күбәеп китте” (Таң йолдызы, 1991, 10 окт.);

Бу сүзләрне биеклеге үсү рәтендә языгыз: *кыя, үр, тау*. Җавабы: *Үрләр биек / Таулар – биегрәк / Ә кыялар – баш әйләнә баксаң түбәнгә* (Гакыйл Сәгыйров); “Тавышлану” дигәндә нәрсә күз алдында тотыла соң? Закон проектының бер инициаторы Рафил Ногманов аңлатуынча, бу – *ремонт, төзелеш эшләре*, йөк төяү яки бушату, автомобиль сигнализациясе тавышы, *музыка тыңлау*, уен коралларында уйнау, җырлау, петардалар шартлату”. Бер рәт төшенчәләренең тиңдәшлеге төгәл бирелми.

Тәңкә карлар, күбәләкләр, чәчәкләр коела. (Р.Әхмәтҗан).

**Мәгънәви кабатлау (тавтология):** *кулына* көрәк алып; *башын* аска иде;

“Лена редиска чистарта, ә Ира суган турый иде. *Башларына* ак яулык бәйләгән, *күлмәкләре өстеннән* ак алъяпкычлар *кигән* кызларны башта танымыйча тордым (Яшь ленинчы, 1984, 11 авг.);

Тезмәдә бер үк мәгънәле ике, хәтта өч берәмлек янәшә килә: “*Бүгенге көндә* республикада 986 пенсионер яши. (Т.я., 2010, 7 сент.); “2007 елда илдә җинаятьчеләр саны 5 процентка кимегән. *Әмма шул ук вакытта* җинаятьләрдән зыян күрүче үсмерләр саны арткан икән. (Т.я., 2008, 17 май).

Тавтология калыплары (штамплары): *беләсеңме, аңлыйсыздыр, шәт* һ.б.;

**Бәйләү чараларын дөрес кулланмау аркасында туган мантыйкый хилафлыклар**

**Төп кимчелекләр болар:** нәкъ шул бәйләү чарасы түгел; язма бәйләү чараларына күнегелеп, әйтмә чаралар (интонация, пауза) искә алынмый; бәйләү чарасы нәкъ шул сүз үзе түгел; китек чара, калька чара һ.б.

Каршылык кисәкчәләре, кереш сүз-гыйбарәләр, бәйлекләр үз грамматик функцияләрендә кулланылмый. “1нче Октябрь – Өлкәннәр көне. Бу көнне без өлкәннәрне аеруча хөрмәтлибез, олылыйбыз. *Ләкин* без әби-бабайларга бәйрәм көнне генә түгел, һәр көнне хөрмәт күрсәтергә, ярдәм итәргә тиеш, *чөнки* алар – безнең эти-әниләребезгә тормыш биргән кешеләр” (“Татарстан” радиосы, 2010, 1 окт.). Беренче ике тезисны *ләкин* каршылык бәйлеге белән тоташтыру урынсыз – каршы кую максаты каралмаган бит. Өченче тезис исә *чөнки* мөнәсәбәтле сүзе белән дөрес бәйләнгән.

“Андый ата-аналар балаларына үзләре үк үрнәк булып торалар, алар алдында тавышларын күтәрмичә, тыныч кына сөйләшәләр, хезмәткә мәхәббәт тәрбиялиләр... Безнең районда андый гаиләләр күп. *Ә шулай да* кайберләрен атап әйтәсе килә” (Әлмәт таңы, 1990, 20 март). Биредә каршылык чарасы белән бәйләү ихтыяҗы юк иде.

**Орфография, орфоэпия кагыйдәләренең бозылуы**

Алар, гадәттә, тел законнарын бозу аркасында килеп чыга. Мәсәлән, мантыйкый басым бозылып, пауза әйтелми: “Сикереп торып тәрәзә төбенә килдем” (Т.я., 2007, 22 сент.). “Торып”тан соң өтер куелмаган, ә бит *тордым, килдем* тиңдәш кисәкләр, алар арасында өтер тиеш.

**Күнегү**

Менә бу гыйбарәдә артык сүз бармы, текстны әле төзәтеп буламы: “Юлда пыяла ваты*клар*ы сибелеп ятса – ике машина бәрелешкән, тротуарда булса – ике күзлекле (Т.я., 2006, 20 гынв. М.Ахунов).

**Мантыйкый кимчелекләрне булдырмау өчен методик-гамәли киңәшләр** (А.Мильчинга ияреп). (219–255 б.).

– текстны уку барышында шикне белдерә торган бер сигнал “кабынып” китәргә тиеш: мантыйкый хилафлыкны белдерә торган. Алар: фикер өлешләрен бәйли торган чаралар (*чөнки, димәк, ягъни, шуңа күрә, минемчә, безнеңчә, аңлашылуынча, күрәбез ки* һ.б. мөнәсәбәтле бәрәмлекләр яисә әйтмә сөйләмдә шушы мәгънә төсмерләрен белдерә торган *интонация, пауза, басым* чаралары, ә язмада шуларга тәңгәл *тыныш билгеләре*. Редактор менә шушындый “сигналларга” юлыгуга ук “Тукта! Шулаймы?” дигән шик белдереп, уйланырга тиеш. Уйлану нидән гыйбарәт? Мантыйкый бәйләнеш дөресме-түгелме? дигән сорау куеп, шуңа җавап эзләү: а) фикернең үзәген ачып, аны тәмам конкретлаштырып-гадиләштереп-“кечерәйтеп” бетереп күзаллау, ягъни фикри нәтиҗә (умозаключение) кысасында анализлау; ә) фикернең төшеп калган буыннарын да торгызып, бөтен бер чылбыр итеп күзаллау.

Катлаулы гына ситуацияләр килеп чыгуы ихтимал. Бервакыт Камазга Россия Премьер-министры Владимир Путин килеп, яңа производство ачу тантанасында катнашты да радио хәбәрчесенә интервью бирде. Шунда ул Камаз директоры Коготинны искә алды, тик исем фамилиясен әйтмәде. Бу хәл директорны бик түбәнсетте; моны радиотыңлаучылар да тойды. Икенче көнне радиоинтервьюны кабат биргәндә... искитмәле хәл... түрә директорның исем, фамилиясен дә әйтте. Димәк, текстның кимчелеген тотып алып, (аны кемдер кисәткәндер инде), аны төзәтү юлларын тапканнар. Ничек? Монысы инде редакторлык һөнәренең чыннан да середер...

**Күнегү**

Фикер агышындагы мантыйксызлык очракларын ачыклагыз, сәбәбен аңлатыгыз, төзәтү алымнарын тәгаенләгез:

“Без аларга нефть агызган арада, Кытай котычкыч тизлектә камилләшә, әллә нинди техникалар уйлар таба. Хәзер алар Русияне һәм дөньяның башка илләрен автомобильләр белән күмә башладылар” ( Т.я., 2007, 29 сент.); “Газ кертү белән поселок советы шөгыльләнә, *һәм начар түгел”* (Коммунизмга, 1990, 1 март); “Бер хатын гаражда ирен сөяркәсе белән тота. һәм шундук икесен дә “акылга утырта”: пычак белән иренең

күкрәгенә кадый, ә сөяркәсенең исә һөҗүмгә арт саны *дучар була*. Әйе, *мондый* хатыннардан күпне көтәргә кирәк “ (Т.я., 1991, 2 апр.).

**Нәтиҗә (йомгак)** - мантыйкый фикерләүнең сыйфатын бәяли торган критерийларның иң көчлеседер. Югары сыйфатлы нәтиҗә ясау – редактор осталыгының күрсәткечләреннән берсе. Аңа җентеклерәк тукталыйк әле.

Нәтиҗә диалектик мантыйк фәнендә калыпланган катгый категория булуга карамастан, редактор нәтиҗә ясауга, текст, сөйләм төренә бәйле рәвештә, иҗади карарга тиеш. Шуңа күрә нәтиҗәнен форма төрлелеге табигый санала. Бу яктан Габдулла Тукайның нәтиҗә ясау осталыгы игътибарга лаек. Үрнәкләрдән менә кайберләре генә:

– текстагы урынына карап нәтиҗә текстның башында, уртасында, азагында да була ала. Текстның башында ук була: “ *Җирдәге көннәр, төннәр, ел фасыллары – барчасы да кояштан киләдер”*. Текст буена шушы төп нәтиҗә икенчел нәтиҗәләргә таркатылып, дәлилләр белән исбатланып киленә: *“Иртә белән кояш чыкса, якты көн башланыр... Кояш булмаса, җирдә җылылык та, яктылык та булмаслар иде...*” (304 б.). Мәсәлән, менә бу нәтиҗә әдип шигыренең **урта** бер җирендә: *“Бу халыкны шул бозадыр, шул котырта, аздыра: Ялтырап күзләрне чагып, тугры юлдан яздыра“* (4т., 106 б). Яисә: *“Гакыллы сүзне ахмакка әйт, чукракка әйт – икесе дә бердер* “(карт балыкчы сүзе) (Шунда ук, 250 б.); нәтиҗә баш өлешкә дә, азакка да бүленә: “Кеше һәм арслан” мәсәле болай башлана: *“Көчле булмактан гакыллы булмак кат-кат артыктыр. Моңар ышанмаган кеше менә бу хикәячекне укыгач, гакылның артыклыгына кангать хасыйль итәр (ышаныр)”*; Мәсәл тәмамлана: *“Гакыл көчне җиңде. Көчле Арслан һәлак булды”* (Шунда ук, 269 б.); Нәтиҗә кереш сүз, кереш гыйбарә рәвешендә төп тексттан берникадәр аерылыбрак тора: *Бу урында һичкемнең йөзен ертмыйча гына бер сүз әйтергә мөмкин: бер эшнең очына чыкмыйча мактану кирәкмәс* (250 б.); Тексттан бөтенләй дә аерым торган нәтиҗә дә очрый: *“Мин сиңа бер сүз әйтим, хәтерең калмасын: син кыр Кәҗәләрен сыйлап, азык бетергәнче, үз Сарыкларыңны яхшы сакласаң булмасмы?”* (252 б.)

Нәтиҗәне белдерү чаралары да бик төрледән, мәсәлән, а) әсәрнең теләсә кайсы персонажы сөйләме рәвешендә. “Каракош бу сүзләрне (тавыкның аларны хуплау сүзләрен) тыңлап торуга чыдый алмыйча: *“И дуслар! Кайвакытта безгә тавыктан да түбән төшәргә туры киләдер. Әмма Тавыкларга һичбер вакытта да болытка җитү насыйп булмыйдыр!”*– диде ( 3 т. 1956, 229 б); әсәрдән бер түгәрәк гыйбарә, образлы сурәтләү рәвешендә: *“Тычканнар, үлчәвечнең ике ягы да тигезләнгәнен күргәч, тавышсыз гына кайтып киттеләр* (Шунда ук, 297 б.); Сорауга җавап рәвешендә: *“Сабан сорый: “Иртәш, син ни сәбәптән болай ялтырыйсың да мин ни сәбәптән мондый тутыккан? Иптәше аңар: ,Минем ялтыравым тырышуымнан килде...*” (Шунда ук, 299 б.); Фактка яисә хәбәргә аңлатма, комментар бирү рәвешендә: “Төп текст: *“Укучы! Исең китмәсен, кем ни*

*яхшылык хакында сөйләсә, кешеләрнең колагын тондырса, бел ки, ул кеше икенче берәүнең кесәсеннән генә яхшылык итәргә яратучы буладыр”.* Менә бу тезиска өстәмә аңлатма нәтиҗә максатын да күз алдында тота: *“Ул яхшы белә ки, аның үзенә ул яхшылыктан бер тиен дә зарар килми, әмма үз өлешенә бер изгелек итәргә тугъры килсә, ул бөтенесенә ошбу Төлке кеби буладыр* (Шунда ук, 231 б.).

Шушы рәвешкә янә бер мисал – “Күке илә күгәрчен” мәсәленнән: *“Аталар! Аналар! Бу – сезгә сабак. Мин моны балаларны гаепләр өчен язмадым”.* Шушы төп нәтиҗәгә әдип өстәмә бирүне дә кирәк тапкан – ул нәтиҗәне конкретлаштыра, үтемлерәк итә, *“Балаларыгыз сездән аерылып, кеше кулында үссәләр, кечкенә вакытта сездән хөрмәт күрми, сезнең тарафтан сөелми үссәләр, карт көнегездә сезгә әйләнеп тә карамаслар. Болай булганда сез балаларыгызны шелтәләмичә, үз-үзегезне шелтәләгез”* (Шунда ук, 271 б.);

Гомумиләштерә торган, билгеләмәгә, кагыйдәгә охшаш йомгак ясауга тартым нәтиҗә: гыйбарәләр: *“Бер сүз белән әйткәндә, бәхетсезлекләр инсаннарның мал бәһәсен белмәүләренең вә үзләренең сыбызгыларына ифрат артык түләүләреннән түгелме соң?”* ( Шунда ук, 243 б.); Бөтен эчтәлеккә авторның кыска гына гомуми бәясе: *“Егет сайлаган кызларга гыйбрәт!”* (228 б.); киңәш итү рәвешендә: *“Безгә дөреслекне ялгыштан һәрвакыт аерырга кирәк, бу икенең берсен берсе урынына төшермәскә тырышырга кирәк”* (217 б.). Яисә: *“Бу аш пешерүче Мәчене сүз берлә инсафка китерергә тырышканчы, чыбык берлә тәэдип итәргә (әдәпкә өйрәтергә) кирәк иде”* (249 б.).

Бәян итү рәвешләренә килгәндә, нәтиҗә менә мондый сыйфатлар ала:

– эчтәлектәге факт, деталь, дәлилләр гомумиләштерелеп, фәлсәфи, нәзәри йомгак ясала: *“Дөньяда күп горефләр бар ки, аларның дәрәҗәсе менүе өчен җан көчләре илә тырышкан Зарифлары баеган Гарифлардан чикләвек кабыгы да күрмиләр”* (203 б.). Монда нәтиҗә ясау өчен бер генә факт, деталь дә нигез була ала: “*Кеше үзе бозык булып та дәрәҗәсез булса ул бик тикшерелмидер. Әмма бозыкка дәрәҗә бирелсә, аның бозыклыгы, тәмсиләдәге (мәсәлдәге) кыңгырау тавышы кеби бик тиз һәм бик ерак ишетеләдер”* (200 б.).

Күчерелмә мәгънәле нәтиҗәләр. Әйтик, мәсәлдә сүз җанварлар турында бара (мәсәлән, Арсланга хезмәт иткән Тиен турында), ә нәтиҗәдә хәл турыдан-туры кешеләргә кайтарып калдырып ясала: *“Шәкертләр гомерләренең иң гүзәл вакытында ачлы-туклы мәдрәсәдә ятып гомер кичерәләр. Дөрес, яшьләре 30–40ка җиткәндә, мулла булыпмы, я башкачамы азык табалар. Ләкин ни файда? Күкрәкләре череп, яңакларыябышкан, уйнап тора торган күзләр урынына тирән-тирән чокырлар гына калган буладыр”* (218 б.). Янә бер мисал – күчерелмә мәгънә кешегә кайтарыла да, нәтиҗә исә күчерелмә мәгънә дәлиле белән беркетелә: Этләр дуслыгы турындагы мәсәл болай тәмамлана: *“Замана дусларын сөйләгәндә гөнаһлы булмыйча сөйләми мөмкин түгелдер. Ике дусның сөйләшкәннәрен*

*тыңлап торсаң, бодларның җаннары бер икән дип уйларсың; аларга сөяк ташласаң, бөтенләй ошбу этләр кебек булалар"* (254 б.);

Талантлы, үзенчәлекле әдип, язучылар нәтиҗәләрне дә калыпланмаган, күнегелмәгән рәвештә ясый алалар. Г.Тукайдан кайбер мисаллар:

– сөйләнгән вакыйганың эчтәлегенә анда бөтенләй телгә алынмаган кеше, вакыйга, фактка күчереп ясала: *"Мин кичә мәхкәмәдә бер хаким күрдем, минем уемча, ул да эшне секретарьга тапшырса, оҗмахлы булыр иде"* (207 б.);

– төрттереп, яисә киная белән ясалган нәтиҗә: *"Сиңа, дустым, сүзем шулдыр: татарга сатма матбугат, трактир ач, татарга сат та тор һәртөрле мәшрубат (эчемлек)"* (1т. 99 б.);

– нәтиҗә турыдан-туры ясалмый да. Укучы аны эчтәлектән, мантыйкый фикер агышыннан үзе ясар дип уйланыла. Мәсәлән, "Сабан сөрүче" мәсәлендә Үгез мөгезендә кайтып килүче Чебен тасвир ителә. Нәтиҗәне үзең яса.

Башка әдип, язучыларыбыз остазның мул тәҗрибәсеннән ничек файдалана? Менә кайберләре иҗатыннан нәтиҗә ясау осталыгына берничә генә мисал: Мәсәлән, шагыйрьләр образлы (сурәтле) нәтиҗә үрнәкләрен бирә. Шәүкәт Галиевтән бер мисал: *"Сатучы чибәркәй чытлыкланып, елмаеп сорый: – Алманың ниндиен аласың – тәмлесенме, матурынмы? Әче булса да матурын сайлады егет. Әчелеге соңыннан беленде ..."* (Ш.Галиев, 104 б.);

Менә бу очракта язучы башта күз алдына килерлек, тәэсир итәрлек итеп күренешне тасвирлый, аннары нәтиҗә ясый: *"Әни, минем күлмәк сәдәпләрен төймәләп, тәрәзәгә ишарә итә:*

*–Әнә андагы урманнарны күрдеңме. Суык бабай әнә нәрсәләр ясап киткән.*

*Алай икән шул. Без йоклаган арада тәрәзә пыяласын бик матур бизәкләр төшергәннәр. Монда эре яфраклы абага үләне дә бар, чыршы агачлары да.."*. (Гомәр Бәширев. Туган ягым – яшел бишек, 27 б.);

Һич уйламаган, көтелмәгән нәтиҗәләр дә очрап куя: *"Мунчада... Иң матур җыр, иң матур арияләрне шунда күп ишеттем. Глинка, Сәйдәш. Берсе җырлый, берсе сызгырып кушыла. Күрәсең, җан йомшый, җан эри..."* (Сибгат Хәким. 291 б.).

Нәтиҗә ясау зур осталык, нечкә бер тәэсир сәләте сорый. Ул турыдан-туры бәреп әйтеп, күрсәтмә бирү, үгет-нәсихәт булып та тоелмасын, сүз боткасы, гомуми фәлсәфә эчендә тоныкланып, югалып та калмасын. Эш дәфтәремдә үрнәк итеп сайлап куйган текст-нәтиҗәләр арасында "очраклы нәтиҗә" дип тамгаланган бер "үрнәк" саклана. Ни кызганыч, авторы да, әсәрнең исеме дә теркәлмәгән. "... 1967 елның көзендә Ялтада эчкәннән бирле минем кымыз эчкәнем юк иде. Бу эчемлек турында гомер буе хыялланган идем. Иллә дә яшь гомерләребез әрәм булды урыс аракысы эчеп. Менә бит бабайлар нинди акыллы булганнар: кәрәздән ясалган ачы

бал һәм кымыз эчкәннәр. *Шулай да зәһәр аракы эчкән урыстан җиңелгәннәр...*".

Дөрес булмаган, кимчелекле, ризасызлык тудыра торган нәтиҗәләр дә очрап тора. Күпчелегендә алар тезис белән дәлил мөнәсәбәтенә бәйле: йә тезис кимчелекле була, йә дәлилләргә куела торган таләпләр үтәлми. Без ул кимчелекләргә аерым-аерым тукталып, анализлаган идек, аларның һәр кимчелеге турыдан-туры нәтиҗәдә дә чагылыш таба.

Тормышчан хакыйкатькә туры килми торган (ялгыш, дөрес булмаган, ялган нәтиҗә ясауга бер мисал: Балыкта кычкырып сөйләшергә ярамый, балыкларның ишетеп, *су төбенә китүе* бар (өстә генә йөзә торган балыклар да була) (Т.,я., 2010, 14 сент.).

**Күнегү**

Тагын бер кат фикер агышындагы кимчелекләрне тоемлагыз, нидән гыйбарәт икәнен аңлатыгыз, төзәтү чараларын барлагыз:

Без еш кына: "Яраткан эш, хезмәт шатлыгы ", дибез. *Ә* бу нәрсә? Һәркемгә дә сәләтенә карап профессия сайлап алырга туры килми бит. *Һәм* эштән кайберәүләр бәхет тоймыйлар, *хәтта* яраткан эшендә дә кыенлыклар, күңелсезлекләр була. *Ләкин* яхшы итеп башкарган эштән безнең һәркайсыбыз канәгатьләнү таба ала... (Алга, 1982, 14 сент.);

Быел терлекләрне *суеп бетерү аркасында киләсе җәйгә бозаулар саны да азаячак* (Т.я., 2010, 7 сент.). Беткәч, бозау кайдан тусын?!

Ә диннең куркыта-өркетә торган ягы да, кызыктыра-җәлеп итә торган ягы да бар. Шунлыктан ул гасырлар сынавын үткән бердәнбер иң кулай, чын мәгънәсендә универсаль идеология булып кала һәм якын арада гына аны алыштырырдай башка идеология юк та. Шушы гади генә нәрсәне аңлый алмау большевизмның башына җитте дә инде (Т.х., 1992, 18 окт.);

Пенсиядә булуына карамастан, Иттакый Халиков әле дә концертларда катнаша (С.Т.);

Районда Ә.Вәлиев үрнәгендә тагын берничә кеше шәхси кибет ачарга ризалык белдерде. Димәк, яңа башлангыч халык тарафыннан хупланды (Т.х.);

Югалтулар төзелешнең гомуми үзкыйммәтенә кире яктан суга ...( С.Т.);

Кояш тәрәзәгә карау белән Марат тиз генә сикереп торды һәм урамга карады. Язгы иртә сокланып туймаслык иде. Күңел нindидер шатлык булыр дип көтә. Иң зур яңалык – кара каргалар һәм сыерчыклар килгән икән. Алар бүген үз ояларына басып, туган якта тәүге таң атуын каршылаганнар.Әнә бит, берсе Марат ясаган ояга да кунган (Сабантуй, 1991, 27 апр.).

**Күнегү**

Әйтмә сөйләмне төзәтү үзенчәлекләрен истә тотарга, дөрес яңгырашка, аһәңлеккә ирешергә

*Күккүгәрченкаемны* сагынам... ди җырчы. Сингармонизм законына буйсынып, күчешне тоемларга, нечкә бирергә, аһәңлелеккә ирешергә мөмкин иде.

Басымны озын сүзләрдә саклау кыен – *Азатлык* сүзе авыр әйтелә, басым чөнки төрлечә төшә ала. Кәрим Яушев, мәсәлән, *Озатлык*, ди.

Татар радиосын тыңлаганга колак торган очраклар: *ат казанган,* дип пауза ясала. *Була чак,* дип.

Элизия күренешләре: *кара урман, аулак өй (*дөресе *курурман, аулагый);*

Протеза: *станса, шпион (*дөресе*: ыстанса, эшпиүн; эскәтер, өстәл, сумала,эшләпә* бит!);

Апокопия (апакопа*): реклама, газета, арматура, программа* (дөресе: *реклам, газет, програм, арматур; рам, кукуруз, аптек, фанер* бит!

Авыр әйтелешле, аһәңгә комачаулый торган очраклардан (сугыш**чысы**, сак**чысы** һ.б.) сөйләячәк текстыңны алдан әзерләгәндә ничек тә “качарга” кирәк.

## ***Җиденче тема*: Текстта фактик материалны төзәтү**

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Факт нәрсә ул? Кеше, предмет, күренеш, вакыйга һ.б. атамаларын, вакыт, урын, микъдарь төшенчә, тамгаларын, сан, датаны һәм башкаларны редакторның факт буларак тою сәләте, боларга мөнәсәбәте.

Фактик материалның төрләре. Фактны әсәрнең идея, темасына, әдәбиятнең төренә, жанрына карап сайлау, куллану, төзәтү үзенчәлекләре.

Фактик материалга куела торган төп таләпләр: дөреслек, яңалык, гомумиләштерү, аһәңлек һ.б. Документаль иҗат (журналистика, публицистика һ.б.) әсәрләрендәге фактик материалны редакцияләү үзенчәлеге.

Исем-атама, терминнар белән белдерелгән фактик материалны сайлау, төзәтү алымнары. Бердәй бәян ителү. Милли үзенчәлекләрне истә тоту. Географик атамаларга таләп.

Текстта сан, дата. Статистик материалларны (таблица, сводка, төрле исемлек, сызымнар һ.б.) редакцияләү. Төзәтү барышында санау, чагыштыру, төгәлләштерү һ.б. алымнары.

Журналистик-публицистик текстта цитатның әһәмияте. Төрләре (башка тексттан өзек, җыр, гыйбарә, туры сөйләм һ.б.) Цитатны тикшерү һәм төзәтү юллары. Цитатка искәрмә бирү тәртибе. Кульъязманың аппараты. Дәүләт стандарты таләпләре.

Факт буларак сүз һәм телнең башка чаралары. Факт буларак экстралингвистик, паралингвистик чаралар. Фактик материал белән эш иткәндә мантыйк законнарына таяну.

**Ялгыш фактны тою, аңлау, сәбәбен төшенү һәм төзәтү**

**Факт нәрсә ул, аның дөреслегенең әһәмияте**

Яшәешне дөрес һәм төгәл чагылдыру, фәннилек – мәгълүмат чараларын редакцияләүнең төп принципларыннан берсе, дигән идек. Бу таләпне фактларга таянып, аларны җитәрлек сайлап алып, дөреслегенә ирешеп редакцияләп кенә үтәп була. Мондый әһәмиятле категория – факт, фактик материал нәрсә соң ул?

Факт – ул тормышның үзендә булып үткән эш-гамәл-хәл, уйлап чыгарылмаган, реаль вакыйга яки күренеш. “Нинди дә булса нәтиҗәгә килергә, йомгак ясарга яки берәр нинди фикерне ачыкларга ярдәм итәрдәй нәрсә; дәлил”, диелә “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә (3 том, 334 бит).

Факт, фактик материал дигәндә без конкет шәхеснең исемен, фамилиясен, әтисе исемен, кушаматын; һөнәре атамасын, мактаулы, хәрби, фәнни дәрәҗәләренең исемен күздә тотабыз; аның эшләү, яшәү урыннарының, ягъни эшханә, учреждение, оешма атамаларын, яшәгән авыл, шәһәр, өлкә, республика, төбәк, мәмләкәт, ил, континент һ.б. урын исемнәрен; тәрҗемәи хәленә караган сан, даталарны саныйбыз. Төрле вакыйгаларның исемнәре, даталары, көндәлек кулланыла торган предмет, күренешләрнең исем-марка, символ-тамгаларның атамалары (мәсәлән, китапның, газет, журналларның, кино,-телефильмның, спектакльләрнең исем-атамалары ) – барысы да фактлар. Әсәрнең үзенә килгәндә, аның исеме, аны барлыкка китерүдә, төзәтеп, бастырып чыгаруда катнашкан шәхесләр, әсәрнең төрен, жанрын, күләмен-тиражын белгеләгән сан-мәгълүмат, әсәр эченнән сайлап алынган цитат, өзекләр – барысы да факт, фактик материал хасыйл итә.

Әсәрен тормышчан, ышанычлы итәр өчен иҗатчы (язучы, журналист) фактның, көчле, тәэсирле чара буларак кодрәтеп, әһәмиятен тоеп, аның кадерен белеп, җаваплылылык белән эш итә. Моны редактор да әсәрнең буеннан-буена исеннән чыгармаска тиеш. Аның фактка карата мөнәсәбәте журналистныкыннан һич тә кайтыш була алмый. Менә бу уртак җаваплылыкның кайбер якларын искә төшереп китик:

– факт – ул чынбарлыкны танып белү һәм өйрәнүнең аерылгысыз бер өлеше, элементы. Факт – җанлы, тере элемент: ул гел үсештә, хәрәкәттә, бер-берсе белән бәйләнештә генә карала, анализлана, өйрәнелә;

– журналист иҗатында фактның әһәмияте чиксез зурдан, дөресрәге, фактсыз журналистик иҗат була алмый;

– фактларны сайлап алу, аларны нәтиҗә ясауның нигезенә салу фәкать фәнни дөреслек, хакыйкать принцибы нигезендә генә була ала;

– ә мондый принцип исә бары гадел, демократик иҗтимагый шартларда яшәгәндә генә мөмкин. Димәк, журналистның да, редакторның да иҗат шартларының нинди иҗтимагый мохитта башкарылуы әһәмиятле.

Әсәр тукымасында факт– ул тема чыганагы да, анализ өчен объект һәм чара да, журналистка эзләнү, иҗат өчен башлангыч нокта да. Аны сайлау, табып алу, куллануның һәр иҗатчының үзенә хас алым-ысуллары бар. Тексны анализларга, төзәтергә алынган редактор да менә бу тезисларны, иҗат нечкәлекләрен белергә тиеш.

Әйе, яшь редакторлар үзләренең төп һөнәри бурычы итеп фактик материалның дөреслеген, ягъни чынбарлыкка туры килү-килмәвен тикшерү дип саныйлар. Тик менә шуннан ары китмиләр, шуның белән чикләнәләр. Ә бит бу бурыч, ягъни исем-атамаларның, сан, даталарның реальлеккә туры килүен тикшерү, дөресләү ул фактның асылын төшенүнең урта бер буыны гына. Төп бурыч – ул фактка нигезләнгән чынбарлыкның фәлсәфи асылын аңлап эш итү.

Факт – чынбарлыкның төп бер элементы. Ни өчен төп элемент? Чөнки яшәешнең кеше аңында, иҗтимагый фикер рәвешендә чагылышы да. Текстка карата бу фәлсәфи закончалык болай чагыла: газет өчен кечкенә генә хәбәрме, яисә тасвирнамә, репортаж, очеркмы, әллә инде фәнни бер хезмәт яисә публицистик язмалар җыентыгымы, редактор аны бәяләү, җәмәгатьчелеккә тәкдим итү өчен анализ ясаганда нәкъ менә аерым фактка, яисә фактлар системасы – фактик материалга таяна. Фактик материалга нигезләнеп кенә текстның, әсәрнең төп эчтәлеге ачыклана, аңа нәтиҗә ясала. Фәлсәфәче Сенека “Мисаллар белән аңлату юлы, гомуми акыл сатуга караганда кыскарак”, дигән. Документаль әдәбият иҗат итүдә бай тәҗрибә туплаган язучыларның берсе Максим Горький: нәзәри (теоретик) нәтиҗәләр ул фактлар “сыгынтысы”, дигән, димәк ки, ахыр чиктә без барыбыз да тормышны фактларга таянып өйрәнәбез, сабак алабыз, дигән (М.Горький  и советская печать. М., 1968, С.217).

Фактлар белән эш иткәндә, аларның фәлсәфи нигезен үзләштергәндә материалистик гыйлемне тирәнтен өйрәнгән белгечләрнең, мәсәлән, галим И.П.Павловның, җәмәгать эшлеклесе В.И.Ленинның күзәтү-нәтиҗәләре әһәмиятле. И.Павлов, мәсәлән, “фактлар галимгә һава кебек кирәк”, дигән. В.Ленин документаль әсәр язганда фактлар белән эш итүнең бөтен бер методик системасын булдырган. Бик кыска гына алганда, ул менә нидән гыйбарәт: – фактлар чынбарлыкка туры килгән, бәхәссез булырга тиеш; – фактның кайдан, ничек алынуы (табылуы) әһәмиятле; – фактларның бер-берсенә бәйләнешен, яшәеш белән дөрес бәйләнештә булуын истә тоту зарур” .“Чынбарлыкның төгәл фактлары гына җанлы тормышны чагылдыра ала”, дигән. (ПСС, 31 т., 134–135 б.).

Димәк ки, редактор фактны анализлаганда аны автор күзаллаган кысада гына күзәтү белән чикләнми, ә бәлки авторның аны ничек табуы, нинди мотив-сәбәп белән текст эчтәлегенә тәкъдим итүен, нинди нәтиҗәләр ясау

өчен куллануын күзәтә-уйлана, бәяли. Бу анализ барышында ул үз-үзенә менә нинди сораулар куя:

– текстта фактлар бармы?

– алар буш сүз, буш фраза, артык гомуми түгелме?

– төгәлме, шик тудырмыймы, бәхәссезме?

– башка фактлар белән бәйләнештәме?

– үсештә, хәрәкәттәме, тормышчанмы?

– нәтиҗә ясарга нигез-дәлил була аламы?

– аңлаешлымы, фикер агышында буталчыклык, икеле-микелелек китереп чыгармыймы?

– хәбәр чыганагы, мәгълүмат буларак кирәклеме, әһәмияте бармы?

– фикерне дөрес бәян итәргә булышамы, бүтән фактларны кабатламыймы?

– стильне, сөйләм аһәңен бозмыймы?

– яңамы?

Менә шушындый анализ ясый алырлык, мөстәкыйль нәтиҗәләр ясап, авторның да үз хатасын аңларлык итеп төшендерерлек тәҗрибә-осталыкка ирешү өчен яшь редакторга кайбер гомуми таләпләрне дә үтәргә тырышырга кирәк була. Менә алар:

– белемеңә, тәҗрибәңә тәнкыйть белән карарга, редакцияләргә алынган текст белән танышканда “ничек тә җырып чыгармын, тәҗрибә җитәр”, дип үзеңне юатмаска. Текстта сүз барган тема-өлкәне тирәнтен өйрәнергә (өстәмә әдәбият укырга, белешмәләр тупларга, нәзәри һәм гамәли тәҗрибә белән танышырга, кирәк булса белгечләре белән аралашырга һ.б.). Узган гасырның азагында Татарстан китап нәшриятенең күренекле редакторлары арасында Кыям Миңлебаев сәнгать әсәрләрен редакцияләү буенча махсус белгечкә әверелде. Моңа аңарга атаклы сынчы Бакый Урманче иҗаты турындагы әсәрләрне редакцияләү, белгечнең үз язмаларын да бастырып чыгару белән шөгыльләнә башлау этәргеч булды. Ул сынлы сәнгать турында нәзәри әдәбиятне, белгечләрнең тәҗрибәсен төпле өйрәнде, Бакый абый белән танышып, бик якыннан аралашып, тәрҗемәи хәлен җентекле өйрәнде, сынлы сәнгать әсәрләрен – альбом, проспект һ.б. бастыру өчен безнең типографияләрнең үзенчәлекле шартларында сынау-экспериментлар ясады. Кыскасы, бер язманы редакцияләү бурычы аңа өр–яңа үзгә бер дөнья белән танышырга, шуны фәнни төпле өйрәнергә сәбәп булды. Соңыннан ул Бакый Урманче турында роман-дилогия язып бастыруга иреште;

– гомумән культуралы булырга, ә моның өчен белемгә даими тартылып торырга, күп укырга, “эрудит” дигән, гадиләштереп әйткәндә, “энциклопедист” дигән дәрәҗәгә гел омтылып торырга, шуңа ирешү, аны аклау өчен эчке бер ихтыяҗ тоеп яшәргә кирәк. Күренекле шагыйрь укытучыларга биргән “иң галим кеше икәнсез” дигән дәрәҗәле сыйфат

халык күңелендә редакторларга карата да береккәндер кебек. Ә ул сыйфат бик нечкә таләпләр белән бәяләнә.

Беренче тапкыр редакторлык вазыйфасын үзем Уфада 1918 елдан ук чыгып килгән “Кызыл таң” дигән татарча газетта үти башладым. Газетның баш редакторы Гали абый Алмаев иде. Әллә ни “мәшһүр” мөхәррир, әдип түгел иде. Шуңа яшь журналистта аңа соклану хисе башта әлләни чәчрәп тормаган иде. Шулай беркөнне дежур торганда бөтен битләрне дә төзәтеп бетереп инде кул куярга гына торганда ул укыган битләрне дә кертеп бирделәр. Искитмичә генә күз салган идем (башка вакытта аның нәрсә дә булса төзәтеп “кысылуын” хәтерләмәгәнгә), бер төзәтмәсенә күз төшеп, тукталып калдым, “... республика статистларының мәгълүматына караганда, быел уңыш...”. Бу текстны инде язманы әзерләгәндә дә, аны редакциядә басарга көйләгәндә дә, аннары мөдир-җитәкчеләр имзалаганда да, һәм менә тәмам кул куярга тиеш корректор, дежурлар укып чыкканда да – бер унлап кеше карашыннан, аңыннан үткән иде. Ә хата яшеренеп калган. Чын редактор аны барыбер тоткан: редактор *статистлар*ны *статистиклар* дип төзәткән иде. Статистның курчак театрында уйнаучы артист икәнен болай һәркайсыбыз белә инде югыйсә.

Чын редактор кем ул? дигән сорауга җавап бирергә туры килгәндә иң беренче булып Гата агайны күз алдына китерә торган булып киттем. Менә күптән түгел генә (2009 ел) “Татарстан яшьләре” газетында хәтта республика хөкүмәте башлыгының шул хатаны “тота алмавына” юлыккач, теге горурлык хисе яңарып, редакторлык хезмәтенең никадәр җаваплы, искерми торган, вакыт үткән саен актуальләнә генә барган хезмәт икәнен ачыкладым;

– редакторда фактик материалның асылын аңлау, аның текст эчтәлеген тулы, аңлаешлы итеп ачып бирү өчен әһәмиятен тоемлау сәләте булырга тиеш. Текстны уку барышында ук ул мондый сораулар куя бара (үзенә, авторга): бу факт нәрсәгә дә нигез була аламы? гомуми фикерне ачыклый гынамы, әллә конкретлаштыра дамы? иллюстрация-тасвир чарасы була аламы? – моның кайсысы мөһимрәк, нисбәтләре сакланамы?

– текстта хата бар дип хис итәргә, шуны табуның юл-алымнарын үзеңдә булдырырга. Сораулары: бу фактның асылын ачык беләмме? Нәрсәсе шикле? Нәрсәсен белеп җиткермим? Нәрсәне расларга, тикшерергә тиешмен?

– шушы текстны редакцияләр өчен нинди чыганак, белешмәлекләр кирәк, кайсы белгечтән өстәмә мәгълүмат алырга. Аларны кайдан табарга була?

**Фактик хатаны булдырмауның методологик һәм методик нигезләре**

– тексттагы һәр фактны тарихи күренеш дип хис итеп, аны үсештә, үзгәрештә, хәрәкәттә дип күзалларга кирәк. Әйтик, текстта сүз барган районның, республиканың, илнең тарихи үсеш барышында үзгәргән булуы да ихтимал. Мәсәлән, заманында безнең Казан арты төбәгендә берничә

район булып алды (“Кызыл юл”, “Тукай”, “Әтнә”, “Арча”...). Бу текстта сүз барган вакыйга кайсы чорга карый, ул чагында бу төбәк кайсы район саналган. Моны ачыклау тарихи хакыйкатькә хилафлык китермәс өчен кирәк. Күренекле шәхесләребез турында сөйләгәндә, еш кына бу төбәкнең иске исем-атамалары тикшерелмәгән, төзәтелмәгән була. Мәсәлән, радиодан күренекле шагыйрь Сибгат Хәким еш кына *Арча* районында туган дип хәбәр ителә, хәлбүки ул бүгенге *Әтнә* районы Күлле-Киме авылында туган. Сүз чыккач, әйтик: бик дәрәҗәле бер басма мине дә *Арча* районы Олы Бәрәзә авылында туган, дип язган иде, гәрчә ул шулай ук *Әтнә* районынык.

Хәтерлим: Яңа Чишмә районы оештырылып, ул рәсми расланганнан соң җитди генә бер газет күренекле генә журналистның репортажында “Күршебез *Чистай районы*” дип язылган иде, югыйсә күршеләре инде *Яңа Чишмә* районына әйләнгән иде.

Исеме берничә тапкыр үзгәргән тарихи шәһәрләргә карата аеруча сизгерлек сорала. Ринат Мөхәммәдиевнең “Сират күпере” романында Мирсәет Солтангалиев 1919 елның салкын октябрь иртәсендә *Петербургка* килеп төшә, диелгән иде. Санк-Петербург, Петроград, Ленинград исемнәрен йөрткән ул шәһәр әйтелгән көннәрдә *Петроград* исемендә иде. *Чаллы* шәһәренең дә *Брежнев* исемендәге чоры булуын еш кына истән чыгаралар – фактик хата еш китә;

– фактны хәрәкәттә күрсәтү дигән сүз –ул фактның асылын ачык күрсәтүне дә аңлата. Әйтик, тарих белән бәйле фактларның әһәмиятен көчәйтү өчен аны бүгенге фактлар белән чагыштырып, бәйләнештә бирергә кирәк. Элекке фактлар үзгәреп торганга, аларның иң яңаларын табарга тырышырга кирәк. Әйтик, Гражданнар сугышы чорында Идел хәрби флотилиясенең батырлыклары турында еш телгә алына. Аларны гадәттә комиссар *Николай Маркин* исеме белән генә бәйлиләр иде, ә менә соңгы елларда флотилия командующие *Федор Раскольников* аклангач, бу батырлыкларда аның да өлеше аз булмавы ачыклангач, каһарманнарның исеме янәшә күренүе тарихи фактны тагын да тулыландырып җибәрде;

– фактның тәэсир көче аны ничек бар шулай бәян итүдә генә түгел, ә төрле өстәмә чаралар белән тасвирлы, сурәтле итеп бәян итә алуда да. Факт ул күзалланырлык, күренеп торырлык, сурәтле булырга тиеш. Тонык факт, гомуми факт кебек үк, тискәре генә йогынты ясый;

– фактларның саны текст эчтәлегенә дөрес нисбәттә булырга тиеш: артык та түгел, ким дә түгел. Кайбер язучы ышандыру көчен арттырам, дип саннарны артык күп куллана. Сан булганы өчен генә язылган мәгълүмат берни бирми, тискәре тәэсир генә ясый. Һәр сан реаль хәлне белдергән төшенчәне алыштыра алырлык булсын. Хәзер дә әле район газетлары, мәсәлән, урак чорында яисә сөт саву буенча хуҗалыкларның мәгълүматын сводка рәвешендә бастыралар да өстәп шуңа комментар да бирәләр. Өстәмә, тулыландыру максатын тоткан мәгълүмат булса тагын бер хәл, юк бит, шул ук саннарны кабатлыйлар. Факт артык булмасын, җитәрлек кенә

булсын, югыйсә нәтиҗә өтек була, йомгак канәгатьләнерлек булмый. Психолог А.И.Липкина болай дигән: “әгәр нәтиҗә фактлар рәтеннән соң ясалса, ул хәтергә тирәнгәрәк сеңеп кала, әгәр фактларсыз гомуми, абстракт нәтиҗә ясалса, ул тиз онытыла”. Күренекле журналист, галим Ф.И.Әгъзәмевнең дә бер киңәше истә калган: әгәр дә әһәмиятле факт текстта кабатлана икән, ул хәтергә тирәнрәк уелып кала.

**Фактик ялгышларның сәбәбе, аларны булдырмау алымнары**

Һәр төр хата укучыга тискәре тәэсир итә: фикер агышын бүлә, уйландыра-борчый, ризасызлык тудыра; әгәр сизелми китә икән, ул аңа ялгыш информация бирә, яңа хаталарга китерә; журналистның, редакциянең, матбугатның абруен төшерүгә сәбәпче була. Тәҗрибәле редактор бер генә фактик материалга да (сан, дата, исем-атама, фамилия, цитата һ.б.) беркайчан да битараф булмас. Сизгер, үз-үзенә таләпчән булыр. Бу яклап редактор вакчыллыктан, “бет чүпләү”дән гарьләнмәскә тиеш. Бу аның һөнәри сыйфаты, бурычы.

Дөрес, редакцияләрдә аның бу сыйфатын дәртләндерә, үстерә, бу яклап аңа ярдәм итәрдәй чаралар да булдырылган. Текстны кабат-кабат эшкәртү өчен өстәмә вакыт бирелү, корректорларның кара-каршы укуы; элегрәк классикларның цитатларын махсус “кече редактор” дигән вазыйфа иясе укый иде; рәсми басмаларда (редакцияләрдә) “сафбаш” дип аталган өстәмә штат та кертелде. Һәрхәлдә редакцияләүнең фәнни дөреслек, хакыйкать принцибын үтәр өчен редакторга шартлар да тудырылырга тиеш;

– хатаның зуры яисә кечкенәсе дигән ялгыш фикердән һәр редактор азат булырга тиеш. Әйтик, Татар календаренда “Март ае үзенең *унике* туганы арасында иң үзенчәлекләреннән санала”, дигән җөмләдә киткән хата (бер айның туганнары унбер буладыр) әлләни хәвефле дә түгелдер, иҗтимагый зарары дәвамлы да түгелдер. Ә менә илленче елларда “Металлургия” нәшриятендә басылган бер кулланмада корыч койганда составына фосфор өстәү таблицасында 0,0001 урынына *0,00001* кебегрәк хата китүе аркасында чит илгә җибәрелә торган корычның сыйфатына күпмедер зарар килеп, гаепле редакторның эше судта каралуы истә калган. Редакторлык хезмәте белән Уфада, “Кызыл таң” газетында таныша башлавымны әйткән идем инде. Нәкъ шул елда “Кызыл таң”да ун ел элек хата җибәрелеп (Сталинград урынына *Сталингад)* дип басылып гаеплеләрнең ун ел утыру сроклары тәмамланып, берничә гаепле арасыннан бары берсенең эшкә кайтуы шаһиты булган идем. һәрхәлдә матбугатта илле ел эшләвем чорында редакторның бер генә фактка да гамьсез булмаска тиешлеген, хаталарның кечкенәсе-зуры булмый дигән хакыйкатьне төшенерлек мисалларга шактый юлыгырга туры килде.

Аңлашылса кирәк: һәр факт тикшерелергә тиеш. Редактор эшенең төп бурычы шушыдыр. Нәрсә ул фактны тикшерү?

– Текстны уку барышында ук барлык фактлар да барланып бетәргә тиеш, берсе дә “посып”, “качып” калмасын. Беренче чиратта: билгеләмә, аңлатмалар, йомгак, нәтиҗәләр; конкрет булмаган яисә конкретлашып

бетмәгән формулировкалар һәм нигезләмәләр; саннар, микдарь чаралары; даталар; исем, фамилия, кушаматлар; атамалар; терминнар; географик атамалар; сүзнең төп мәгънәләре; рәсем асты текстлары, иллюстрациягә аңлатмалар; мәгълүм кебек тоелган билгеләмә, аңлатмалар; цитата, өземтәләр һ.б.

– **кеше исем, фамилия, әтисе исеме белән бәйле хаталар**: – дөрес әйтелми-язылмый; гадәттә татарча ничек әйтелү-язылуын белсә дә исем хуҗасы аны “паспортта шулай язылган”, дип, татарча белмәвенең сәбәбен ачыклап та тормый, ә журналист (редактор) инде “хуҗа” белән бәхәсләшүне кирәк санамый. Шулай итеп, Йосыпов урынына *Юсупов*лар, адым саен;

– исемнең, фамилиянең әйтелеше (язылышы) охшашлыгы белән бәйле хаталар (җырчы *Венера Шакирова* диде Яңа гасыр радиосы (2010, 11 окт.) *Венера Шәрипова*ны; заманында күп кенә үзәк радио,-телекомпания дикторлары, журналист, редакторлары Шәймиев Минтимер *Шәймиевич* ди торганнар иде. *Шәрипович* урынына;

– исем, фамилия, әтисе исеме текст буена төрлечә языла: *Ислам Тимербаев, Ислам Кәрим улы, Кәрим Ислам улы, Ислам Кәрим улы Тимербаев, Ислам Кәримович Тимербаев, иптәш Тимербаев, Тимербаев иптәш, Тимербаев Ислам Кәрим улы, Тимербаев әфәнде* һ.б. Укучының фикерен мәгълүматны төрләндереп өзгәләгәнче текст башында шәхес турында тулы мәгълүмат биреп, аннары текст буена инициалларны бирүне унификацияләү (бер төрле итү) хәерлерәктер;

– татарча бер генә төрле әйтелергә (язылырга) тиешле исем, фамилия төрлечә әйтелә (языла): *Бадыйков, Бадиков, Фатыйх, Фатих, Фатхрахманов, Фәтхерахманов, Фәтхрахманов, Фәттәхов, Фаттахов, Фуат, Фоат, Фаат* һ.б.;

– татар үзе дә паспортны “бозу”дан куркып, бабасының әтисенең, хәтта үзенең исемен хаталы (урыс әйтә дип) язарга күнеккән. Гомер буе Таһирев Индусның Ризак улы дип әйтелүе-язылуына, шуңа үзенең ризасызлык белдермәвенә аптырадым. Менә  Татарстан радиосы аннан сорапмы-сорамыйчамы Ризаэтдин улы, диде;

– бер үк кешенең исеме фамилия булып, фамилиясе исемгә әйләнеп бутала; бу аеруча урыс исем-фамилияләрендә еш очрый. Бер елны “Литературная газета”да күренекле язучы *Иван Васильев* текст эчендә *Василий Иванов* булып киткән иде;

– төрле шәхесләр йә исеме, йә фамилиясе әйтелеше, язылышы охшаш булганга бутала. Бервакыт якташыбыз шагыйрь Хәкимҗан Халиков музеен ачарга Әтнә районының Яңа Шашы мәктәбенә кайткан идек. Шуннан үз кулларым белән язып, үз кулларым белән редакцияләп “Мәдәни җомга” газетының “И туган тел...” кушымтасында репортаж бастырдым. Икенче көнне укысам, чәчләр үрә торды – Язучылар союзыннан җитәкче булып барган язучыбыз *Вакыйф Нуриев*не *Вакыйф Нуруллин* дип язганмын. Нуруллинны әсәрләрен ешрак  укып та яхшы белгәнгә, Татарстан китап

нәшриятендә байтак еллар бергә эшләп тә, хәтта тору урамыбыз да бер булганга аның белән күбрәк аралашылган, исем-фамилиясен дә бергә әйтеп-язып та күнегелгән, күрәсең, хәтердә ул калып гыйбарә булып береккән.

Мондый төр хатаның китү ихтималын һәр редактор хәтереннән чыгармаска тиеш. Бер елны язучыларның еллык йомгак җыелышында күренекле генә рәисебез чираттагы нотыкчыга – Чаллы бүлеге рәисе күренекле язучы *Вахит Имамов*ка сүз биргәндә *Вахит Хаков*ка сүз бирелә, диде. Тагын бер үкенечле мисал: “Төзәтү. Газетабызның 27 апрель санында “Шуның белән шул” рубрикасында бирелгән хәбәрләрнең берсендә хата киткән. Җырчы *Флера Сөләймановаы Флера Сафиуллина* дип язганбыз...” (Т.я., 2008). Бер радиотапшыруда Мирсәет *Солтангалиев турында* сүз барганда алып баручы тик торганда Мирсәет *Сөнгатуллин* диде. Бервакыт Уфада күренекле татар генералы *Мәхмүт* Гәрәев килгәч, газет репортажында аны *Муса* Гәрәев дип яздылар. Уфада сугыш каһарманы Муса Гәрәев еш языла, еш кабатлана торган исем иде. *Марсель* Зарипов белән *Марсель* Галиевне дә бутадылар; Гыйбрәткә янә бер мисал: **“Гафу.** Газетабызның узган санындагы “Камалда премьера” дигән хәбәрдә хата киткән. “Зөбәйдә – адәм баласы” пьесасының авторы Шәриф Камал түгел, Шәриф Хөсәенов. Укучыларыбыздан, Камал театрыннан һәм язучының туганнарыннан гафу үтенәбез (Т.я., 2009, 24 дек.);

– теге-бу исемлектә шәхесләрне санап киткәндә еш кына система, тәртип булмый (алфавит, яшенә, фәнни, хәрби, эш урыны, вазыйфа дәрәҗәсенә һ.б. карап), һәрхәлдә фәнни нигезләнгән система, тәртип белән санарга күнегергә кирәк;

– **географик атамалар белән бәйле хаталарны:** элекке атама белән бүгенгесе алышына (моңа мисаллар китергән идек инде). Татарча атамаларның ялгыш әйтү-язуга аерым тукталырга кирәк. Гарәпчә, төрекчә, фарсыча атамаларның татарчасының дөрес булмау очраклары еш тәнкыйть ителә. Татарстан белән аннан читтәге матбугата төрлелек һаман бетерелми ( *Мәскәү–Москва, Чиләбе–Челябинск, Арча–Арск, Бөре–Бирск, Белорет–Белорецк* һ.б.). Турыдан-туры тәрҗемәгә кагылган кимчелекләр: *Юрмалы* түгел – *Юрмала; Карский* диңгезе түгел, *Кара* елгасы түгел – *Кар* диңгезе, *Кар* елгасы; *Нидерланды* түгел – *Нидерланд, Минусин* крае түгел – *Минуса* төбәге (елга атамасы да); Шул ук вакытта *Нахимов* авылы түгел – *Нахимовское, Кара* диңгез шәһәр комитеты түгел – *Черноморск* шәһәр комитеты; Татарстан матбугатының үзендә дә географик атамаларны төрлечә язу – иң еш очрый торган җитди хаталардан (Мәктәп исеме *Түбән Үрәтмә* дип тә, *Түбән Уратма* дип тә газетның бер санында (бер язмада) ике төрле басылган (С.Т., 1984, 19 гыйнв.);

– авыл исеме белән районныкы дөрес бәйләнмәгән була. *Чишмә, Тигәнәле, Балтай* кебек мәгълүм авылларны автор тарафыннан районы күрсәтелмәгән очракта газетта чамалап кына (тикшермичә) язып куялар, ул исемдәге авылларның башка районнарда да булу ихтималы истә

тотылмый. Чирмешән районы *Чишмә*се Апас районыныкы белән шулай буталган иде. Кыскасы: һәр фактны шик белән укы, һәр шикне фәнни тикшереп, бетер!

**Күнегү**

Фактик хатаны төзәтергә

Ятимнәр авылы Санк-Петербург өлкәсендә бар икән инде (Яңа гасыр радиосы. 2009, 1 дек.).

**Оешма, учреждение, эшханә һ.б. ләрнең атамаларын дөресләү**

– аларга тарихи үзгәрә торган фактик материал дип карарга күнегергә (*Татарстан китап нәшрияте* турында сүз барганда аның чорына, төрле елларга карап төрлечә аталуын истән чыгармаска кирәк: *Казгосиздат, Татгосиздат, Татиздат)*; Тарих белән бәйле текстта оешманың бүгенге исеме әйтелә дә элеккесе аталмый, яисә киресенчә, элекке исеме белән аталып, аның бүген ничек йөртелүе телгә алынмый; Оешма исемнәре белән бәйле янә берничә кабатланучан кимчелек: бүгенге рәсми исемнәр (мәсәлән, муниципаль җирлекләр авыл, район советлары белән бутала; Оешманың, төбәкнең Конституциядә, законнарда тәгаенләнгән рәсми атамасы гадиләштерелә, акланмаган алынмалар барлыкка килә (*хөкүмәт премьеры, район главасы, Дәүсовет рәисе* һ.б.); Оешма атамаларының кыскартылган варианты, яисә аббревиатура рәвеше аңлашылмаган рәвештә әйтелә һәм языла; текстны укыганда яисә әйткәндә берninди ООО, ҖКҖ лар да мәгънәсе аңлашылмаган килеш калырга тиеш түгел.

Оешма атамаларының өстәмәләре дә (фәлән исемендәге, орденлы, мактаулы яисә тарихи вакыйгага бәйле) фактик материал санала, аларда да төгәлсезлеккә юл куелмаска тиеш. Югыйсә заманында Ленин орденлы өстәмәсе белән Ленин исемендәге өстәлмәләрнең буталуы була торган иде;

– **вакыйга, күренеш, предмет, әйбер атамалары**ның да күпчелеге – фактик материал булып күзаллана: мәсәлән, шәхескә бәйле вазыйфа, һөнәр, белгечлек атамалары үтә төгәллек, конкретлык таләп итә, бу таләп үтәлмәгәндә аңлашу, аралашуда ялгышлыклар, кимчелекләр килеп туа, ризасызлык, канәгатьсезлек барлыкка килә;

**– тарихи вакыйга атамаларында китә торган хаталар:** урынсыз кыскартулар, өтеклекләр – *фин сугышы*; дөресе: *акфиннарга каршы сугыш*; *1905–1907 елгы Бөтенрус революциясе;* дөресе: *1905–1907 елгы Бөтенроссия революциясе* һ.б.;

- вазыйфа атамалары, мактаулы, фәнни дәрәҗә, хәрби исемнәр һ.б. “Минтимер Шәймиев һәм Фәрит Мөхәммәтшин Әлмәт сайлаучылары белән очрашты. Сайлаучылар *хөкүмәт җитәкчеләрен* котлап каршы алды. Вазыйфалары буенча беренчесе Татарстан Президенты (ул вакытта), икенчесе Татарстан дәүләт советы Рәисе. Бездә Хөкүмәт – Татарстан Министрлар кабинеты дип атала. Аның җитәкчеләре: Министрлар кабинеты Рәисе (премьер министр) һәм аның урынбасарлары (вице-

премьер). Гомумән дә, дәүләт термины белән хөкүмәт термины буталучан: *Хөкүмәт Президенты* аппараты ( Яңа гасыр радиосы тапшыруыннан).

Шәхеснең фамилиясе, исеме, әтисе исеме, һөнәре, белгечлеге, вазыйфасы, фәнни, хәрби дәрәҗәсе атамалары дөреслеккә туры килми, хаталы языла: "Гомәр Саттаров, Казан дәүләт университетының атказанган профессоры, филология фәннәре *кандидаты"* (Филология фәннәре докторы, күренекле галим үзенең фәнни дәрәҗәсе атамасын үзе шулай бозып язган булып чыга, чөнки хаталы мәгълүмат аның язмасының азагында куелган. Чын-чыннан редактор хатасы (В.Т., 2010, 20 февр.).

Фактик хаталар рәтендә еш кына кешегә өстәлгән вазыйфа атамасы ул кешенең вазыйфасы үзгәргәч яисә инде ул вазыйфада булмаса кабатлана торган була. Минтимер Шәймиевне президент дип, Рөстәм Миңнехановны премьер -министр дип автомат рәвештә өстәүләр әле бик озак дәвам итте. Урыс радиосы журналистларының Россия Хөкүмәте башлыгы итеп Примаков билгеләнгәч тә әле Премьер-министр Виктор... дип,... Черномырдин дип әйтә язып, тотлыгып торулары хәтердә;

– **газет, журнал, китап, кино,-телефильмнар атамалары**нда төгәлсезлекләрне булдырмау да – редакторның көндәлек хәстәре, моңа даими күнегүләр үтә бару зарур.

– **орден, медаль, мактаулы исем атамаларын** төгәл бәян итү; Монда ике төрле хата китүчән: беренчедән, орден, медальнең кыйммәти дәрәҗәсен белмәү, тоемламау, ягъни текстта санау тәртибен бозу: "Б.Фазлетдиновның күкрәген сугышчан медальләр, "Кызыл Йолдыз" һәм икенче дәрәҗә "Ватан сугышы" ордены бизи (Авыл утлары, 1982, 29 март).

Икенче җитди кимчелек ул бу предметларның исемен дөрес язмау: Татарстан китап нәшриятендә эшләгәндә бер күңелсез хәл истә калган. Сугыш ветераннары турында очерк җыентыгы чыгарган идек. Бер провокатор сугыш "каһарманы" булып йөргән икән, үзе турында очерк та яздырткан. Авторга ул өченче дәрәҗә "Ватан сугышы" ордены белән бүләкләндем, дигән. Автор тикшермәгән, редактор да сизгерлеген югалткан, бу орденның өченче дәрәҗәсе барлыгына шик белдермәгән;

– **техника атамалары, маркалары** һ.б. Заманында, мәсәлән, У–2 очкычы ПО–2 гә үзгәртелгәч (конструкторы Поликарпов үлгәннән соң үзгәртелгәч) газетларда киткән хаталарны нык тәнкыйтьләгәннәр;

**– терминнар, фәнни төшенчәләр** дә факт дәрәҗәсендә төгәллеккә ия булучан. Аларны фикер агышында тәмам ачыклап барырга, моның өчен белешмәлекләрдән, термин сүзлекләреннән файдаланырга, термин сүзне гомуми (битараф) сүз белән чагыштырып, аермасын ачыклый барырга кирәк. Шулай итмәгәндә *кильватер* белән *фарватер*ның буталуы бик ихтимал. Үземнең "ачы" тәҗрибәмдә дә андый мисаллар аз түгел (*полилог –полиглот).* Революциягә кадәрге вакыйгаларны язганда *полицийский* белән *жандарм* еш бутала иде. Мондый очракларда, хәтта белгеч язмаларында да өзекне эчтән кычкырып укып, мәгънә төсмерен тәмам төшенеп бетерергә кирәк.

Рәсми, хокукый, фәнни текстларда һәр сүз өчен җаваплылык тою фарыздыр. “Җинаятьчеләрне милиция бик тиз тапты... Берсенә –17, икенчесенә 18 яшь. Яңа гына мыек чыга башлаган *яшьүсмерләр*” (Ш.К., 1992, 2 окт.). 17 яшьтә кеше җиткән егет була, яшьүсмер – ул 12 яшьлек малай-кыз.

**Күнегү**

Хатаны аңлатырга, төзәтерә тырышыгыз: Шул рәвешле тикшерү эшләре башлана, *берничә суд* була (В.Т., 2010, 27 окт. К.Хәсәнева).

Сизгерлек югалмасын, “каешланмасын” өчен һәр гадәти (битараф) сүзне дә фикер иләгеннән үткәреп барырга күнегергә кирәк. Әйе, әйе, һәр сүзне фактик материал дип хис итәргә күнегергә! Беренче чиратта, вакытны, микдарьне, күләмне белдерә торган сүзләрне. Яңа ел башында басылган язмаларны күзәткәндә *быел* сүзенең *былтыр, узган ел* мәгънәләрендә булырга тиешлеген чамалавы кыен түгел. Димәк, *күптән түгел, әле кайчан гына, шушы араларда, бу көннәрдә* кебек сүз-гыйбарәләргә анализ барышында мәгънәви расшифровка ясый бару зарур. Чаманы конкретлаштырып бетермәү очракларына берничә мисал: “ М.Сафин – тырышлыгы белән хөрмәт казанган кеше. Ул менә *озак еллардан бирле* сарыклар карый (Маяк, 1984, 15 сент.); “Механизатор Л.Ихсанов чәчкечләргә үзе ясаган җайланманы көйләп, *байтак кына* ягулыкка экономия ясады (Маяк, 1984, 15 сент.); Газетның шушы ук санында *чиксез зур мөмкинлекләр, гаять зур мәсьәләләр* гыйбарәләре дә редактор анализының конкрет булмавына дәлилдер. Конкрет фактның тәэсир көче дә бөтенләй башка инде! “Мәймүнә апа алдыма төргәк-төргәк соры кәгазьләр, зур кулъяулыкка төрелгән орден-медальләрен чыгарып сала. 071775 БМ номерлы хәрби билетны актарам (С.Т., 1985, 4 апр.). Фактның конкретлыгы көчәеп, образлы, сурәт сыйфатында тәэсир итү көче дә бар; “Тәҗрибәле игенче, комбайнын туктатып, җиргә төште, әле генә бушатылгын салам өеменнән бер учма кибәк алып, камылларга җәелгән пинжәге өстенә коя башлады. Суктырылган башакларны, вакланган саламны җил очырды. *Биш* бодай бөртеге туп-туп итеп пинжәккә төште. “Бодай бөртеге авыр шул”, дип куйды өлкән игенче һәм тиз генә комбайн күперчегенә менеп, сигнал кнопкасына басты. Бераз вакыт узуга аның янына башка механизаторлар да килделәр. Ул аларга сүзсез генә бодай бөртекләрен күрсәтте. Барысы бергәләп кабаттан кибәк җилгәреп карадылар, киңәшкәч, комбайннарны яңадан көйләргә таралыштылар” (Авыл утлары 1992, 18 авг.);

– **сан,** әлбәттә, иң төгәл, иң саллы, иң тәэсирле фактик материал. Редакцияләү барышында аның бу сыйфатларын һич тә киметергә ярамый. Санны редакцияләүнең үз алым-чаралары бар:

– һәр фактик материалны документ-чыганактан чагыштырып карау мәҗбүри, яшь авторлардан хәтта фактлар алынган чыганакны күрсәттерү дә әхлактан тайпылу түгел. Югыйсә менә мондый хаталар китмәс дип

ышанып булмаячак: “Төзәтү. “Тамаша”ның 26 август чыгарылышында “Хәтерлим мин әле бүгенгедәй” дигән язмада хата киткән. Римма Ибраһимованың истәлекләрендә җырчының туган авылында мәктәпне дүртьеллык кына булган дип язганбыз...” (Т.я., 2006, 26 окт.);

– **сан мәгънәсен (төсмерен) белдерә торган сүзләр**: *шактый* чыгымнар сорый; Ринат Дасаев *моннан 18 еллар чамасы элек* үзенең беренче гаиләсе белән Испаниягә китеп барган иде...” (Т.я.). Кайчан киткән соң!?

Моннан *бер-ике еллар* элек “Татарстан яшьләре”ндә...; Моннан *ике еллар чамасы* элек мин Көнбатыш җәмгыятен яхшырак аңлау нияте белән Америка телевидениесенең яңалыкларына язылган идем... (Т.я., 2009, 17 ноябрь. Б.Хаков); Миңа моннан  шундый бер атеист милләттәш белән бер бүлмәдә *ун көн тирәсе* яшәргә туры килде (Т.я., 2010, 20 ноябрь. Б.Хаков);

Санны цифр белән һәм сүз белән язу аермасын тояргга кирәк “Бер курыккан эт *кырык көн* өрер диләр, бит (К.т., 1991, 7 февр.). *Кырык* монда саннан бигрәк *“күп вакыт*” мәгънәсендә; *Унсигезем минем унсигезем– яшьлегем*  мәгънәсендә; Бүген басуга *өч тәгәрмәчле* трактор  чыкты. *Өч* тәгәрмәчле трактор (асфальт җәя торган кебек) дип аңлашылмасын өчен *3* дип язарга мөмкин.

**Күнегү**

Кимчелекләрне төгәл аңлатырга, төзәтергә тырышыгыз:  Уйлары 165 сантиметрдан *югары* (Дулкын, 1999, 16 февр.); 2 сәгатьтән артык (күбрәк) көттем; Дөресе: Арча педколлиятендә 2000 елда 1146дан *күбрәк* студент укытыла”, диелгән (Энцикл. 1 т. 185 бит).; Сан янында тавтология: тугыз ай *эчендә*; Бер ел *вакыт эчендә;*

Фактик **материал чыганагы** ышанычлы булырга тиеш. Башлыча законнар, энциклопедия, хөкүмәтнең, дәүләти оешмаларның карарлары, аларның җыен, корылтай, конференцияләренең документлары, дәрәҗәле, абруйлы белгечләрнең чыгышлары, рәсми статистика оешмалары хисаплары һ.б. ышанычлы була. Чыганак ышанычсыз, шикле булса, анда теркәлгән фактка да шикләнеп карарга кирәк. Чыганакка бәя бирү осталыгы – һәр редакторның һөнәри сыйфатыдыр;

– теләсә кайсы санны, яисә аны алыштыра торган вакыт, күләм, чама берәмлекләрен, процентларны кабат укып, чагыштырып, санап-исәпләп (“бухгалтерия белән шөгыльнәнеп”), ап-ачык итеп **күз алдына китерергә** кирәк. Шулай эшләгәндә менә мондый китеклекләргә юл куелмас иде:

“Берәр бәйрәм булса, чәчне рәтләтер өчен *80–90 чакрым*дагы Брежнев, йә булмаса Түбән Кама шәһәренә барабыз” (К.у., 1984, №4, 141 б.);

“Игенчелеккә киңрәк керә барган интенсив технология – шул яңалыкларның берсе. Андый басулардан *50–60 центнер* уңыш алу бездә хәзер гадәти күренеш” (Календарь, 1988, 20 окт.). Гектарыннандыр?

“Авылда *ел саен 2 мең агач һәм куак утыртыла*” (Авыл утлары, 1984, 17 апр.). Бу авылда 320 йорт. Димәк ки, йорт саен 64 агач туры килә?!

“Сания Ибраһимовна сыйныфында *30 укучы*. Һәр иртәдә педагог дәрескә килеп керүгә, аңа (аңарга) *30 кызыксынучан күз текәлә*” (Т.я., 2004, 30 окт.);

Күренә ки, инде әйткәнебезчә, санны белдергән берәмлек белән аны ачыклый торган сүзләр дә фактик материалны тәшкил итә, аларга да игътибар сорала: төп эчтәлек белән чыгыштырырга, санап-исәпләп карарга һәм башка операцияләр башкарырга кирәк була. Әйтик, бер факт икенчесе белән чагыштырыла; вакыйганың атамасын ул булган дата белән, анда катнашкан шәхесләр белән бәйләп карарга; географик атаманы илдә, төбәктәге урыны белән бәйләргә; факт мәгълүмати детальләр белән дә тулыландырыла;

– иң мөһиме санның күләмен, зурлыгын аңда күзаллап бетерергә кирәк. Югыйсә укучы алдында оятка калырга, “Төзәтү” биреп, аңардан гафу үтенергә туры килүе ихтимал: Т.я., да (1996, 8 окт.) мондый фактик материал басыла: “Бәрәңгене Кукмарада беренче икмәккә тиңлиләр. Һәр елны диярлек Кукмара бәрәңгечеләре 2 шәр мең тонна күләмендә “икенче икмәк” сата... Соңгы нәтиҗәләр әле билгесез, әмма һәр гектардан уртача 135 әр центнер бәрәңге чыга, диләр. “Яңа тормыш” хуҗалыгындагы арендачыларда исә ул 275 центнер тәшкил итә”. Өч көннән соң газет менә мондый төзәтү бирергә мәҗбүр була: “Газетабызның 42 нче санында Кукмара районыннан язылган “Эшли белсәң, эш карышмый” дигән язмада хата киткән. Беренче абзацта һәр ел саен Кукмара бәрәңгечеләре 20 шәр мең тонна “икенче икмәк” сата, дип укырга кирәк”;

–фактик материалны әйтү белән язу арасындагы аерманы тоемлау әһәмиятле: Мәсәлән, *777000* санын ничек әйтергә? Азаккы өлешне *өч нуль* дию дөрес булмас, *өч тапкыр нульме?* Яисә радиодан көн торышын әйткәндә еш кына *1–3 градус*ны санау интонациясе урынына чама интонациясе белән әйтәләр. Өч градус чамасы (тирәсе) дигән мәгънә килеп чыга;

–**даталарны язганда** да эчтән кычкырып әйтергә күнегү әһәмиятле. *Мең дә тугыз йөз дә туксанынчы ел*. Болай эшләгәндә *1918* елның *1891* булып язылу куркынычы кими. Кычкырып уку гына җитми, “исәп-хисап ясау”да сорала. Шунсыз менә мондый “Төзәтү” бирүләрдән котылып булмый: “Төзәтү. Журналыбызның 10 санында басылып чыккан “Бөтен нәрсә сине хәтерләтә” дигән язмадагы “1986 елда әниемнең 90 еллыгын опера һәм балет театры “Травиата” операсын кую белән билгеләп үтте”,” ...Галия Кайбицкая 1983 елның ямьле май аенда минем кулымда җан бирде,” дигән җөмләләрне “...1996 елда әниемнең 90 еллыгын...” һәм “...1993 елның ямьле май аенда...” дип укырга кирәк...” (Сөембикә, 1997, №11, 15 б.). Монда ничә яшь дигән фактны туган елы белән тикшереп алырга кирәк булган;

– **“Төзәтү”** бастыру – ул редакция эшенә тискәре генә бәя. Ул редакторларның абруй-дәрәҗәсен төшерә торган факттыр. Төзәтү хатаны төзәтү чарасы булса да, ул инде ничарадан бичара гына, ул соңгы чиктә

генә аклану чарасы. Хәер, төзәтү бирүнең бүтән алымнары да була. Менә Т.я.нең 2004, 25 сент. санында башмәкаләдә мондый хата киткән: “Австралия милли университеты исәпләвенчә, 10 елдан ирләр, биологик зат буларак, бөтенләй бетәчәк...”. Шуннан соңгы санында (28 сент.) газет шул темага янә башмәкалә бастыра. Анда мондый текст: “Газетыбызның узган санында, хата китеп, 10 елдан ирләр бөтенләй бетәчәк, дигән сүзләр басылган. Дөресе – 10 миллон ел иде...”;

**– фактик материал буларак цитат, документтан өзек**не редакцияләү дә җитди, җаваплы шөгыль. Алар мондый сораулар куеп тикшерелә: цитат кирәклеме, урынлымы? Урынлымы, ягъни эчтәлеге ягыннан, нәтиҗә буларак әсәр эчтәлегенә тәңгәл киләме? Цитат авторы белән редакцияләнә торган әсәр авторы арасында каршылык юкмы? Автор бу цитатны ялгыш (ялган) фикерен раслар өчен файдаланмыймы? Цитат төгәлме? Моны чагыштырып кына белеп була. Ул тик оригинал белән генә чагыштырылырга тиеш.

Цитатның чагыштырмача бөтенлеген сакларга тырышырга кирәк. Ким дигәндә ноктадан ноктага алырга, өзгәләмәскә кирәк. Өзелә икән, моны искәртү зарур. Цитатны тәрҗемә итү-итмәү әлегә бәхәсле. Татарча текстта фикернең табигый агышына татарча чаралар белән генә ирешеп була. Татар теле теләсә кайсы телдән теләсә кайсы эчтәлекне тулы мәгънәле итеп күчерергә сәләтле. Берәр битле урысча цитатны тәрҗемәсез іүчерү – ул авторның һәм редакторның ялкаулыгыннан гына;

– Фактик хатаның зуры-кечкенәсе, әһәмиятлесе-әһәмиятсезе булмаган кебек аның сәбәбенең дә зуры-кечкенәсе булмый, бер хәреф-авазны дөрес әйтмәү (язмау) аркасында да җитди хата барлыкка килә. Фактларны барлаганда ук лингвистик фактор сүз (сүзтезмә)не дә хәтергә сеңдерергә, аны истә тотарга кирәк. Узган гасырның алтмышынчы елларында Африканың күренекле җәмәгать эшлеклесе Патрис Лумумба “теге дөньяга китте”. Аның үлеменең сәбәбен белдерү (*вафат булдымы* әллә *һәлак булдымы*) бөтендөнья бәхәсенә әйләнде – дөнья бер-берсенә каршы икегә ярылды. Кайсы сүзне әйтүгә карап, аерым кешеләрнең генә түгел, бөтен бер илләрнең, халыкларның язмышы кыл өстендә калды.

“Бөгелмә *вокзалыннан* салам төялгән 19 автомашина районнарга китте” дигән җөмләдә дә фактик хата “яшеренгән”: *станция* һәм *вокзал* терминнары буталган. Синонимнарны, вариант төшенчәләрне урынлы-урынсыз куллану еш кына фактик хатага китерә дә: *эштән азат итү* белән *эштән бушату* бер түгелдер – нинди сәбәп белән эштән китүе (үрләтелгәнме әллә куылганмы) дөрес сайланмаган сүз аркасында чынбарлыкка туры килми.

**Күнегү**

Әйтү белән язу нисбәтен сакламау аркасында җибәрелә торган хаталар – радио, телевидение, сәхнә сөйләме кимчелекләрен күзәтегез, сәбәбен аңлатыгыз, төзәтү чараларын күрегез:

– Мәскәү дикторы *манил* диде дә капыл туктап, *Милан* дип тиз генә төзәтте (1995, 14 гыйнв.);

– омофоннар барлыкка килә: Сузык аваз тарайса, *ник алай Николай*га әйләнә (Радиодан);

– кайвакыт орфография, орфоэпия кагыйдәләрен үтәмәүдән хата түгел, киресенчә, дөрес вариантка ирешелә: "Бәлки безгә карата үтенечләрегез, *дәгъвәләрегез* дә (кагыйдәчә *дәгъваларыгыз*) бардыр..." (Вакыт, 1991, дек.);

– станок-качалкаларны станок-*качалаклар* дип (татарчага тартымлап) әйттеләр (Яңа гасыр, 2002, 1 июнь);

– встреча Путина и *Бушина* (диде). Төзәтте тагы: *Буша* (Россия радиосы, 2004, 9 июнь).

**Кыскартуларда, аббревиатураларда китә торган хаталар**

*"Буккнига"* (китап кибете язуы); Ул Пәнжәр төбәгеннән Әгерҗе тимер юлы депосына хәтле булган арада *яркәмнәр (ярдәм кәмиссияләре)*, дружинниклар, активистлар оештырды (К.,у., 1977, №3, 28 бит. Г.Ахунов);

– хәтта аерым хәреф-авазлар, аерым иҗекләр дә хата чыганагы була ала: нәшрияттә эшләгәндә хезмәттәшебез Венера Шәриповага (календарь редакторы иде) бәйле бер күңелсезлек килеп чыкты. Аның *энесе* озак еллар урында чирләп ятып, үлеп китте. Газетка кайгынамә бирдек. Икенче көнне газетны кулга алып, нишләргә белмичә, телсез калдык: "...*әнисе* вафат булу сәбәпле" дип язылган иде.

Юк шул, факт дип танылган бу хәреф (аваз) иҗек, бер дә "вак", "кечкенә", "бәләкәй", "гөнаһсыз" түгел. Без инде "Сталингад" (бер хәреф) аркасында күпме редакторның "кара" язмышка дучар булуын искә алган идек. Сүзне дәвам иттерү үзеннән-үзе сорала. Шуңа күрә бу төр хаталарга "техник хаталар" (яисә "хәреф хатасы", яисә "күз" хатасы) дип атап, үзенә бер бүлекчә багышлау ихтыяҗы – табигыйдер.

## Техник хаталарның сәбәбе, аларны булдырмау алымнары

Мондый хаталар чыннан да очрый, алар укучыны борчый, уйландыра, тынгысызлый. Аларга юл куярга ярамый дигән фикерне һәр редакторда беркетергә омтылып, янә берничә мисал китерик:

"Иске Яңа елны озаткан төннәр. Чатнама суык төн. Этләр дә өрми, *мәчетләр* дә чинамый..."(Т.я., 2007, 22 сент.);

"...Утырышта "Пенсиягә өстәмә федераль түләү күләмен ачыклау өчен Татарстан республикасында *песионерның* 2010 елга яшәү минимумын

билгеләү” турында закон проекты беренче укылышта кабул ителде” (В.Т., 2009, 25 сент.).

Хәзер бу төр хаталарны тәртип-системага салып барлыйк, анализлыйк. Алар фикерләү барышы белән бәйләнмәгән, дөресрәге, уйланып бетермәү, эшләнеп җитмәү аркасында, үзеннән-үзе килеп чыккан, дип акланырга юл калдыра торган “техник”, “күз хатасы”, “хәреф хатасы” гына дип җавапсызлыктан тайпылырга сәбәп була торган хаталар. Алар күпчелек очракта, чыннан да, эш технологиясе, техникага сылтап була торган сәбәпләр аркасында яисә редакторның шәхси сыйфатларына да бәйле (холкы, табигате, психик һәм физик хәләте белән бәйле) сәбәпләр аркасында киткән.

– **хәреф (аваз) хаталары:**

Бер хәреф урынына икенче бер хәреф языла һәм басыла. Гадәттә хата язылышы һәм әйтелеше белән охшаш хәрефләрдән гыйбарәт (*н* урынына *ң*, *х* урынына *һ* һ.б.): “... Билгеле инде, *аңа* кеше (*ана* урынына) барысын да сөйләп бирә алмый (Х.Сарьян. Уеңны уйдырып сал,,,, 120 бит).

*Роль* артындагы шофер (*руль* урынына). Бу пароним, парономас күренеше – әйтелеше, язылышы белән охшаш, әмма мәгънәсе белән аерым морфема, лексемалар барлыкка китерә торган хата. Бу төр хата аеруча алынмаларда, беренче чиратта гарәп алынмаларында, китә. Мин гомер бу студентларны кисәтә киләм: Мин *Мәлик* малае дим, урысчадан алып, *Малик* улы дисәгез, имтиханда уңай бәя алырмын димәгез. Икесе ике мәгънәле сүз: Мәлик – мәмләкәт башлыгы, патша, солтан, ә Малик милек иясе, тәмугта гонаһлыларны җәзалау кирәк-ярагы склады хуҗасы; *Зарбә* – каршы бәрү, отпор бирү, *зәрбә* – үсемлек; *нәшер* – китап бастырып тарату эше, *нәшир* – шул эшне җитәкләүче; Бездә бихисап алынма бер хәреф аркасында мәгънәви хаталыга әйләнеп китә: *махсус –мәхсүс, табыйб – тәбиб, талибә – талыйбан* һ.б.

Гарәп алынмаларының төрле вариантта язылу мөмкинлеге очраклы хаталарга (чыннан да “техник” хаталарга) сәбәп була*: һаләк (һәлак* урынына). *агъзә (әгъза* урынына), *балә (бәла* урынына), шәхсән үзем гап-гади *бәрәбәр*не бер текстта ике-өч төрле язам (*бәрабәр* (орфография кагыйдәсендә каралганча), *барәбәр, барабәр* һ.б.

Алынмаларны язу (әйтүнең) орфография һәм орфоэпия кагыйдәләре алфавит камил булмаганга һәм күптән үзгәртелмәгәнгә күрә, хаталарны арттыруга гына хезмәт итә: Күптән инде *сәләм, сәләмәтлек, фатыйха, вазыйфа, хәләт, Исхакый, икътыйсадый, кәсәфәт* һ.б.дип язарга вакыт та бит, (кайбер кыю басмалар уңай адымнар ясаса да), юк шул, сөрсеп беткән орфография кагыйдәләре барыбер кулдан тотып тора;

– сүз эчендә янәшә урынсыз хәреф өстәлә: *бала* тоткан кулы (*балта* урынына); Мондый төр хаталарны аңлатып була. Әлеге очракта “бала тоткан”ны язганда язылачак *тоткан* сүзенең *т*-лары алдан ук тәэсир итеп, *бала*га өстәтә, *балта* барлыкка килә. Сүз белән уйлау механизмының

табигате шундый. Мәсәлән, татарча уйлап, татарча әйтеп *күз* дип язуга күнеккән редакторның яисә хәреф җыючының шуңа охшаш сүзне (мәсәлән, кузничная урамын) *күз*ничная дип язуына аптырарга кирәкми (С.Т.,1984, 7 июнь);

*Әһәмият* урынына бернинди сәбәпсез әдәбият дип язганмын. Хәер, сәбәпсез берни булмый – әдәбият сүзе ешрак кулланам, күрәсең, шуңа күнегелгән. Аннары текстта шул тирәдә *-ият* иҗеге булмады микән, шул тартмады микән?

Берәүне тәнкыйть иткәндә *хуплап* диясе урынга *хурлап* дигәнмен. Нишләп? Үзем дә аңлата алмыйм.

Гомер буе машинкада (компитерда) *очекр* дип бастым (дөрес язсам да);

– артык хәреф өстәлә. Сәбәбе: хәреф хәрефне тарта: “Каравылчылар белән тулы автобусны аның өчен *җибәрәгәннәр* (Т.я., 2007, 10 ноябрь);

– сүз эчендә янәшә хәреф төшеп кала. “Рус телендә аныкланмыш белән аныкла*н*гыч (*аныклагыч* урынына) булган сүзләрнең үзара мәгънә мөнәсәбәтен татар телендә тәрҗемәдә шунсыз биреп булмый (Р.Сибәгатевнең тәрҗемәдә хата җибәрмәү турындагы китабыннан, 58 б.).

“Профессиональ *сәнгатьче”* урынына *сәгатьче* киткән (диплом эшендә)

Хикмәт бу хәрефләрнең күзгә ничек ят булып тоелуы гына түгел, ә ул гайре табигый форманың мәгънәви хатага китерүе. Менә бу мисалларны анализлап карагыз әле:

Мөхәммәт Мәһдиевнең “Ачы тәҗрибә” китабыннан бер гыйбрәтле хатага игътибар итегез (Китапны бит әдип үз кулы белән язган, үз кулы белән редакцияләгән дә иде. “Ул *кафедра* (*кафеда* урынына) даими рәвештә чех сырасы “Плзень” була”; Диңгезче журналист-публицист Вахит Юнысовның “Давыллы диңгездә бер утрау...” дигән язмасыннан: “Мәскәү урамнарындагы телефон-автоматтан шылтыратырга ниятлим. Тик ... күбесенең *рубкалары* (*трубкалары* урынына) тамырлары белән йолкып алынган” (Т.я.,1992, 18 гыйнв.). Бу хатаның сәбәбен “диңгезче Мәскәүдә дә рубкадан аерыла алмаган” дип шаярып аңлатырга да булыр иде, тик мәсьәләгә җитди килгәндә, моны фәнни аңлатуы кыен, аптыраудан елмаерга гына кала...

Заманында журналист-редактор Тәлгат Нәҗмиев шундый төр хаталарга редакторларның игътибарын юнәлткән иде: бер хәрефнең алмашынуы аркасында киткән менә мондый хаталары хәтергә уелып калган: *бала-бака, эш-эт, Азат хатын– таза хатын, сынады-сылады, Хуйбышев* һ.б.;

– сүз эчендә хәрефнең (авазның) урыны үзгәрә: йә алга, йә артка күчә. 1) хәреф төшеп кала – хәтта мәгънәви кимчелек барлыкка килә: Татар *журналисткасы* (*журналистикасы* урынына); 2) сүз эчендә артык (урынсыз) хәреф өстәлә. Үзем гомер буе бер хатадан арына алмадым – *мәсәлән* сүзен нечкәлек билгесе өстәп яздым (*мәсьәлән*) . Сайланма әсәрләремнән тупланган “Мәхәббәт хакы” китабында шул хата киткән. Бик

ачынып, нигә төзәтелмәгән соң!? дип өзгәләнгәндә, санадым: унбиш кеше – иң күренекле редакторлар "сизмәгән" булып чыкты. Үз кулың белән хата җибәрдеңме, кемдер төзәтер дип бервакытта да, беркайчан да ышанма, өметләнмә!

Менә янә берничә "хәреф" хатасы. "Хәреф" хатасы гынамы!? *Тапшырырга –таптырырга; зирәк – зирек.* Алардан бит аерым кешеләргә карата тискәре фикер туа. Утызҗиденче еллар булсамы...

– күп очракта техник хаталарны "техникага" сылтау акланмый, сыныкка сылтау гына, күпчелеге грамотасызлык, наданлык аркасында киткән булып чыга: редактор теге-бу сүзнең мәгънәсен белми (*каралту– карайту, сөрлегү-сөртенү, аз – әз, әзерләү – хәзерләү, ачы – әче* һ.б.). Сингармонизм законын, татар теленең агглютинатив тел буларак үзенчәлекләрен белмәү белән бәйле хаталар да бихисап :*фаҗигага* (*фаҗигагә* урынына) (Т.я., 1991, 16 февр.), *вакыйганы (вакыйгане* урынына); Шулай итеп идарәдә бердәнбер түләүле штат – сәркатип *кына* (*кенә* урынына) кала (Т.х., 1991, февр.).

– кабатланган хәрефләр бер-берсен тартып китерә: Каравылчылар белән тулы автобусны аның өчен җибәр*ә*гәннәр (Т.я., 2010,10 ноябрь); "Үзен әйләндереп алган"ны язганда "*үзәен*" дип язылган; Охшату хатасы. Яисә пар наратны *пар нанат* диелгән, ник? Чөнки *пар канат*ка күнегелгән; *Вәхшилек – вәхишлек*;

– әйтү–язу хаталары арасында да "техник" хаталар бихисап. "Марат Әхмә*тов*";

– күз хатасы белән колак (ишетү) хатасы үрелеп китә – редакторның сизгерлеге тоныклана: Базарда ачкыч ясаучы карт *ларегында* төрле-төрле ачкычлар эленеп тора. Тик торганда шуны *лагерында* дип укыдым; *Гамәлсез* галим – *Галәмсез* галим; *Агро*промышленность – а*рго*промышленность; *милит*аризм – *миллит*аризм; *укылышта* – *утырышта*; татар *редактор*лары – *радиатор*лары; *колхоз – колзох* (язуда); *протест – протез;* иртәгә *очрачканчыга* кадәр (Татар радиосы, 1902, 4 март).

**Техник хата дип "чын" хатаны аклау очракларына мисаллар:**

Карбыше*ва* урамыннан килгән хат, ди Татар радиосы (2002, 4 март).

Бер җырда ук: Син *табарсың* мине...; Син *табырсың* мине... (Радиодан).

*Статистлар* (статистиклар урынына) ("Татарстан" радиосы);

**Басым законы бозылу сәбәпле китә торган хаталар**

*Уры́нбасар* (Яңа гасыр радиосы, Марсель Насыйбуллин); *Ба́шкалабыз* ("Татарстан" радиосы. Тәлгат Хәмәтшин)

**Ижек язылышында (әйтелешендә) техник хаталар**

– иҗектә сүз тәртибе үзгәрә: хәрәкәттә – бә*кәр*әт; *препарат – препатор, пароход – пародох. әдәбият – әбәдият* һ. б; Бу очракта да "техник" хата булып кына калмыйча, җитди мантыйкый кимчелек хасыйл булуы да бар:

*урам – урман*; “...семантик *яткан (яктан* урынына) ясагычлы нигез ул кушма нигез белән бер төрле үк бурыч үти” (Тел дәреслегеннән); “... Шул вакыт “спецмедслужба” *машина*сы килеп чыкты. *Мишана*га утырырга теләмәгән исерекләрне, көч кулланып, утыртып алып китәләр (С.Т, 1984, 17 февр.); “Тамак ялгау максаты белән ашханәгә *сулыгу (сугылу* урынына) гына барып чыкмады (Туган як, 1991, 23 авг.); Бер текстта рәттән ике тапкыр *Сөйләйманов* дип язылган; Рашат Сафин “Азатлык” радиосында “коралларга *дәгъва* итәләр” дигән фикерне “*вәгъдә* итәләр...” диде; “*Верена (Венера* урынына) ханым, укучыларыбызга нинди теләкләрегез бар?” (Ш.К., 2002, 20 сент.); *Бөртек – бөркет* дип языла һәм укыла (әйтелә); Давыт Юлтый *Дултый* дип язылган иде. Мондый төр хата, гадәттә, таныш булмаган сүзне тексттан күчереп язганда яисә цитат китергәндә җибәрелә;

– җөмләдә янәшә сүзгә иярепме, мәгънәдәш берәмлекләр хәтердә яңарыпмы, иҗеккә омоним өстәмәләр барлыкка килә яисә төшеп кала: *референдром (референдум* урынына), *интернант (интернат* урынына; гадәттә хәрби терминнар белән эш иткән кешеләрдә китә (Фәндәс Сафиуллин), чөнки алар интернант, комендат сүзләренә күнеккән була; *гиппотам (гиппопотам* урынына); Яисә артык китә: *тенисистчылар* (“Азатлык” радиосы);

-*лар*/-*ләр* тавтологиясе: Болардан тыш та утырышта күп кенә сорау*лар* каралачак; Тыңлаучыларның игътибар*лар*ын шуңа юнәлтәбез (“Татарстан” радиосы);

Фәндә бу күренешләр элизия, аплография, диттография һ.б. дип йөртелә.

– язуда сүзләрне юлдан юлга күчергәндә барлыкка килә торган мәгънәсезлек, буталчыклык, өтеклекләрне дә җитди хаталарга санарга кирәк. Болар соңгы вакытта аеруча ешайды, аларга карата укучылар ризасызлыгы артканнан-арта бара: деле*–гат*, дәф*–тәре, гад*–әти, бам*–бук, тыч*–кан, *күт*–әренке.; яшел*–чәче; Ир–кутск* һ.б. Мондый төр хаталарга грамматик нормаларны, орфография һәм орфоэпия кагыйдәләрен үтәмәгәндә китә торган китеклек-кимчелекләр дә карый: “Формаль яктан караганда, ФБРның АКШтан *тышта* (-*та* кушымчасы ялгыш кушылып язылган) разведка эше белән шөгыльләнергә вәкаләте юк”; *Берук* вакытта; *Бер үк вакытта* урынына; *Бердән бер чара – бердән-бер чара* урынына;

**Җөмлә эчендә сүз бәйләнеше (сүзнең урыны) белән бәйле “техник” хаталар**

– ике сүз бәйләнешендә: а) тартык авазлар йә саңгыраулана, йә яңгыраулана (аллитерация): “Хәер, әллә ни хәсрәткә тарырлык хәвеф юк та кебек, ә шулай да күңел борчыла, *эш поша* (К.у., 1975, №9, 5 б.); ә) сузык авазларның бер-берсенә тәэсир итүе аркасында (ассонанс күренеше); б) сингармонизм законынына буйсынып, тәртип үзгәрә:

– ике сүз бәйләнешендә өстәмә мәгънә төсмерләре (контекстка бәйләнмәгән, хәтта хата мәгънәгә әверелгән, язарга ярамаган, әдәпсез төсмерләр барлыкка килә (... әмма өлкән класс укучыларын мавыктыру

өчен *бу гына* аз (С.Т., 1987, 26 ноябрь). Аларның ике*се генә* имтиханны тапшыра алган (Радиодан). (Гафу итегез, боларны кычкырып редакторлар дәресендә генә әйтергә ярыйдыр);

– бәйләнештә ялгыш (авыр) әйтү ихтималы: Мәдрәсәләребез*дә дә*ресләр бара.

**Техник хаталарны җибәрмәү, алардан котылу юллары**

– текстны кычкырып уку (эчтән генә дә кычкырып уку була); а) ялгызың кычкырып уку; ә) ике кеше кычкырып уку (корректорлар укуы тәҗрибәсе); Профессионаллар моны артикуляция белән хатаны төзәтү, диләр. Бу чара юлдан-юлга күчергәндә дә хата җибәрмәс өчен бик кирәкле;

– ят почерклы язманы укыганда аеруча сизгер булырга кирәк. Авторга почеркын яхшыртырга киңәш итү дә зарур;

– текстның өстенә йә астына кәгазь куеп укырга була. Карашны каләм белән йөртеп укырга – каләм карашка алга "чабарга" ирек бирми. Гадәттә, язганда да, укыганда да караш алда торган сүзгә текәлергә ашыга. Миңа "Кызыл таң"да "Сталингад" хатасын җибәреп, ун ел утырып кайткан Рәхим Ризванов абый белән эшләргә туры килде – дежур торганда корректураны ике лампа яктылыгына куеп кызыл карандаш белән һәр сүзгә сызып укый иде.

## *Сигезенче тема*: Текстның композициясен төзәтү

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Әсәрдә эчтәлек һәм форма бөтенлеге. Авторның идея, тема максатына форманың муафыйк булырга тиешлеге. Эчтәлек, жанр таләпләре. Эчтәлеккә, нинди адресатка багышлануына карап текстның күләме. Аны көйләүдә, нисбәтен дөресләүдә редакторның роле.

Текстның бөтенлегенә ирешүдә мантыйк законнарына таяну, сөйләм оештыру кагыйдәләрен үтәүнең әһәмияте.

Композиция, сюжет төшенчәләренә редактор карашы. Бу төшенчәләрнең матур әдәбият, журналистик-публицистик әсәрләрдә, матбугат, радио, телевидение хезмәткәрләре иҗатында үзенчәлекле чагылышы.

Текстның эчке төзелеше. Кереш, төп өлеш, йомгак. Бу өлешләрнең нисбәте. Хилафлыкны бетерү алымнары. Текст бөтенлегенә ирешүдә башлам, очлам (бетем), баш исеме, эпиграф компонентларының әһәмияте.

Сәхифә, рубрика. Кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф, пункт, матдә, кызыл юл төшенчәләре. Газет, журналда текст төзелеше, сәхифә, рубрика.

Эчтәлеккә тәңгәл форма табу, әсәрнең план-проспектын төзү барышында редакторның авторга булышуы. Бу юнәлештә осталык алымнары, тәҗрибә.

Текстта иллюстрация материалларын (сурәт, фото, клише һ.б.) урнаштыру, төзәтү. Рәсем асты тексты. Бу эштә кимчелекләр, аларны бетерү юллары.

Редакцияләнеп, укучыга тәкъдим ителә торган теләсә нинди язма әсәр,– нәфис-сәнгати әдәбияткә карыймы ул, әллә фәнни яисә иҗтимагый-сәяси әдәбият төренә карыймы,– ул иҗатның бербөтен, мөстәкыйль нәтиҗәсе булсын дисәң, ул эчтәлек һәм форма бердәйлеген хасил итәргә тиеш.

Эчтәлек – форма бердәйлеге әсәрнең барлык якларын колачлый, икенче төрле әйткәндә, әдәби-сәнгати әсәр барлыкка китерү үзе ул эчтәлек белән форма бердәйлегенә ирешүдән гыйбарәт тә. Формасыз эчтәлек, эчтәлексез форма була алмый, чөнки әсәр ул эчтәлек белән форманың диалектик кушылмасыннан, аларның бер-берсенә ярашуыннан гыйбарәт. Димәк ки, эчтәлек – әдәби әсәрнең нигезе, аның асылы, ә форма – эчтәлекнең яшәү рәвеше (Х.Госман, З.Мәҗитев. Әдәбият теориясе, Казан, 1980, 9 бит).

Әдәби әсәрдә эчтәлек беренчел, әйдәүче як булса да, үзенә лаеклы форма табылганда гына ул яшәеш ала, әсәрнең эчке бөтенлеге шул вакытта гына хасил була. Иҗат процессы асылда берүк эчтәлекне һәм шуңа муафыйк форманы эзләү ул.

**Нәрсә ул форма?** Галимнәр фаразлаганча, эчтәлекне тулы, төгәл гәүдәләндерү өчен әдәби әсәрнең формасы сәнгатьчә бөтенлеккә ия булырга, төзек булырга тиеш, ягъни анда образлар системасы да, әсәрнең гомуми төзелеше һәм сюжеты да, тел һәм стиль чаралары да әсәрне бербөтен итеп төзү максатына буйсынган булырга тиеш.

Классик язучы Лев Толстой болай дигән: “ Чын сәнгать әсәрендә – шигырьдә, драмада, рәсемдә, җырда, симфониядә – бер шигырь юлын да, бер күренешне дә, бер фигураны да, бер тактны да үз урыныннан алырга һәм бөтен әсәрнең мәгънәсен бозмыйча икенче урынга күчереп куярга мөмкин түгел; нәкъ менә бер әгъзасын алып, икенче җиргә утыртсаң, органик нәрсәнең тереклеген бозмый калып булмаган кебек үк (Полн.собр.соч, 3 т. М., 1951, 31 б.).

Бу үзеннән-үзе аңлаешлы тезис-аксиоманы, хакыйкатьне икърар итү кирәкме? дигән сорау бирүче дә булыр. Табигать яралткан агачның эчтәлеге-асылына бәрабәр формасы-рәвеше бар, нинди төстә-расада булуына карамастан адәм баласының да бер форма-рәвеше булмый калмый. Шуның кебек, акыл нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән язма әсәрнең дә барлыкка килү, яшәү рәвеше гомумкешелек күзаллавында формалашкан, күнегелгән рәвеше булырга тиештер бит. Ул чыннан да бар: әдәбият теориясендә “композиция” дигән категория хәтта мәктәптә үк өйрәнелә, теләсә кайсы белешмә-энциклопедиядә бу хакта мәгълүмат табарга була. Татар халкының да экият, бәет, мөнәҗәт, дастан кебек жанрларының төзелеш-композициясе халык аңында гасырлар буе формалашып, мәгълүм бер тәртип-система буларак буыннан-буынга күчә килә. Аны тагын нигә, ничек редакцияләргә!?

Шулай да, шулай да ... Сиам игезәк балалар, ике башлы яисә өч аяклы бозау тууын ишеткән бар; очын яшен сугып, ике үзәкле булып үсеп киткән агачларга юлыгабыз. Әсәрләргә карата да гайре табигый. ягъни стандартларга, таләпләргә буйсынмаган композицияле әсәрләр "тууы" табигыйдер. Редакторның бурычы шундыйларны табигый халәткә китерү.

1922–1925 елларда шигъриятә ак шигырь (ягъни катгый классик формага буйсынмаган) поэтик әсәрләр белән мавыгу чире булып ала. Ул Кави Нәҗми, Гадел Кутуй кебек татар шагыйрьләренә дә йогып куя. Көнбатышта таралып, Россиягә дә тәэсир иткән футуризм, имажинизм кебек күренешләр, башлыча, эчтәлек белән бәйле булса да, алар шул ук вакытта эчтәлек белән форма бәйлелегендәге дисгармониягә кайтып кала.

Шунысы игътибарга лаек: татар әдәбиятендә вакыт-вакыт пәйдә булып алган мондый тискәре күренешләрне беренче булып нәкъ менә татар редакторлары тәнкыйть итә – 1914 елда ук әле футуризм шаукымына "Йолдыз" газетында Ф.Сәйфи-Казанлы күрсәтә, Г.Кутуйның егерменче елларда басылган "Футурист", "Базарда җан сатам" дигән шигырьләрен истә тотып, Ф.Бурнаш бу күренешне "Илһам" комедиясендә тәнкыйть утына ала.

Эчтәлек һәм форма арасындагы берлектә эчтәлекнең әйдәүче роль үтәве, актив булуы форманың әһәмиятен, дәрәҗәсен һич тә төшерми. Эчтәлеккә яшәү рәвеше бирүче форма – әдәби иҗатта үзе дә актив бертмлек. Шуңа күрә редакцияләү барышында да аңа игътибар ким булмаска тиеш.

Форма камиллеге – ул кешене тормышчан тасвирлау; әсәрнең жанр таләпләренә җавап бирүенә ирешү; композициянең милли үзаң традицияләренә җавап бирүе, шигырьдә – ритм, рифмика, прозада – агыш, аһәңнең чын милли булуы; эчтәлеккә муафыйк сөйләм; традицион тел нормаларының традициядә береккән кагыйдәләргә, тел законнарына җавап бирүе һ.б.

**Композиция** нәрсә ул? Латыйнчадан (compositio) – төзү, теркәү, тәртипкә китерү. Әдәби әсәргә карата ул әсәрнең төзелеше, образларны ачу, оештыру, бер-берсенә бәйләү чаралары. Бу төшенчә әдәби әсәргә карата, беренче чиратта, жанр, сюжет төшенчә-терминнары белән дә бәйле. Әсәрнең камил төзелешенә, эчке бөтенлегенә эчтәлекнең төгәл формалаштырылуына язучы теге яки бу жанрның, жанр формасының үз закончалыклары кысасында ирешә. Икенче төрле әйткәндә, бу бөтенлек **жанр** таләпләренә нигезләнеп, әсәрнең композициясе һәм сюжеты уңышлы төзелгән вакытта гына тудырыла. Композиция дигәндә үзеннән-үзе жанрны күз алдына китерергә күнегелгән. **Сюжет** исә әдәби әсәрнең хәрәкәтләр эчтәлегеннән гыйбарәт булган вакыйгалар системасы (Словарь литературоведческих терминов, М., 1974, 393 б.). Аны алда әле ачыграк күзалларга тырышырбыз.

Композицияне редакторлык эшчәнлегенә турыдан-туры караган категория буларак күзалласак, без аны образларны бер-берсенә бәйләү,

вакыйгаларны төп максатка ярашлы итеп урнаштыру, әсәрнең барлык элементларын сәнгатьчә оештыру процессы дип аңларбыз.

Композиция, ягъни әсәрнең төзелеше – катлаулы берәмлек, ул күп төрле алымнар, чаралар ярдәмендә корыла. Нинди алымнарга, нинди чараларга мөрәҗәгать итү, барыннан да элек, әсәрнең материалына, ягъни сурәтләүгә алынган объектларга, шул нигездә жанрга бәйләнгән.

Әсәрдә аның беренче җөмләсеннән алып соңгы сүзенә кадәр барлык элементлар оештырыла. Җөмлә димәктән, композициягә бәйле редакторлык эше – төзәтү әлеге дә баягы композицияне күзәтү, бәяләү, камилләштерү җөмләдән башлана да инде. Гәрчә һәр җөмлә синтаксик таләпләргә буйсындырылып сөйләм максатын үтәү өчен автор тарафыннан ук дөрес, камил “корылган” булырга тиеш тә бит, нишлисең, өч аяклы бозаулар туган кебек, хәбәре алдан иясе арттан язылган инверсив, гайре табигый җөмләләр дә “туып” тора. Шулай булгач, редактор бөтен әсәрнең тулылыгына һәр җөмләнең камиллегенә таянып кына ирешә ала – йортның, корылманың бөтен конструкциясенең, архитектурасының камиллегенә һәр бүрәнәнең, һәр ниргәнең дөрес салынуына ирешә барган кебек.

Димәк, композициянең беренчел, төп вазыйфасы – материалны оештыру. **Материал** дигәндә без әсәрдә сурәтләнгән барлык өлеш-компонентларны, ягъни эчтәлеккә (тема, проблема, идея) һәм формага (әсәрнең төзелеше, сюжеты, сурәт-тасвир чаралары системасы-тәртибе) каралган барлык нәрсәләрне кертәбез.

Дөрес анысы: эчтәлек һәм форма материалын оештырган вакытта, беренче чиратта, нәфис әдәбият жанрларын иҗат иткәндә, язучы әсәрнең тулы, төгәл, бөтен булуына ирешергә тырыша. Моны иҗади максат итеп куя. Ягъни әсәрдә бернинди җитешсез як – артык детальләр дә, җитешмәгәне дә калмаска тиеш. Һәр кисәкне, һәр элементны кирәкле күләмдә (эчтәлек таләп иткән нисбәттә) тиешле пропорция белән генә кертергә кирәк була. Монда әсәрнең жанрына карап нинди кисәк-өлешләрдән торуын яхшы белү сорала. Кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф, пункт (статья), матдә, микротекст, макротекст, синтаксик бөтен, җөмлә (күләм-төзелеше ягыннан төрле характердагылар: катлаулы, кушма, иярченле, тезмә һ.б) сүзтезмә (синтагма), сүз, кушымча, иҗек, аваз (хәреф) һ.б. тезелмәләрне ачык күз алдына китерергә, һәр төр тезелмә категория-берәмлекне физик корылма итеп кенә түгел, образ-сурәт итеп тә күзаллау сорала – әгәр тәрәзәләр яисә ишек артык зур булып, йорт үзе бәләкәй булса дип күзаллау кызык, гыйбрәтле бит.

Язучы үзе бу таләпләрне үтәгән булырга тиеш тә бит. Әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр аларны шулай эш итәргә омтылсыннар дип тырыша. Теория (нәзәрият) дә татар язучыларын да шулай өйрәтеп килгән. Алар да В.Белинский таләпләренә туры китереп өйрәтәләр: “Әдәби әсәрдә барлык әгъзалар бердәм организм, бөтен бер зат барлыкка китерәләр. Табигать тудырган барлык камил нәрсәләр кебек... сәнгать әсәрләрендә дә

төгәлләнеп бетмәгән, җитешмәгән нәрсә дә, артык әйбер дә булмаска тиеш, һәр образ зарурый, һәм үз урынында булырга тиеш (Полн.собр.соч., М., 1957, 200 б.).

Материалны урнаштыруда күләм-чама, пропорция ягы да истә тотыла. Әсәрне укыганда без кайбер эпизодларның җентекләп сурәтләнүен, кайберләрендә исә “эштер-өштер”, ашык-пошык, йөгертеп узылуын, кайвакыт эре планда, ә кайвакыт вагайтылып тасвирлануына юлыгабыз.

**Әдәби (сәнгати) әсәрдә композиция**

Язучы үзе әсәренең төзелеш-композициясен ничек күз алдына китерә? “Кыска хикәя башта җыр булып яңгырый. Беренче фразаны кәгазьгә төшергәч, мин аны эчтән әйтеп, ишетеп карыйм. Фразалардан кызыл юл оеша. Кызыл юллардан – бүлек. Бөтен бер хикәя пәйда була. Ул нота нотага теркәлгән кебек укмаша. Менә сиңа композиция. Шулай да аңа әле оранжировка ясарга, өлешләрнең нисбәтен тәртипкә китерергә кирәк була. Монда да башта – күз, дөресрәге хәтер, аннары инде тыңлау...” (Николай Никитин. Как мы пишем. М.: Книга, 1989. С.96).

Образга корылган, сюжетка нигезләнгән әсәрләрдә образлар бер-берсе белән төрле рәвеш, чаралар белән бәйләнешкә керә. Аларны тасвирлауның бөтен бер системасы, төркемнәре “үреләә”. Редактор менә шул җепне очыннан азагынача сизгер күзәтә барырга, йомгакны, “кызыл җеп”не кулдан ычкындырмаска тиеш. Кайсы моментларга аеруча игътибар итәргә?

Әсәрдә текст тукымасына кайсы персонажның кайчан килеп керүе, нинди төстә, тонда, күләмдә тасвирлануы-күрсәтелүе, башка персонажлар белән нинди нисбәттә бәйләнүен чамада тоту бик әһәмиятле. Әдәбият теоретиклары болай ди: Образны яисә характерны төгәлләнгән бер бөтен итеп оештыру эшен образ композициясе башкара. Г.Бәширевнең “Намус” романында, мәсәлән, Зиннәт образы әледән-әле пәйда булып тора. Һәр очракта ул Нәфисә образы белән бәйле – ул аны ача, тулыландыра, бөтенәйтә.

Сюжет элементларын, сюжет сызыкларын дөрес чиратлаштыру да – композициянең эзлеклелеген, тулылыгын саклау алымы. Редактор моңа да сизгерлеген сүрелдермәскә тиеш– вакыйганы тасвирлау эзлеклелеге өзелүе, берәр очраклы чигенеш килеп чыгуы, кабатланган күренеш-сурәт барлыкка килүе ихтимал.

Хикәяләүне кем алып баруына да укучы игътибарлы. Чөнки вакыйгаларга, персонажларга хикәяләүченең мөнәсәбәте аларга үзенчәлекле төсмер бирүе бар. Персонаж сөйләме белән автор сөйләме яисә уртак сөйләм бер-берсеннән аерылырга, укучы аларны бутамаска, буталчыклык, ”томан” килеп тумаска тиеш.

Матур әдәбият әсәрендә **сюжет** дигәндә әсәрнең буеннан-буена редактор игътибарыннан төшмәскә тиешле элементларын кыскача санап кына китик:

– экспозиция – персонажларның конфликт туганга кадәрге хәлен тасвирлау, анда геройларның үз-үзен тотышы мотивлаштырыла;

– төенләнеш;

– вакыйга үстерелеше;

– кульминация – әсәрдәге вакыйгаларның, көрәшнең иң югары ноктасы, проблеманың иң үткенлеге;

– чишелеш – сурәтләнгән конфликтның тәмамлануы һәм куелган проблеманың чишелеше (хәл ителүе);

– пролог – баш сүз әйтелә, проблема куела;

– эпилог – соңгы сүз, йомгак тасвирлана, чишелеш үзгә бер формада бәян ителә;

– сюжеттан тыш элементлар: лирик чигенеш; өстәмә эпизодлар; портрет белән тасвирлау; пейзаж белән тасвирлау; каймалап алу (әйтик, Әмирхан Еникинең "Җиз кыңгырау " хикәясенең башламындагы кыңгырау образы әсәрнең урта бер җирендә дә, очламында да кабатлана).

Менә бу әдәби категорияләр әсәрнең композициясен укучы зәвыгы, аның таләпләре югарылыгында камиләштерүдә әһәмиятле чаралардан санала. Яшь редактор бу юнәлештә гамәли күнегүләр тупларга тиеш.

**Журналистик әсәрләрнең композициясе**

Документаль нигездә иҗат ителә торган публицистик-журналистик әсәрләрнең композицион нигезен мантыйкый дәлиллелек, эзлеклелек, система-тәртип тәшкил итә. Бу төр әсәрләргә жанр ачыклыгы, катгый композицион төгәллек зарур, чөнки реаль, документаль вакыйганы, конкрет характерны бәян итү өчен ул сурәтлерәк, тәэсирлерәк, җиңел аңларлык, күз алдына ачыграк (аныграк), хәтергә тирәнрәк сеңеп калырлык булуы зарур. Моның өчен андый әсәрләрнең дә композиция-төзелеше алдан уйланган, сызылган, оештырылган, материал мантыйкый яктан текстта дөрес нисбәттә урнаштырылган булуы таләп ителә.

Редактор анализы әсәрне ике юнәлештә тикшерә, дидек: эчтәлеге һәм формасы, ягъни төзелеше (асылда композициясе) яссылыгында. Төзелеш-структур анализ барышында материалның өлешләре, һәркаюсының эчтәлеге; темасы; проблемасы; күләме; кемгә адреслануы; нинди шартларда үтәлүе һ.б. ачыклана;

Редактор мондый төр әсәрнең үзен укыганчы ук аның эчтәлеге белән таныш була, чөнки нәшрият планлаштырганда ук автордан аның план-проспектын таләп итә. Яисә бу әсәрне планлаштыру тәкъдимен редактор үзе үк ясый. Шуңа күрә ул үзе бу әсәрне язу барышында ук катнаша дияргә дә була. Монда иң әһәмиятлесе, редактор әсәрнең эчтәлеге белән бергә формасын да ачык күзаллый бара, беренче чиратта, аның жанр кысаларын һәм сыйфатларын күз алдына китерә. Бу аңа алга таба – әсәрнең текстын редакцияли башлагач, җиңеллекләр китерә, вакытны исраф итмәскә, автор белән конфликт-каршылыксыз эшләргә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә, әйтик, Татарстан китап нәшриятендә социаль заказ белән китап бастырып чыгаруның уңай ягы нәкъ менә булачак китапның нинди жанрда булуын

редакторның алдан ук күзаллап куюы редактор эшен (композициягә бәйле мәсьәләләрнең чишелешен) күпкә җиңеләйтә иде.

Композицияне тәмам камил итү өчен, әлбәттә инде, редактор бөтен әсәрне тулаем укып чыгып, төзелешенә редактор анализы ясау барышында гына ирешә ала. Шуннан соң гына ул аны камилләштерү тәкъдимнәрен авторга җиткерә һәм үтәлүенә ирешә ала. Әлбәттә инде, сәнгати булмаган әсәрләрне редакцияләү барышында да барлык әсәрләргә дә яраклык рецепт-тәкъдимнәр юк, була да алмый – журналистик әсәрләрне төзәтү дә ул шәхси иҗади эш. Шулай да редакторның игътибары иң башта менә нәрсәләргә төшәргә тиеш:

1) тәкъдим ителгән композиция теманы дөрес итеп, мантыйкый эзлеклелектә, тәганләнгән жанр кысаларында азагынача ачып бирерлекме? Ягъни тема автор уйлаганча һәм план-проспектта каралганча ачылганмы?

2) әсәр өлешләргә (кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф, пункт (статья), матдә, микротекст, макротекст, текст, кызыл юл) дөрес бүленгәнме? Теманың тулы ачылышына бу бүленеш муафыйкмы? Аерым бүленеш төрләре бер-берсенә дөрес нисбәттәме? Бүлекләрдә эчтәлек нисбәте дөрес чагылганмы, “ваграк” мәсьәләгә тәфсилле тукталып, төп темадан читкә тайпылынмаганмы?

Менә ни өчен план-проспектны җентекле өйрәнүгә, аның кульязма эчтәлеге белән тәңгәллегенә җитди игътибар итәргә кирәк. План-проспект та, эчтәлектә ачылырга тиешле төп юнәлешләр дә китапның (җыентыкның) азакта бирелә торган **эчтәлектә** (оглавление, содержание) тулы чагылыш табарга тиеш. Әсәр кисәк, бүлек, бүлекчә, параграфларга бүленгән икән, ул бүленешләр башисем яисә сан (тамга) белән билгеләнгән икән, ул бүленешләр төп-төгәл килеш эчтәлектә дә күрсәтелсен. Укучының әсәр композициясе белән алдан ук танышып куюы – хәерле фалдыр;

3) Кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф бер-берсенә тыгыз бәйләнештәме, буйсыну тәртибендә урнашканнармы, эчтәлек күләме ягыннан дөрес нисбәттәләрме, исем-атамалары аларга куела торган таләпләргә туры киләме, кабатланмыйлармы, исемнәр эчтәлек җисеменә туры киләме?

Композицияне камилләштерү дә автор белән бергә башкарыла, редакцияләү процессының тулаем барышында өзлексез игътибар үзәгендә тора. Редакторның бу юнәлештәге барлык тәкъдим, таләпләрен дә автор эчтәлек таләпләре дәрәҗәсендә үк үтәргә тиеш. Үтәлгәнме-юкмы икәнен редактор янә контрольдә тота – автор текстны төзәтеп китергәч, редактор кульъязма эчтәлегенең проспектка һәм эчтәлеккә тәңгәл булуын янә тәфсилләп тикшерә: аерым алганда, үзгәргән вариантта бүлекләр арасында нисбәт сакланганмы, кыскартылган бүлекләрнең исеме эчтәлектә калмаганмы, үзгәртелгәннәре эчтәлектә үзгәртелгәнме?

Кагыйдә буларак, әсәрнең эчтәлеге өч өлешкә бүленә: **кереш, төп өлеш, йомгак**. Бу бүленешнең формаль рәвештә композициядә турыдан-туры чагылмавы да бар, эчтәлектә дә андый бүленешне күрсәтү мәҗбүри түгел.

Эчтәлекнең мондый бүленеше жанр төренә, әсәрнең күләменә карап (мәсәлән, репортаж һәм очерк, хисап һәм эссе һ.б.) ярылып ятмаска да мөмкин. Әмма редактор шул эчке бүленешне һәм аларның бәйләнешен, нисбәти мөнәсәбәтен һичшиксез тоемларга, саклый алырга тиеш.

**Керештә** теманың асылы, ни өчен сайлап алынуы хәбәр ителә, бик кыска гына мәгълүмат бирелә, эчтәлек агышының юнәлеше тәгаенләнә. Керештә әйтелә торган фикер, мотивлар әсәрнең кереш өлешендә әйтелмичә, төп өлешендә дә бәян ителергә мөмкин.

**Төп өлештә** теманың асылы ачыла, тасвирлана. Анда төп тезислар, нигезләмәләр, аларга дәлилләр (система белән) китерелә, исбат ителә. Тема катлаулылыгы төп өлешнең дә композицион яктан катлаулы булуына нигезле сәбәп була. Төп өлеш кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф, пункт кебек өлешләрдән, композициянең башка төр бүленешен хасил иткән төшенчә-терминнардан тора.

Текст агышы – бәян итү, хәбәр итү, анализлау, хикәяләү, тасвирлау алымнары белән бара. Бер очракта (авторына, жанрына карап) фикер, анализ гомумидән өлешкә (хосусыйга) (анализ алымы), икенче очракта, киресенчә, хосусыйдан гомумигә, конкреттан абстрактка (синтез алымы) тәртибе белән башкарыла.

**Йомгакта** кереш һәм төп өлештә әйтелгәннәргә нәтиҗә ясала – әсәрнең төп фикер, юнәлешләре кыскача гына гомумиләштерелә, йомгаклап әйтелә. Кереш тә, йомгак та газетның һәр язмасында композицион төгәлләнгән, аерылып торган рәвештә булмаска да мөмкин, шулай да редактор аларның эчке хәсиятен тоемларга, укучының да тоюына ирешергә тиеш. Китапларда, фәнни хезмәтләрдә алар конкретлыгы, кыскалыгы, тыгыз язылуы белән аерылып тора.

Кереш, төп өлеш, йомгакның нисбәтен автор материалының эчтәлегенә, бәян итү, тасвирлау алымына, әсәрнең адресатына карап үзе төзи, көйли; мәгълүм бер күрсәтмә-кагыйдә яисә үрнәк-калып билгеләнмәгән; редактор да үз тәҗрибәсеннән тупланган күзәтү-нәтиҗәләргә таяна. Элекке дәреслекләрдә, мәсәлән, кереш белән йомгак күләмен бөтен әсәрнең сигездән бер – уннан бер өлешеннән арттырмаска дип өйрәткән.

Композиция төгәллегенә ирешмәү аркасында текстта нинди кимчелекләр китә:

– мәгънә күләме нисбәте бозыла: артык өтек яисә артык җәенке, күп сүзле була;

– кереш, йомгак төп өлеш белән идея ягыннан да, тема ягыннан да “җепшек” бәйләнешле, таркау, “җилеме җитмәгән” була;

– композиция төзеклеге тотрыксыз, “өтек” була: кереш ачык тоемланмый, йомгак исә бөтенләй дә булмый. Бу, гадәттә, редакцияләү вакытында, аннан да бигрәк, әзер текстны инде типографиядә басу вакытында ихтыярсыз, мәҗбүри кыскарту аркасында килеп чыга.

Сәнгати әсәрләрнең композициясе аның сюжеты рәвешендә билгеләнә, ә журналистик әсәрдә – **план** белән. Шул ук вакытта бу фактор андый төр әсәрләрнең композициясен төзү һәм төзәтү гади, җиңел дигәнне аңлатмый. Композициянең гадыймы, катлаулымы булуы аның кайсы төр әдәбияткә, хәтта кайсы төр жанрга каравыннан түгел, ә бәлки эчтәлегенең катлаулылыгыннан килә. Композиция төгәллеге, аның укучыны җәлеп итү, мавыктыру көче үзәккә куелган проблеманың чыннан да үзәктә булуыннан, игътибар "үзәгеннән" тайпылмавыннан килә, иң кирәге язылса, артык-портык алып ташланса, барлык өлешләр дә гармониядә булса, әсәр тулаем да гармониядә була.

Гадәттә автор нәкъ шушы гармониягә ирешелгәнен тоеп бетерми, аңа читтән үлчәү-бәя кирәк, шуңа күрә дә ул редакторга: "үзең кара инде, теләгәнемне әйтергә тырыштым", ди. Бу очракта редактор чыннан да реаль, объектив бәя бирүче булып кала. Шул ук вакытта ул авторның җаваплыктан читләшүенә дә юл куймаска тиеш. Менә ни өчен ул аңардан план-проспект таләп итә, шул планга нигезләнеп эшләвен контрольдә тота.

Шушындый эшнең дә механик эш түгеллеген, ә бәлки иҗат эше икәнлеген авторга төшендерергә кирәк; югыйсә, әйткәнебезчә, "ярый үзең бүлгәләп куй инде", диюче авторларга да очрап торабыз. Авторның үз әсәрен композицион яктан күзаллый белмәве, аны өлешләргә дөрес нисбәттә таркатмавы аның тематик күләм кысаларын чамаламавыннан, жанр үзенчәлекләрен тоймавыннан килә. Әйтик, интервью жанрында да чыгырдан чыгып китү очраклары аз түгел. Гәрчә анда композиция гади генә кебек: сорау –җавап. Монда да бер яктан сораулар гади, калыпланган, сорау интонациясе белән генә чикләнгән булуы ихтимал. Соравың нинди, җавабы шундый. Ул да йә артык "туры", йә артык"җәенке", "томанлы" була. Тема агышында өзек-өтеклек килеп чыга, артык тармаклану-төрлелек, җилем җитмәү күзәтелә. Җавап игътибарсыз калдырыла, аңа бәя бирелми. Чираттагы сорау бирелгән җавапка, яисә башланган темага бөтенләй бәйләнешсез була. Ярый әле шул әңгәмәдәш, шул кеше җавап бирә, югыйсә темасы ягыннан бөтенләй бәйләнешсез сораулар китә. Артист әле генә җырының эчтәлеге турында сөйләгән иде, журналист инде, аны тыңлап та бетермичә, күлмәгенең кем тегүе турында сорый.

Ә бит редакторның композицияне тоемлавы иҗат эшенең гасырлар буена тупланган тәҗрибәсенә таянган таләпләрдән килеп җыела. Әйтик, нәшрият эшендә төрле тип әсәрләрнең күләме, шул күләмнең композицион-структур бүленеше хәтта нормаларда да тәгаенләнгән. Мәсәлән, киң массага адресланган иҗтимагый-сәяси әдәбият 4 табактан артмаска тиеш, фәнни-популяр әдәбият – 10, монография, җыентык-мәҗмугалар – 20, уку ярдәмлекләре 5 табак.

Газет, журнал материалларына карата да газетның төренә, күләменә карап композиция төзелеше регламентка салына – репортаж, интервью, башмәкалә, очерк һ.б. жанрларның мәҗбүри (норма) күләме тәгаенләнгән. Татарстан язучылары, мәсәлән, "Казан утлары" журналының катгый

таләбен истән чыгармый: очерк-публицистик язма, мәсәлән, 18 биттән артмаска тиеш. Шәхсән үземә "Татар энциклопедиясе"нә берничә язма әзерләргә туры килде. Редактор заказ биргәндә үк булачак әсәрнең күләмгә бәйле төзелешен, оформлениесен (шрифтның төренә кадәр ачыклап) тәгаенләгән таләпләр куя. Редакцияләү барышында ул аларга таләпчән булачагын кисәтә. Сүзендә тора да. Хәтерлим әле: Татарстан китап нәшриятендә эшләгәндә, күренекле язучы Кояш Тимбикованың очерклар җыентыгының күләмен еллык планда каралганнан бер-ике табакка гына арттырып тәкъдим иткәнем өчен шул арткан табакларга гонорарны үземнән түләтәбез дип искәрткәннәр иде.

**Әсәрнең эчке төзелешен редактор тоемлавы**

Әсәрнең тулай композициясен редактор эчке бер сиземләү белән, ачык күз алдына китерергә һәм аны буеннан-буена эзлекле рәвештә саклый килергә тиеш. Моның өчен беренче шарт – ул фикернең өлешләрдән (хосусыйдан) бөтенгә (гомумигә) табигый бәйләнә, теркәлә баруын сиземләү. Фикер берәмлеге җөмлә икенче җөмләгә ничек бәйләнә, каршылык, аһәңсезлек килеп чыкмыймы; алга таба зуррак фикер берәмлеге хәбәрләмә тел берәмлеге синтаксик бөтен (микротекст) сыйфатында бер-берсенә ничек бәйләнә. Микротекстлар үзара макротекстларга "шома" бәйләнәме: алар кызыл юл эчендә, параграф, бүлекчә, бүлек эчендә нинди нисбәттә урнашып бара, күләм нисбәте мәгънә (эчтәлек) нисбәтенә туры киләме – сөйләм агышында "керәле-чыгалы"лар, "тырпаеп тору"лар, өтеклекләр юкмы, фикер тиешенчә "келәйләнеп-җилемләнеп" барамы? Әлбәттә, һәр өлеш-берәмлекнең механик "тигезлеге" (кызыл юлларның күзгә ятышлы булып, ачык күренеп торуы) дә әһәмиятле, тик, аннан да бигрәк, эчтәлек гармониясе әһәмиятле – сөйләм агышы әсәрнең буеннан-буена структур-мантыйкый камиллектә булырга тиеш.

Җөмләне җөмләгә, микротекстны микротекстка, кызыл юлны кызыл юлга һ.б. мантыйкый бәйләү, аһәң камиллегенә ирешү – үзеннән-үзе ирешелә торган "казаныш" түгел, аңа мантыйк законнарын яхшы белү, аларны нәкъ менә шушы әсәр тукымасында урынлы куллану нәтиҗәсендә ирешелә. Шул ук вакытта ул бәйләү фикер чаралары белән генә түгел, ә шул чараларны гамәли чаралар белән, ягьни ана теленең бәйләү чаралары (бәйләгеч кушымча, сүзләр, кисәкчә, мөнәсәбәтлекләр һ.б., пауза, интонация һ.б.) дөрес, урынлы кулланып кына ирешелә.

Дөрес бәйләү (кушу, төзү һ.б.) – ул дөрес аеру (бүлү, таркату һ.б.) белән тыгыз бәйләнгән. Хәтерлисездер, редактор укуының өч тапкыр булырга тиешлеге, икенче тапкыр ул әсәрне таркату максатында укуын кисәтеп киткән идек. Кире кайтып, моңа бәйләү мәсьәләсе яссылыгында якынрак килик әле.

Фикерне бүлү – ул мантыйк төшенчәсе, мантыйкка бәйле категория, мантыйк операциясе. Димәк ки, теманы, әсәрне бүлү дә мантыйкый операция. Менә ни өчен текстны, әсәрне бүлү эше ул мантыйк

законнарына нигезләнеп үтәлә. Кыскача гына барлаганда, мондый нигезләмәләргә таянырга була:

– эчтәлекне, текстны бүлгәләү дәлилләнгән булырга тиеш (нигезләнгәнлек кагыйдәсе);

– бүленгән өлешләр суммасы текст күләмен тәшкил итәргә тиеш (дөрес нисбәт кагыйдәсе). Хата нидән гыйбарәт? Материалы күп,төрледән-төрле, димәк, игътибар темадан читкә китә; Материалы җитми, шулай ук игътибар читкә китә; Исеме җисеменә туры килми;

– бүленеш баштан алып азагынача эзлекле булып тәмамланырга тиеш – параграф эчендә параграф, кызыл юл эчендә тагын кызыл юл калмаска тиеш, юкса, кабатлаулар, кире кайтулар, композиция “китеклеге” килеп чыгар;

– бүленеш система-тәртипкә буйсындырылырга, эзлекле булырга тиеш – башта кисәк, бүлек, бүлекчәләр, аннары “ваграк” кисәкләр (параграф, пункт, матдә һ.б.), ә киресенчә түгел. Система таркау булганда фикер агышы “кытыршылана”, аңлау кыенлана.

Мондый катгый мантыйклык укучыга әсәрне тәмам ”чәйнәп” бирүгә китерер, аның сәнгати хыялын, үз иҗатын чикләү булыр, диючеләр дә табылыр. Иҗатчылар арасында андый бәхәсләр булып тора. “М.Мәһдиев әсәрләрендә классик композияция күзәтелми”, дип мисал да тагалар. Композициядә “яңа форма” эзләргә өндәүчеләр дә очрый.

Психологлар моңа каршы; алар мантыйкый фикерләү нигезендә тупланган, тезелгән материал җиңел укыла, хәтергә сеңеп кала һәм озак саклана, дип саный. Аннары бит һәр укучыны уйланырга, фантазиягә бирелергә мәҗбүр итеп тә булмый. Аны бит, иң беренче чиратта, эчтәлек, проблема, ситуация, проблеманың чишелеше кызыксындыра. Һәрхәлдә ул милли аңда күнегелгән, береккән дөрес мантыйкый фикерләүгә нигезләнгән, ягъни төзек композициягә күнеккән.

## Композициягә редактор анализы методикасы һәм алымнары

Әгәр әсәренең композициясен автор үзе төзегән булса, шул төзелеш редакторны да канәгатьләндерсә (әдәби әсәрләрне редакцияләүдә шулай күнегелә дә), редактор шул композицияне йә язып куя, йә хәтерендә тота. Һәрхәлдә редакцияләү барышында композиция редакторның башында (хәтерендә) булырга тиеш. Әгәр әсәрнең төгәл композициясе юк икән (бу хәл гадәттә газет жанрлары белән шулай була) редактор композицияне көчләп тага алмый, бергәләп, килешеп иҗат итәргә кирәк була. Нинди эчке кагыйдәләргә нигезләнеп?

Күңелдән план төзеп, шуңа таянып эшләргә өйрәнү күнекмәләрен тупларга, шуларга нигезләнеп эшләргә күнегергә кирәк: а) бер синтаксик бөтеннән (микротексттан) икенчесенә күчүне тоеп барырга, мәгънәви (мантыйкый) эзлеклелекнең саклануын тоярга кирәк. Монда тема бердәйлеге, жанрга хас тон, сөйләм-стиль агышын тоемлау һ.б. “тәртә”

була ала; ә) бер бөтеннең (параграф, кызыл юл һ.б.) эчтәлеге аңа бәйләнгән бөтеннең эчтәлегенә нисбәтән туры килүен тоемлау кебек. Монда форма берәмлегеннән бигрәк хәбәрләмә (ягъни эчтәлек) нисбәтен тоемлау әһәмиятлерәк.

Икенче бер күзәтү, тоемлау күнекмәләрен ясарга була: күңелдә тотылган планны (композицияне) эчтәлектә тәгаенләнгән бүленеш белән даими чагыштырып тору; фактик композицияне тема агышы, мантыйк системасы белән чагыштырып барырга. Бу җиңел генә бирелә торган күнегү түгел. Әсәрнең төзелешен буйдан-буйга истә тоту – редакторның таланты, осталыгы ул. Керештә вәгъдә биргәнне төп өлештә онытмаска, бер бүлекчәдә әйткәнне бүтәннәрендә истә тотарга, кабатлауларда бер үк фикергә, бер үк нәтиҗәгә юл куймаска. Йомгакта исә нәтиҗәне төп аргументлардан гына ясарга, бүлекчә, бүлекләрдә ясалган нәтиҗәләр суммасы итәргә, төп аргументларның эчтәлектә чагылган булуын күздә тотарга. Менә бу таләпләр үтәлмәгәндә композицион хата китәсен онытмаска. Бер генә мисал: “Ү1–ҮП класслар өчен өстәмә әдәбият. Казан, 1979” китабында автор кереш сүзендә: “Китапта Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим поэзиясеннән дә үрнәкләр бар. Бу шигырьләрдә дә...” дип, укучыларга бер бәйләм шигырь вәгъдә итә. Карасаң, кулланмада бер генә шигырь икән...

Композицияне бүлү **рубрикалау** белән башкарыла. Рубрика эш агышында да, рәсми эчтәлектә дә чагыла.

Автор иҗаты нинди генә шәхси эш, әсәр нинди генә үзенчәлекле, хосусый иҗат җимеше булмасын, әсәрнең төзелеше барыбер композицион төзелештән торачак, аның нигезен рубрикаларга бүлү тәшкил итәчәк. Шуңа күрә рубрикаларга бүлү авторга да, редакторга да кагылган нигезләмәләрдән гыйбарәт. Менә аларның кайберләре генә:

– рубрикалау әсәрнең эчтәлек күләменә бәйле. Гадәттә микротекст җиде берәмлектән (җөмлә формасындагы хәбәрләмә) артмаса, текст рубрикаланмый.

– рубрикалауның классик тәртибе: кисәк – бүлек – бүлекчә – параграф – пунк – матдә; кызыл юл; мәгънә белдерүче тел берәмлекләре: аваз, иҗек (кушымча); сүз, сүзтезмә (синтагма), җөмлә, синтаксик бөтен – микротекст, макротекст, текст; сөйләм берәмлекләре: аваз (фонема), морфема, лексема, фразема, хәбәрләмә, фикерләмә;

Рубрикалау белән артык мавыкмаска, катлауландырмаска тырышырга кирәк. Ничә буынлы рубрикалау кирәклеге китапның (әсәрнең) жанрына, укучының әзерлегенә карап тәгаенләнә. Дәреслекләр, уку кулланмалары ваграк кисәкләргә бүлгәләнә. Матур әдәбият, фәнни-популяр әсәрләр классик бүленештә тәкъдим ителә.

Бүленешнең эчтәлеккә муафыйк аталуы бик мөһим. Бүленеш исемле һәм исемсез була. Исемлеләр башисем, санисем (рим цифры һәм гарәп цифры), санлы-исемле була. Һәр бүленештә (кечерәюгә карап та) исемнең

кабатланмавын, бер төрле формада булуын күзәтә барырга кирәк. Еш кына цифр төре үзгәрә яисә бер параграф исемле, икенчесе цифрлы була.

Бүленеш белән бәйле янә берничә хата төре: текст эче эчтәлеге белән текст тышы эчтәлегендә аерма килеп чыга, чөнки бер-берсе белән бәйләмичә тикшерелә. Мәсәлән, Татарстан Конституциясенең яңа басмасын чыгарганда бер кыскартылган бүлекчәсенең исеме тышкы эчтәлектә калган иде.

**Рубрикаларның график бирелеше**

Гадәттә рубрикаларның типографик (график) бирелеше техред, рәссам функциясе исәпләнә, бу үзенә бер белгечлек санала; Дөресе дә шулай. Шул ук вакытта редакторның редакцияләү методында, механизмында бу да читтә кала алмый. Монда без бүленешкә бәйле терминнарны санап китү белән, бик кыскача гына аларның асылын искә төшерү белән чикләнәбез: шмуцтитул, шапка, рубрика на спуске (текст башында), рубрика в разрез текста (текст эчендә, аны бүлеп); рубрика в подбор с текстом (кызыл юл эчендә үк); форточка (оборкада); форточка; фонарь; Аерым хәрефләр белән (баш хәреф, юл хәрефе, һәр ике очрак бер яклы җәя эчендә һәм җәясез (нокта белән аерылып). Болар сүзле исем белән дә аерыла ала.

Китаптан аерым буларак төрле җыентыкларны, журналны һ.б. басмаларның композициясе һәм аларны редакцияләү шактый үзенчәлекле булса да газет композициясе аерым тукталуны, үзгә игътибарны таләп итә.

Газет текстын оештыру эше махсус предмет, курсларда өйрәнелә. Без исә монда редакцияләү эше белән бәйле кайбер закончалыкларга, үзенчәлекләргә генә тукталырбыз.

Редактор газетның тематик төрлелеген истә тотарга тиеш. Гәрчә редакциянең махсус бүлекләрдән торуы бу проблеманы үзеннән-үзе хәл итә кебек. Шул ук вакытта рубрикаларның кабатланмаска тиешлеге таләбен үтәүдә редакторның да тырышлыгы сорала. Һәр бүлекнең конкрет план белән эшләве таләп ителә. Даими рубрикалар өчен аерым бүлек, хезмәткәр җавап бирүенә күнегергә кирәк. Шул ук вакытта бу факторлар редакторның сизгерлеген томаламаска тиеш. Менә хата китү ихтималы булган кайбер “нечкә” урыннар:

– газет битләре арасында эчтәлек ягыннан да, төзелеше ягыннан да нисбәтне саклау; кабатлауларга юл куймау. Әйтик, газетның һәр бите чагыштырмача мөстәкыйль булса да (дүрт, яисә сигез, уналты ... битле), алар бөтенләй үк мөстәкыйль булырга тиеш түгел. Аларның һәркайсын әсәрнең кисәге сыйфатында күзаллау зарур. Аның эчендә бүлек, бүлекчә, параграф бүленешләре... бар (булырга тиеш) дип. Башисемнәр кабатланмаска, бер үк төрле иллюстрациядә булмаска тиеш;

– текст белән иллюстрация бәйләнеше. Рәсем астының “исеме җисеменә туры килмәве” (мисал); биттән биткә күчеш формасы; Газет аппаратын билгели торган Гост таләпләре (ни кызганыч, төрле газетта төрлечә) һ.б.

**Күнегү**

1) "Гафу үтенәбез. Газетыбызның (28 ноябрь, 1996 ел) "Сатып алынган чир" исемле язмада фотохәбәрчебез Е.Канаев архивыннан Зеленодол районы, Паново авылында туй вакытында төшерелгән фоторәсем файдаланган идек. Әлеге рәсемдә клуб мөдире һәм сатучы булып эшләүче Н.Зубина да булган. Укучыларыбызга шуны хәбәр итәбез: язманың эчтәлеге белән очраклы рәвештә кадрга эләккән Надежда Васильевна һәм Евгений Мишанин арасында бернинди мәгънәви бәйләнеш юк.

Ә редакция әлеге очраклы, күңелсез хәл өчен Н.Зубина һәм Е.Мишаниннан гафу үтенә (Т.я., 1996, 12 дек.).

2) "Төзәтү. Газетыбызның үткән санында 5 нче биттә "Самавырлы Шыгырдан" исемле язманың рәсемендә секретариат гаебе белән хата киткән. "Хуҗабикә Гөлчәчәк оныгы Хәдичә белән кунакларга чәй әзерли" дигәнбез, ә сурәттә оныгы юк: киселеп калган. Әлеге хатабыз өчен укучыларыбыздан гафу үтенәбез" (Т.я.,2010, 7 сент.).

3) Матур әдәбият китабын, фәнни (монография), фәнни-популяр, рәсми әдәбият, дәреслек, уку кулланмасы, әсәрләр җыентыгын, рәсми документлар җыентыгын композиция ягыннан анализларга; композицион, лингвистик, типографик, рубрика бүленешен анализларга.

4) Өлкә, район, шәхси (коммерция), корпоратив һ.б. газетны төзелеше (композициясе) ягыннан анализларга. Бер әсәр буларак бәйләү чаралары (баш исеме, рубрикалар, куш баш (чардак, подвал) атамасы, биттән биткә күчә торган рубрика, баш исеме һ.б. Кушбит (разворот), сәхифә (бит), тупланма, җыелма (подшивка, подборка) төшенчәләре һәм редактор.

## *Тугызынчы тема*: Баш исемен сайлау, төзәтү

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Баш исеменең эчтәлек белән форманы бәйләүче чара, текстның аерылгысыз кисәге булуы.

Баш исеменә төп таләпләр: эчтәлек белән туры бәйлелек, конкретлык, диккать җәлеп итүчәнлек, яңалык, аһәңлек һ.б.

Әдәбият, жанр төренә карап баш исеме. Текст бөтенлеген саклаучы чара буларак баш исеме. Тулаем әсәргә, аның өлешләренә куела торган баш исемнәренең нисбәте. Нисбәтнең бозылуына китергән сәбәпләр, кимчелекләрне бетерү юллары.

Газетта рубрика, баш исеме, башасты һәм башөсте исемнәре. Радио, телевидениедә тапшыруны исемләү мәсьәләсе.

Баш исемен табу, сайлау, камилләштерү – иҗади эш. Авторга ярдәм алымнары. Баш исеме чыганаклары: төрле стиль (өслүб) сүзе, сүзтезмә (синтагма), фразеологизмнар, мәкаль, әйтем, гыйбарә, канатлы берәмлек,

цитатлар һ.б., аларны үзгәртү мөмкинлекләре. Калыплашкан баш исемнәре, алардан котылу юллары.

**Эчтәлек көзгесе**

Баш исеме – ул әсәр эчтәлегенең һәм формасының (композициясенең) аерылгысыз бер өлеше. Беренче чиратта, эчтәлегенең аерылгысыз өлеше. Ә бит без вакыт-вакыт баш исеме китапка аны башкалардан аерыр өчен, яисә газетта мәкаләләр бер-берсе белән буталмасын өчен тамга, билге буларак, яисә китап тышын "матурлый" торган форма детале дип уйлыйбыз.

Эчтәлек белән турыдан-туры бәйләнгән элемент булуы нәрсәдә чагыла? Баш исеме әсәрнең беренче сүзе, чын мәгънәсендә башы ул. Төрле әдәбият төрендә иҗат иткән Максим Горький, мәсәлән, "Китапның беренче фразасы – укучының беренче тәэсире ул... Ә бу бик мөһим", дигән. Бу образлы күзаллауны текст белән физик бәйләнеш дип тә аңларга була. Моңа мисаллар җитәрлек. Журналистикада, шул җөмләдән татар журналистикасында да, баш исеменең текстның беренче фразасыннан алып куелуы киң таралган. Хәбәрләр тупланмасы сыйфатында бирелгән материалда һәр хәбәр-хроникаының беренче юлы баш исеме булып аерыла; Бу очракта газет битендә урынга исрафлык булмый, күпсүзлелеккә юл куелмый; Бу янә баш исеме эчтәлек белән турыдан-туры бәйле булырга тиеш, дигән кагыйдәгә мисал булып та тора;

Әлбәттә, мондый формаль бәйләнешкә гел ябышып ятарга димәгән. Төп максат: эчтәлек белән аерылгысыз бәйләнеш. Ә бу әсәрнең эчтәлеге, идеясе, хәсияте белән тукыма кебек бәйләнгән булуы:

– әсәрнең идеясен белдерә: "Намус" (Г.Бәширев);

– әсәрнең хәсиятен, асылын тәшкил иткән төп образның исеме яисә фамилиясе, символик кушаматы: "Тукай" (Ә.Фәйзи); "Газинур" (Г.Әпсәләмев), "Кәшфи абый" (М.Мәһдиев); шушы образның һөнәр исеме, белгечлеге белән бергә: "Ардуан батыр", "Габбас хәзрәт" (Г.Ахунов), "Маякчы кыз" (Г.Гобәй); "Хат ташучы" (М.Җәлил);

– идеяне символ рәвешендә тасвирлау: "Тирән тамырлар" (Г.Ибраһимов), "Кара йөзләр" (М.Гафури), "Бодай бөртеге һәм тегермән ташы" (Ә.Гаффар), "Тәүбә", "Элмәк" (Т.Галиуллин);

– төп вакыйганың урынын, вакытын, яисә берәр сыйфатын символлаштыру: "Агыйдел" (М.Әмир), "Утызынчы еллар" (Ф.Хөсни);

– әсәрнең эчтәлеген теге йә бу яклап ача торган үзенчәлекле (юмор) гыйбарә, берәр образ, факт, деталь: "Сызгыра торган уклар" (Н.Фәттах), "Иске сәгать дөрес йөри" (Р.Вәлиев), "Өч аяклы ат" (А.Хәлим) "Кишер басуы" (З.Хәким).

**Баш исемен алыштыру, яңасын эзләп табу**

Баш исемен үзгәртү, алыштыру, төрле вариантлардан иң кирәклесен сайлап алу турында автор белән бәхәс, киңәш тоту – кызыклы да, файдалы да процесс. Үз тәҗрибәмнән берничә генә мисал. Архивымда күренекле

генә авторларның басыласы әсәренә берьюлы берничә исем тәкъдим иткән язмалары сакланган. Алексей Литвин: Былое забыть нельзя, Былое напоминает, Встречи с прошлым, Немеркнувщая слава, Тревожные дни Казани... Сигез вариант тәкъдим ителә. Китап безнең тәкъдим, авторның килешүе белән "Дело сдать в архив" дип басылып чыкты. Журналист Сәмигулла Хәйретдиневнең "Классташлар" җыентыгына тәкъдим иткән вариантлары: Бер класс язмышы, Еллар узгач, Классташларым – җан дусларым һ.б. Марат Әмирхановның "Чулманның ак йолдызы" очерк җыентыгы исеме дә Балкыш, Чал Чулманның ак йолдызы вариантларыннан сайлап алынган иде. Күренекле журналист Рахмай Хисмәтулланың кулъязмасына "Үземне таптым" дигән баш тәкъдим иткәч (бер очеркы шул исемле иде), ә күренекле җәмәгать эшлеклесе Камил Фасиевнең китабына "Бәхетең үз кулыңда" дигән исем табып биргәч, сөенеп рәхмәт әйтүләре әле дә истә.

**Баш исеменә куела торган таләпләр:**

– эчтәлек белән турыдан-туры бәйләнгән булуы;
– гадилек, кыскалык;
– ачык, аңлаешлы, күпчелеккә тиз барып җитүе;
– игътибарны тиз җәлеп итәрлек, мавыктырырлык;
– кабатланмаган, яңача;
– күңелгә ятышлы яңгырашлы, аһәңле;
– бер газет, журналда, бер әсәрнең бүлекләрендә кабатланмавы.

Баш исемен композиция элементы буларак әсәрнең буеннан-буена истән чыгармау – редакторның бурычы. Бездә әле тәҗрибәле редакторлар да әсәрнең кереш өлешен редакцияләү барышында баш исемен тәмам килешенгән, хәл ителгән дип, аннары инде аңа кире кайту артык, кирәкмәгән эш дип санап, кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф исемнәренә төп исемгә караган таләпләрне куймыйлар, автор интуициясенә тапшыралар; "пашталюн куяр әле" дигән шаярту да йөри. Автор исә җаваплылыкны редакторга аударып калдыра. Шушындый шартларда менә мондый хаталар китә:

– автоматик бүлгәләнгән текстта автоматик (эчтәлеккә бәйсез) башлар куела;

– редактор төп баш исемен яисә әсәр эчендәге берәр баш исемен үзгәрткән очракта, автор куйган баш исеме системасын (әгәр ул булса да) азагынача саклау хәстәре күрелми; Бигрәк тә бүлекчә баш исемнәре төп баш белән бәйләнми.

Бу таләпләрне үтәү авторга гына түгел, редакторга да җиңелдән түгел. Икәү бергәләшеп иҗат итү хәлне берникадәр җиңеләйтә булса кирәк. Әхмәт Фәйзи Җәүдәт Фәйзигә хат яза (1949 елның 11 октябре): "Спектакльнең исеме турында сөйләшәсе бар иде һәм мин сиңа исемнәр исемлеге хәзерләп куйган идем. Алардан хәзер мин күбесен сыздым.

Калганнары менә: Сердәшләр, Серле кич, Шук йөрәкләр, Бар да үз урынында, Дуслык җыры, Йолдызлы кич, Айлы кич, Йолдызлар, Зәйтүнәкәй, Гармунчы Зиннәт... Соңгы икесен без инде икәү уйлаган да идек, һәм мин аларга каршы түгел. Ләкин “Зәйтүнәкәй” дип куйсак, аның роле пьесада зур түгел, (зато аның җыры халык арасында шактый таралган!). “Гармунчы Зиннәт” дигәндә, ул хәзер гармунчылыктан чыгып тракторчыга әйләнде”. Әсәр “Акчарлыклар” булып дөньяга мәгълүм була.

Г.Әпсәләмевнең бер уйлануы: “... Романның исеме – “Ак чәчәкләр” – шулай калырмы, үзгәрерме – белмим. Әсәрнең исеме эчтәлегеннән кечкенәрәк булырга тиеш. Укучыга зур нәрсә вәгъдә итеп тә бәләкәйне бирсәң, яратмый. Киресенчә булганда, күңеленә хушрак килә (1963, 25 авг. Переделкино).

Эзләнү газабы редакторга да шул ук дәрәҗәдә төшә. Кире кагып кына, “бармый” дип кенә котыла алмыйсың. “Ярамый” дияр өчен дә уйланырга, эзләнергә кирәк, ул тезисны исбатларга, дәлилләргә кирәк. Ярамаганы урынына автор бүтәнен тәкъдим иткәч, анысын да өр-яңадан “иләргә”, “бизмәнгә салырга” тиеш буласың...

Редактор баш исемен алыштырыр, яңасын куяр өчен һәрвакыт әзер торырга, ягъни аның запаста баш исемнәре теркәлгән булуы зарурдыр. Шәхсән үземнең эш куен дәфтәремнең азагында баш исемнәре теркәлгән “запаслык” бар. Кайберләрендә файдаланылмый калганнары да саклана: Чүкеч искерми, Бөркет канатлы хыялың булса, Кулы җиңел булсын. Теркәлгән баш исемнәренең күбесе файдаланыла килгән.

Әлбәттә, монда үзеңне эчтәлеге ягыннан канәгатьләндергән, укучы да уңай кабул итәр дип өметләнелгән әсәр турында бара. Эчтәлеге, язылышы укучы таләпләренә туры килмәстәй язманы, мәкаләне ялтыравыклы, “акыллы”, “шаккатыргыч” баш исеме белән генә коткарып булмый Аны яңадан эшкәртергә, яңадан яздырырга кирәк.

Баш исемен сайлауга җавапсыз караганда, төзәтү принципларын үтәмәгәндә менә мондый кимчелекләр туачак:

– баш исеменең мәгънәсе эчтәлекне колачлый алмаслык гомуми. Сәбәбе семантикасы белән артык гомуми, абстракт мәгънәле сүзләр куллану: *заман, бәхет, үрнәк, максат, күңел, язмыш, игътибар, ихтирам, чәчәк, якты, тормыш, моң, җыр, юл...* Заманында курсның шушы темасына материал туплау максатында мин шул чорның барлык газетларын да диярлек күзәтеп-анализлап, кызыклы нәтиҗәләр ясауга ирешкән идем. Әйтик, шушы гомуми мәгънәле берәмлекләрне үзенә бер мәгънәви төркемнәргә тупларга мөмкин булган икән. Менә мондый төркемнәр төсмерләнгән икән: “Ут – янгын – кайнар” (*Без кабызган утлар, Туган як җылысы, Ялкынлы еллар яктысы, Чаткыдан – ялкын, Трассаның кайнар сулышы* һ.б); “Үр – биеклек – күтәрелү” (*Үргә күтәрелгәндә, Күтәрелеш баскычлары, Биеклек* һ.б); “Эз –адым – сукмак – юл”: (*Җиңү юлларыннан, Аккан су юл табар, Ныклы адымнар, Якты эз, Шөгер – гомер сукмагы*

һ.б.); “Йөрәк – күңел – җан” (*Күңел яктысы, Йөрәк ялкыны белән, Йөрәк әмере* һ.б.); “Заман – тормыш – максат” (*Заман сулышын тоеп, Олы максат белән, Тормыш мәгънәсе, Тормышның үзәгендә* һ.б.). Янә дә “Көрәш – сугыш – хәрби”, “Моң – җыр – музыка”, “Төчеләр” (*Матур омтылышлар, Бөек батырлыкка һәйкәл* һ.б.), дигән төркемнәр дә аерып чыгарылган.

Сизәсез булыр: артык гомуми баш исемнәре сискәндерми-уйландырмый, борчымый, “төче” хисе тудыра.

Киресе дә очрый: артык конкрет берәмлекләр белән белдергәннәре. Алар, гадәттә, артык тар мәгънәле (яңа сәер сүзләр, техницизмнар, штамп-калыплар яисә бер укуда аңлашылмый торган, гомумән дә авыр аңлашыла, икеле-микеле хисе калдыра торган исемнәр: *Гомер тургайлары, Икмәк таләп итә, Әби һаман чаба, Чынлык рухы* һ.б. Шапырынкы, “матур” башларга “алдаткычлар” дигән кушамат та такканмын. Алар бит чыннан да укучыны “алдый”, ялгыштыралар, ялган мәгълүмат бирәләр. Балалар газетында “Балалар – табигать сагында” дигән баш исеме, тема актуаль булганга,үзенә тартып ала, тик укый барган саен балаларның лагерьда урманны пычратулары, агач-куакларны имгәтүләре, дару үләннәрен тамыры белән йолкуларына тап булгач, баш исемнең “алдавына” үпкәлисең. Г.О.Винокур менә нәрсә яза: “ Баш исеме әсәрдә нәрсә язылганын укырга чакырыр өчен кирәк дип уйларга ярамый... Аның андый функциясе дә бар, әлбәттә ... Шулай да исемнең нинди дә булса вакыйга турында кыска гына, сызымлап, бер күз ташлап кына хәбәр итүе, иң гади тышкы формалар белән безгә вакыйганың әһәмияте, асылы турында да белдерүе мөһимдер”.

Уйлавыбызча, “тышкы формалар” дигәндә ул иң беренче чара дип тел берәмлекләрен күзалдында тотадыр. Без хәзер шуларына тәфсилле тукталырбыз. Башка “формаларга” (экстралингвистик чараларга) да анализ ясау мөмкинлеген табарбыз.

Баш исеменә куела торган барлык таләпләрне дә ана теле чараларын кулланып һичшиксез үтәп була. Әлбәттә, баш исеме эчтәлекне төшендерергә тиеш дигән таләпне истә тоту ул эчтәлекне “чәйнәп” бирергә димәгән, мәгълүмәтне тәгәл бирә торган конкрет-номинатив берәмлекләр, терминнар белән тутырырга димәгән, төп эчтәлеккә киная ясаган, күчерелмә мәгънәле, юмор-сатира төсмере биргән берәмлекләргә дә телебез бик бай. Ягъни газет көн саен чыгуга карамастан, газет-журналларның саны да күп булуга карамастан, баш исемнәрен игътибарны җәлеп итәрлек, кабатланмаган, яңача яңгыраган, лексик байлыкның төрле катламнарыннан, төрле рәвештәгеләрен җәлеп итәргә, калып-ыштамплардан качарга мөмкинлек җитәрлек.

Фәнни тикшеренүләрдә баш исемнәрен эчтәлек ягыннан, форма ягыннан, лингвистик берәмлек буларак классификацияләү очрый. Мәсәлән, И.Гальперин баш исемнәрен менә шушындый төрләргә төркемли: символ исем, тезис исем, цитата-өзек исем, хәбәр исем, киная исем, хикәяләү исем

(Текст как объект лингвистического исследования.–М.:Наука, 1981, с.134), ә баш исеме турында махсус диссертация язган Н.Е.Бохарев менә мондый классификация тәкъдим итә (“Структурно-функциональное развитие заголовков. Алма-Ата, 1971). Хәер, аның системасы мәгълүм бер бәяләү критерийларына таянмаган, әйтик, функциональ бәяләр белән грамматик (синтаксик) бәяләр кушылып-буталып киткән. Шәхсән без баш исемнәрен бәяләгәндә дә аны сөйләм берәмлеге дип танып, мотивларга бәйләп анализларга тәкъдим итәбез. Менә Бохарев классификациясе – төп өч төркемгә аера: атау, хәбәр итү, реклам. Хәбәри баш исемнәрен болай төркемли: хәбәр итү, сорау кую, апелятив (мөрәҗәгать итү) баш исеме, полемик (бәхәс) баш исеме. Менә бу функциональ төрләренең нинди җөмлә төрләре белән белдерелүе – автор анализының төп өлешен тәшкил итә.

Баш исеменә **мәгънә (эчтәлеге)** ягыннан анализ

Кимчелекләр:

– артык гомуми; конкретлыгы шундук күзалдына килми: *Күңел җылылыгын өләшүче, Югары савым нигезе, Тирәнлек хуҗалары, Упкыннар кочагында, Чынлык рухы, Гомер тургайлары*;

– конкрет төшенчә дә төп-төгәл аңлашылмый, сорау кала, каршылыклы фикер туа: *“Ак чебеннәрне” күтәләр, Икмәк таләп итә, Бар да кара, Чыршы утын кабызыр өчен* (утын, ут–ын омоним), *Машинаны ник боралар, “Манекеннар балы* (омоним)( шул ук газетның беренче битендә *Бал суырталар* – бернинди проблема юк иде);

– шаккатаризмнар (аңлашылмый, “томанлы” әмма үзенә тарта): *Дәвамлы дәвам, Отышлы әйләнеш, Уңай тамгалы нуль* һ.б;

– мәгънәсе белән дә, язылышы (графикасы) белән дә начар аңлаешлы: *Этус, ЛТУ һәм ыр-мырр...;*

– уңай тәэсир калдыралар, хис бирәләр: *И Шәрифуллин, Шәрифуллин...* ( В.Т., М.Әмирхан ), *Ә-нии!!!* (Сәйдә Зыя), *“Аптыраганский”...* (Т.я., 2010, 23 окт.).*“Яхшырган ди, бар!* (Т.я.,2010, 9 сент.).

**Баш исеменә лингвистик күзәтү**

**Сүз.** Баш исеменең төп – беренчел бурычын, ягъни эчтәлекне ничек тә тулы бирү өчен сүз – иң тулы һәм ышанычлы чара. Иң башта ул яңа хәбәр (информация) чыганагы. Бу функцияне баш исемендә, нигездә, конкрет-номинатив берәмлекләр үти: алар – кеше исем, фамилияләре, урын, вакыйга исем-атамалары, хәбәр чыганагы сан, даталар, микъдәрне белдергән сүзләр һ.б. Кызык бер вакыйга искә төшә. Заманында шахмат буенча дөнья чемпионы булуга ирешкән Бобби Фишер дигән кеше ярышка әзерләнгәндә айлар буе кеше күзенә күренмичә, беркая чыкмыйча өйдә ята икән. Күп булса бер сәгатькә һава сулап керергә чыга икән. Шул вакытын ул дөньяда басыла торган абруйлы газетлар эленә торган витрина янында үткәрә икән. Нәрсә укыйсыз ул арада? дигән сорауга ул: берни укымыйм,

баш исемнәреннән күз йөгертеп кенә чыгам, дигән, шулардан бөтен дөньядагы яңа мәгълүмат белән танышып була, дигән. (С.Т., 1986, 23 окт,).

Баш исемендәге сүз мәгънә күләме ягыннан да, хис-тойгы белдерү сәләте белән дә иң күләмле, бай эчтәлекле, үзенчәлекле төсмерле булырга тиеш. Хәбәр чыганагы буларак та иң бае булырга тиеш. Әлбәттә инде: тиз аңлаешлы, көндәлек сөйләмгә ят булмаган, шул ук вакытта берникадәр сәер дә, калыпланып-каешланып бетмәгән дә булуы зарур. Ул уйландырырга, сискәндерергә, битараф калдырмаска тиеш.

Күзәтүне төзелеше ягыннан **ялгыз сүз** булган баш исеменнән башлыйк: гомуми берәмлек (яисә битараф дип атала торганнар): *Тәүбә, Галка, Каеш, Уйлар, Көтмәгәндә* (Т.я., 2007, 10 ноябрь); *Сусызлык..., Сердәш, Иң-иң , Кыскача* (Т.я., 2010, 26 окт.); *Кырылу, Кайтаваз, Көлдергечләр, Эш* (Т.я., 2010, 16 окт.); *Ярлыкау, Хикәя, Инә, Фарыз, “Каныгу”, Аллергиядән, Котлыйбыз! Астрология* (В.Т., 2010, 15 окт.).

Бер сүзле исем берәмлекләрен **туры мәгънәлеләр**гә: *Минекеләр, Моң, Сан, Төзәтү, Афәрин! Күзәтүдән, Дүртюллыклар, Муниципальләштерү* һ.б., **күчерелмә мәгънәлеләр**гә аерырга кирәк: *Фырт, Төер* һ.б.

Бер сүзле баш исемнәренең кимчелеге – кабатлануга дучар булучан; аеруча *булу, бар* һ.б. сүзләре кабатлана: *Әйтер сүзем бар; Су астынданиләр бар* (шул ук баш исеме 2нче биттә дә; *Җиңүләрнең була төрлесе* (8 нче биттә кабатлана); *Биргәннең дә ояты бар; Мусалар күбрәк булса...; Авыр булачак;* (В.Т., 2010, 2 ноябрь):

**Сүзтезмә** баш исемнәреннән: **ике сүзлеләр**: *Сүз көче, Табигать сабаклары, Сеңлесенең абыйсы, Һава торышы, Банк бүләге, Ау сезоны, Олимпия өметләре* (Т.я., 2010, 7 сент., 2 окт).

Күрәсез, күпчелеге тартым кушымчалы исем+исем рәвешле тезмәләр. Бу – баш исемнәренең калыпка әйләнгән формасы. Тешкә тиеп беткән. Шул факторга карата куен дәфтәрләремнең берсендә язма да саклана икән: Төштә кайсыдыр бер материалыма баш исеме эзлим, имеш. Ниһаять, табып куйдым, сәер бер исем иде: “Эшем кичәсе” кебегрәк. Мәгънәсе томанлы, төштәгечә. Ә менә төзелеше – уйланырлык. Тартымлы исем+исем формасы. Димәк, ул форма каныбызга сеңеп, ми күзәнәкләренә юшкын булып каткан инде (1992, февр.).

**Ике-өч сүзле троп баш исемнәре:** *Оясында ни күрсә, Канат какканда, Батыр ярасыз булмый, Бил алышу, Абрамовичның башы ике түгел* (В.Т., 2009, 11 февр.). *“Аякланган” миллиард* һ.б.

Әлбәттә, татар телендә сүзтезмәләрнең бәйләнеш формасы бик төрле. Шул мөмкинлектән файдаланырга, калыпка (шул ук тартым рәвеше) әйләнгән формаларны төрлеләндерергә тырышырга кирәк. *Икенче дулкын, Кирәксез лейтенантлар, Марокко корольлегендә, Гадәти сентябрь, Өч физкультура* һ.б.

Баш исеме ясау өчен ике сүзле сүзтезмәнең предикативлык нигезендә җөмлә функциясен үти алганнары бик әһәмиятле (мәгънә тыгызлыгы,

кыскалык һ.б*): Гөнаһка батмыйк! Кишерләре жәл, Ниһаять, яңгыр! Фатир кирәк, Акчадамыни бәхет?*

**Өч сүзле һәм аннан да күбрәк сүзле тезмәле баш исемнәре**. Алар да гадәти тезмәләр (*Атаклы тәртипкә салучы, Көтүче студент кыйссасы,* һ.б.) һәм җөмлә функциясендәге тезмәләргә туплана ала: *Асрамага мәче бирәм, Тавыгың күпме су эчә? Әтиләрдән ким яшәмәдек, 11 миллион сум көлгә әйләнгән, Тел белү бәхет икән, Урыннары җәннәттә булсын h.б.*

Җөмләнең эчтәлек ягыннан классификациясенә караган (хикәя, сорау, өндәү һ.б.) төрләре, форма ягыннан классификациягә караган төрләре (җыйнак, җәенке, ким һ.б.) дә очрый. Аларның да туры мәгънәле, күчерелмә мәгънәле, хисле һ.б. төрләре булуы ихтимал. Менә кушма җөмлә төрләре: *Кем үз вакытында үлә, шул бәхетле* һ.б.

**Баш исемендә җөмләнең функциональ төрләре:**

Атау җөмлә: *Сентябрьдә туганнар;* Исем җөмлә: *Өмет – яшьләрдә;*

Хәбәр итү: раслауны хәбәр итү: бар гомуми раслау, бар конкретны раслау: *Ярдәмнән ташламаслар, Эш хакы түләүдә чикләүләр бетерелде, Базар баштан сыйпамый, Олы яшьтәгеләрне онытkан җәмгыятьнең киләчәге булмый, Туган телнең көче зур, Тарих гафу итмәс* һ.б.

Була каршылыклы (интрига) раслау (“мөгез чыгару”): *Троллейбус урлаганнар:* тискәрене (инкарьне) хәбәр итү; Мөрәҗәгать итү*: Бер көн белән генә чикләнмик, Сабак булсачы, Бәрәкәтле булсын! Бәйрәмгә әйләнмәсен* һ.б.; Сорау җөмләле баш исемнәре: *Без кышка әзерме? Бәрәңгене кая куярга? Нинди әлифба кулай? Кайдан килә начар хатыннар* (Т.я., 1978, 17 окт.); Өндәү җөмләле: *Әдип рухын рәнҗетмик, Улыбызга ярдәм кирәк* һ.б.

Язма сөйләм, әйтмә сөйләм лексикасы нисбәтенең саклануы да зарур. Бөтен газет гади сөйләм рәвешендәге башлардан торса, “гадиләштерү” тоны барлыкка киләчәк. Хәер, укучы хатларыннан торган махсус сәхифәдә моңа тискәре караш тумый шикелле: *Татар мәктәпләре кая киткән? Кияүдән кайтып йөрмәдек, Ябыштырсыннар!, Безгә дә кирәк әле ул, Чыннан да чират микән?* (Т.я., 2010, 20 ноябрь);

Ә менә рәсми хәбәрләр тупланмасындагы баш исемнәренең “гадилеге” уңай тәэсир калдыра микән? *Ата кара тараканның кан әйләнеше...; Бәдрәф кәгазе ... яный, Беткә ачу итеп* (Т.я., 2010, 20 ноябрь).

Туры мәгънәле җөмләләр: Менә бер газетның бер баганасындагы баш исемнәре (В.Т., 2010, 6 окт): *Сулыклар саеккан, Чүп түгүчеләр арткан* (үткән заман хикәя җөмлә); *Тәртип бозалар; Суд эше карала* (хәзерге заман хикәя җөмлә).

Җөмлә функциясендәге, үзгә синтаксик формалы берәмлекләр: *Артмаячак... әлегә;* Әйтеп бетермәү, фикерне (хәтта төшенчәне) өзү;

*Кемгә бәйрәм, кемгә...;* Күчерелмә мәгънәлелер*: Безгә тагын аларны җиңү! Безгәме соң!...* (Т.я.,2010, 11 ноябрь);

Күчерелмә мәгънәле җөмләләр*: Кыйблам кыйбла ягында, Кулдан каләм төшкәне юк, Бакыр базлары корыдымы?* һ.б.

Күчерелмә мәгънәле сүз кергән җөмлә: *Төп башына утырмыйм, дисәң, "Нечкә" мәсьәлә хәл ителә* һ.б.

**Җөмләдән зур берәмлекле баш исемнәре**

Туры мәгънәлеләр: *Кем итне кыйммәт ди, авылга кайтсын да мал асрап карасын; Зәйгә карап хәйран калам: әй суы ла, әй кыры!,*

**Күчерелмә мәгънәлеләр (троплар)**: Күчерелмә мәгънәле сүз яисә гыйбарә (тезмә) кергән берәмлекләр: *Гатаулла янә "ат өстендә"* (Т.я., 2007, 18 дек.).

Метафора, метонимия: *Кулларында ут уйный* һ.б.

Антоним, оксюморон, антитеза тибындагы троплар: *Тирестән ягулык, Әҗәлгә дару бар, Җавапсыз калган сорау, Зәгыйфь җәмгыять җимешләре (Ш.К.,2008, 19 дек.); Зират карагын утырттылар, Җинаятьче иректә йөргән, Эчәргә микән, эчмәскә микән, Ит комбинатында бизәнү әйберләре, Тешсез әби сызгыруы, Бар һәм юк, "Шикле" бәйрәм шиксез узды, Дөнья киңлегеннән ни мәгънә бар, аягыңда кәвеш тар булгач..., Каза күрүче хөкем ителүчегә әверелә* һ.б.; Мәгънәви оксюморан: *Ноябрьдә ... яшен*! (Т.я., 2010, 13 ноябрь.); *Югала язган ... зират* (Шунда ук);

Кабатлау: *Бию, тик бию генә, Акча кирәк, акча* һ.б.

Фразеологизм: (тулы килеш) *Барып чыктык...* (Т.я., 2011, 9 апр.); *Төбенә төшеп* (Т.я., 2011, 23 июнь); (Үзгәртелгән)*: Борыныгызны салындырмагыз!*

Әйтем*:* (тулы килеш) *Акча санаганны ярата*; (Үзгәртелгән): *Бәхетсезгә җил каршы, Миннән киткәнче..., Эт өрә торыр, барс йөри торыр, Эшчән эштә беленер* (Т.я., 1983, 26 апр.);

Мәкаль: (тулы килеш) *Киңәшле эш таркалмый, Иске яңаны саклый, Башланган эш – беткән эш, Җылы сүз – җан азыгы, Өч тиенлек куян, биш тиенлек зыян, Башың эшләмәсә, аягың күп йөрер, Җил басылмый – гөл ачылмый, Хезмәтенә күрә хөрмәте* (А.х., 1983, №5); (Үзгәртелгән) *Түшенә дә кара, Искегә тигәч, ис китсә дә... Май ботканы бозмый* һ.б.

Канатлы гыйбарә, җырдан, классиклардан өзек: *Исемең котсыз, кемнәр куйган*?

Автор афоризмы; җор гыйбарәләр: *Башлык булсаң – башлы бул, җыерылмас кашлы бул...* (М.Рафиков. Ш.К., 1996, 30 гыйнв.*), Гөл син, Гөлсинә* (Ш.К., 1996, 10 гыйнв.), *Табасына күрә тәбәсе* (Әтнә таңы, 1992, 24 июль), *Арылар ары китә* (Шунда ук), *Кадрәктә нәрсә кадерлерәк* (Р.Сабыр), *Битарафлык кай тарафтан* (С.Т., 1987, 11 апр.)*, Үзәккә үткән "үзәк"* (Т.я.,), *Көчле агым – тирәндә* (М.Хөснимәрдәнев. В.Т.,1988, 22 июль), *Чистай паромы погромчылары ...* (Айдар Хәлим. Ш.К., 1991, 24 май.) Автор үзе болай яза: Мин язмаларымны урыс телен мактау белән

башларга тиешмен. Үзегез игътибар итегез, әфәнделәр һәм ханымнар: “Чистай паромы погромчылары. Бу сүзләрдә никадәр моң бар! Паромны татарчалап “кичү” дип әйтсәң, “кичү”гә “кисү” сүзен өстәргә кирәк була, Йә, әйтегез инде, кайсысы музыкальрәк: “Чистай паромы погромчыларымы, әллә “Чистай кичүе кисүчеләре”ме? Әлбәттә, беренчесе!”

Туры сөйләмнән, төрле стиль-сөйләмнәрдән өзекләр. Әзәл Яһүдиннең “Артист язмалары” берничә парчадан торып, һәркайсына баш исем бирелгән иде (С.Т., 1984,18 апр.). Газетның шул санында бүтән баш исемнәрен укудан туктап, шуларга тартылып кителде: *“Исәнмесез, иптәш Вәлиев?”, Шәп номер, “Ничә бригада төзеп булыр?”, Артомонов нигә керми?, “Не правдашный конфетлар...”, “Ну жулик!, “Яп, яп, яп!”.*

Аваз яңгырашы, каламбур: *Берчак... борчак, Алган алганда кала, “Юлдаш”ны юлдаш итик, Шамил белән камил театр* (В.Т., 1995. 24 март. Т.Миңнуллин.), *Камыш арасында танышым, Бакча хикмәте акчадамы?* (В.Т., 2010, 13 нояб.), “*Алколазер” эләктерергә әзер* (Т.я., 2010, 13 нояб.).;

Омоним, омофон: *Ельцинга хәзер нинди төс төс* (Т.я., 1996, 27 гыйнв.*),”Манекеннар балы”* (ашый торган балмы, кичәме, баллмы?), *Алтын балык тотсамы?*

Сынландыру, сурәт ясау (бөтен бер образ): *Ямьсез этнең дә ашыйсы килә, Ул сызган буразналар* (С.Т., 1979, 29 март). Җирдә буразна сызу тормыш юлларын салу образы булып үскән; *Күңелгә төшкән очкын, Бөреләнгән хыял (*С.Т., 1979, 30 март*), Җилдән җитез* (Йолдыз, 1976, 11 дек.).

**Баш исеме – композиция элементы.** Текстка ничек бәйләнеп китә?

– аңлатмалы баш исеме: *Без – мелиораторлар, диләр зур горурлык белән Күгәрчен урта мәктәбе укучылары*;

– баш исеме – текст башламының аерылгысыз дәвамы: *Балалар тынычлык теле. Безнең мәктәптә әнә шундый девиз белән рәсем конкурсы үтте* (Яшь ленинчы, 1983, 26 гыйнв.). – *Үзем сөйлим, үзем*! *Миннән сорагыз. Элек авызыннан бер сүз тартып алуы мең газап булган Валера дәрес саен җавап бирергә теләп кул күтәрә ;–Ышанма, Оля, ышанма син юк-барга*! (Бу баш исемнәре – текст эчендәге кечкенә бүлекчәләрнең баш исеме (Я.л., 1984, 7 апр.); *Әдәбият тарихын ничек язарга? Әдәбиятчеләрнең, фольклорчы, тарихчы галимнәрнең, фәлсәфә, тел белгечләренең... зур сөйләшүләре үзәгендә шушы мәсьәлә торды; Тәмәке тартмаучылар шәһәре. Дөньяда хәзер андыйлар да бар* (Календарь, 1984, 19 окт.). *Нилектән чират. Эшне оештыра белмәүдән. Моны башкача аңлатып булмый* (Коммунизмга (Арча), 1985, 4 июль). *Алдагы атнада, шимбә көнне илебездә Физкультура көне билгеләп үтелә* (С.Т., 1985, 1 авг.).

Баш исеменең текст белән бәйләнеше башламда гына түгел, бәлки бөтен текст буена, хәтта үтәли образ буларак, текст эчендә эледән-эле

кабатланып (бoҗраланып) килә. Рахмай Хисмәтуллинның “Зәңгәр мәтрүшкәләр” очеркы (С.Т., 1979, 17 апр.). Әмирхан Еникинең “Җиз кыйгырау” хикәясен телгә алган идек инде. Бу – талант билгесе, зур осталык сорый торган алым.

Ә менә К.Тимбикованың тимерче Сәрвәрне сурәтләгән очеркында *“Алтын сәгать”*– очраклы гына деталь. Шул деталь очеркның исеме итеп чыгарылган. Югыйсә, алтын сәгать тискәре персонажны фаш итүдә генә катнаша. Бу китап кульъязмасына рецензия язган Рәшит Зәкиев исемне алыштырырга тәкъдим итә, моның кирәклеген исбатлап бирә.

Китапта, газет битендә, журналда баш исеменең техник урнаштырылышына да игътибар кирәк. Рубрика – өстә, аннары баш исеме. Шрифтлар, сурәт нәкъ караш төшәрлек, ачык күренерлек итеп куелырга тиеш. Менә мондый җитешсезлекләр очрый:

“Сөт елгасы басудан башлана”. Сүз сөт алу, сыер көтүе турында бара. Янәшә үк “Көтү бушка китмәде” дигән баш исеме. Уйда әле сыер көтүе тора. Тагын көтүгә ни булды икән? дигән уй белән укый башлыйсың. Баксаң, болнис төзелешенең кайчан бетүен *көтәләр* икән. (В.Т., 2006, 28 июнь).

“Башсыз”лар. Менә *“Пресс-группа хәбәр итә”* башы астында тупланма бирелгән. Анда районнарда кыр эшләренең барышы турында сводка һәм шул мәгълүматка комментар бирелгән. Тик һәр материал композицион бүленмәгән, баш исеме белән дә аерылмаган. Әле рәсем дә бирелгән, тик ул да текстан аерылмаган (С.Т., 1984, 7 июнь).

Баш исеменең график (типографик, полиграфик) бирелешендә кимчелекләр: Сүз формаль (мәгънәсе бөтенләй күздә тотылмыйча) бүленә: “Бакча – *чыга*”, “*Кур –гәзмә, – мәгәнне, – сәтә*” (мәгънәсез кисәкләр).

Әсәр эчендәге кисәк, бүлек, параграфларга баш исеме куйганда аларның эчтәлек белән бигрәк тә тыгыз, аерылгысыз бәйләнгән булуына, эчтәлекне тулыландырырлык өстәмә чара тәшкил итүенә ирешергә тырышырга кирәк.

**Тәрҗемә текстларына баш исеме куйганда** оригинал авторының, оригинал редакторының, тәрҗемәченең фикерен дә белергә, истә тотарга кирәк.

Теманы тирәнтегрәк өйрәнергә теләүчеләргә янә бер мәгълүмат биреп китәбез. Узган гасырның сиксән-туксанынчы елларында Россия Дәүләт китапханәсе “Указатели заглавий произведений художественной литературы” дигән күптомлы җыентык чыгарды. Күз йөртеп чыгу белән үк кайбер нәтиҗәләр ясарга була; әйтик, хәтта әдәби (бик шәхси иҗат бит инде) әсәрләрнең дә исемнәре еш кабатлана икән. Менә шул шәхси табыш

булганга күрә дә аны кабатларга омтылалар икән. Җыентыкларга рецензия язган А.Калганова болай ди: (В мире книг, 1986, №9, 71 б.): Исем образлырак, гомумиләштерелгәнрәк булган саен аның вариантлары күбрәк ясала икән. Әдәби реминисценцияләрне плагиатлыкка санамаска кирәктер, бу хәл сирәк очрый торган табыш-образның эстетик яктан продуктив булуына дәлил генәдер”.

**Күнегү:**

– бу баш исемнәренең чыганагын ачыклагыз, үзгәртү алымнарын әйтегез: *Ташламам, җанкисәгем, Бер күрешү – үзе мең шифа, Айкап җибәр, селтәп җибәр, Кем тегермәненә су коябыз? И машина, машина, җитте минем башыма, Оча, оча ... акбурлар оча, Маймылда да кеше язмышлары, Ач сандугач сайрамый, Дөнья өстендә ... Арча кусәге* (М.ж., 1997, 13 июнь. Р.Шәрәфиев.).

## *Унынчы тема:* Редакцияләү – сөйләм эшчәнлеге (Текстның тәэсир чараларын, телен, өслүбен камилләштерү)

*Бүлекнең кыскача эчтәлеге:*

Редакцияләүнең сөйләм эшчәнлеге булуы – кульязмада тел чараларын (сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст өлешләре һ.б.) аралашуның иясенә, адресатына, максатына, шартларына карап дөрес һәм төгәл табу, камилләштерү. Бу юнәлештә автор юл куйган кимчелекләрне анализлау, бетерүдә аңарга ярдәм итү.

Тел чараларына куела торган төп таләпләр: ачыклык, төгәллек, кыскалык, образлылык, аһәңлелек һ.б. Туган телнең байлык-хәзинәсеннән тулы файдалану мөмкинлекләре. Әсәрнең әдәбият төренә, жанрына карап тел чараларының, өслүб мөмкинлекләренең төрләнүе. Авторның тел үзенчәлекләрен кульязмада саклау алымнары, татар редакторларының бу өлкәдә бай тәҗрибәсе. Авторның иҗади сәләтен дәртләндерү алымнары. Әдәби тел нормалары һәм редактор.

Туган телнең сүз байлыгыннан тулы файдалану. Төгәллеккә ирешүдә синонимнар белән дөрес эш итү. Телнең конкретлыкка, документальлеккә ирешү чаралары: атамалар, термин, профессионализмнар һ.б.; телнең хис белдерү, бизәкләү чаралары: күчерелмә мәгънәле бирәмлекләр, фразеологизмнар һ.б. Алынма сүзләрне, канцеляризм, техницизм, газетизм, диалектизм, жаргон кебек берәмлекләрне урынлы куллану. Неологизм, архаизмга карата дөрес мөнәсәбәт. Яңа термин ясау, хәрәкәттәгеләрен камилләштерү барышында, гомумән, телне үстерү эшендә редакторның җаваплылыгы.

Сөйләм төренә, өслүб максатларына карап телнең грамматик чараларыннан дөрес файдалану. Бу юнәлештә юл куела торган

кимчелекләр. Татар теленең агглютинативлык үзенчәлеге-хәзинәсеннән файдаланып җиткермәү. Кушымча тавтологиясе. Парлы сүзләрнең, ярдәмче фигыльләрнең, мөнәсәбәт берәмлекләренең мәгънә төсмерен төрләндерүдә мөмкинлекләреннән тулысынча файдаланмау.

Синтаксик синонимия мөмкинлекләре. Авторның иҗади сәләтен көчәйтү юллары. Урынсыз инверсияне төзәтү. Текстта сүзне, җөмләне, хәбәрләмәне бер-берсенә бәйләү чараларын дөрес куллану, төрләндерү ихтыяҗы.

Тәрҗемә текстында типик кимчелекләр. Аларны төзәтүдә ана теле чараларыннан тулы файдалану. Тәрҗемә сөйләменең тискәре йогынтысыннан котылуда редакторның җаваплылыгы.

Радио,-телевидение тапшыруы өчен текстны әдәби эшкәртү үзенчәлеге. Аваз. Синтагма. Мантыйкый басым. Татар интонациясе. Орфоэпия кануннарының үтәлүе. Язма һәм әйтмә сөйләм аермасы каршылыкларыннан котыла белү. Кимчелек очраклары, алардан арыну юллары.

Текстны төзәтүдә телдән башка (экстралингвистик, паралингвистик һ.б.) чаралар һәм өслүб мөмкинлекләре, аларны дөрес, иҗади куллану алымнары һәм тәҗрибәсе.

Безнең редакцияләү эшен сөйләм эшчәнлеге белән бәйләвебез очраклы түгел: сөйләм эшчәнлеге –ул, ягьни фикереңне тел (һәм башка чаралар) белән белдерү эше өч яссылыкта була ала дигән идек: әсәрне әйтергә яисә язарга әзерләү һәм шуны башкару; бер телдә формалашкан фикерне икенче телдә бәян итү (тәрҗемә) һәм менә автор әзерләгән текстны төзәтү яссылыгы. Шушы методика белән эш итү редакторга күп кимчелек-хаталардан азат булырга мөмкинлек бирә. Асылы редакторлау барышында төп бурыч – мәгънәгә тәңгәл берәмлек сайлап алу бурычын мотивларга – сөйләм иясенә (С.И.), сөйләм адресатына (С.А.), сөйләм ниятенә (С.И.) һәм сөйләм шартына (С.Ш.) таянып үтәүгә күнегү аңарга күп җиңеллек бирә. Жанр үзенчәлекләренең күпчелеге дә мотивларга бәйле сөйләм төзү үзенчәлеге белән тәңгәл килә. Жанр бит ул сөйләмнең бер төре, аерма шунда гына: җанр ул шушы халыкның, милләтнең аңында озак еллар формалашып тарихи категориягә әверелгән сөйләм төре.

Редактор С.И. буларак, иң башта шәхси үзен (холкын-фигылен, тел тоемлавын, белеме, һөнәри тәҗрибәсе дәрәҗәсен, редакторлык һәвәслеген, бүтәннәр белән аралашу үзенчәлекләрен һ.б) яхшы белергә тиеш.

**Редакцияләү – сөйләм оештыру эше ул**

Текст сөйләм мотивларына нигезләнеп төзәтелә, ягъни төзәтү чаралары, язгандагы кебек үк, тел һәм башка чаралар сөйләм иясенә (С.И.), сөйләм адресатына (С.А.), сөйләм ниятенә (С.И.) һәм сөйләм шартына (С.Ш.) карап эзләп, сайлап алына.

Сөйләм мотивын канәгатьләндерү максатында кулланыла торган иң беренче корал-чара – ул ана теле. Безнең очракта – ул татар теле. Әдәби редакцияләү процессының иң төп өлеше, иң җаваплы һәм соңгы нәтиҗәгә китерә торган өлеше – ул кульязманың сөйләмен ачык, анык, аңлаешлы, үтемле, тәэсирле итү максатында ана теле чаралары белән камилләштерү.

Текстны камил төзәтү өчен, табигый ки, сөйләмнең ике үзәген дә камил белергә, аларның хәрәкәт, тәэсир системасын-механизмын ачык күзалларга һәм гамәлдә төгәл үтәргә тырышырга кирәк. Сөйләм мотивларын ачык, төгәл күзаллаганда гына аларга тәңгәл чара-коралны, ягъни тел чараларын тәгаен тоемларга, табып куярга, кирәк булса, үзгәртергә мөмкин. Хәзер без корал-чара буларак ана телебезнең мөмкинлекләрен барлыйбыз. Һәр очракта, һәр мисалда аларның нәкъ менә теге-бу мотивка бәйле рәвештә генә сайлап алынуын, табылуын истә тотарга тиешбез.

Гадәттә редакцияләү барышында без сүз белән эш итәбез дип уйлыйбыз. Килешик: без төшенчә белән эш итәбез. Ә төшенчә ул мәгънә белдерә торган берәмлек, гадәттә без аны сүз дип күзалларга күнеккәнбез. Ә гамәлдә ул мәгънә белдерә торган теләсә кайсы берәмлек – аваз, иҗек, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст өлеше була ала. Ягъни ул фонема, морфема, лексема, фразема да була. Редакцияләү курсын үткәндә, редакцияләүне сөйләм процессы дип күз алдында тотканда шушы терминнар белән дә, беренче чиратта, лексема термины белән дә эш итү урынлы булырдыр. Димәк, төзәтү максатында без автор уйлаган, язган контекстта ул белдерергә теләгән мәгънәгә тәңгәл берәмлекне –лексеманы таба алмаган очракта, без аңа нәкъ тәңгәл лексема эзләргә булышабыз. Бу очракта ул сүз кулланган икән, дөрес, кулай, нәкъ урынлы берәмлек фонема да, морфема да, лексема да була ала, хәтта фразема булу очрагы да ихтимал.

Бу эшнең чыннан да катлаулы, аңа чын белгечләр кирәклеген дәлилләүче берничә генә мисал:

ГАИ хезмәткәрләре һәм шәһәр санитария-эпидемиология станциясе работниклары тикшерүеннән күренгәнчә, автобуслар һәм йөк транспортының байтагы *линиягә эшләнгән газларда углерод окисе микъдаре күп булган хәлендә чыга* (С..Т., 1982, 4 июнь). Сүз отработанный, ягъни янып чыккан газ турында бара икән.

*Яисә*: *Гражданлык бурычын үтәп тавыш бирү үзе үк барлык сайлаучыларның тормыш позициясен демонстрацияләгән кебек, депутат буларак халык ышанычын аклау өчен армый-талмый көрәшү коллективлар вәкилләренең зур активлыгын күрсәтә* (Байрак, 1982, 22 июнь). Нинди “томан”, буталчыклык!

Нигә шулай килеп чыккан? Сөйләм ачык, аңлаешлы, эзлекле, тәэсирле булсын өчен аны хәзер ничек төзәтергә? Аңлашыла ки, һәр гади нәрсә катлаулылыкны, каршылыкны җиңү нәтиҗәсендә туган кебек, монда да шул закончалыкны истә тотып эш итәргә кирәк була. Бу очракта каршылык шунда: сүз үзе генә торганда ачык, аңлаешлы булуы гына

җитми, ул тулаем сөйләмдә төгәл дә, кыска, туры, эзлекле, тәэсирле (хисле, дулкынландыргыч) та булырга тиеш.

Янә бер каршылык: без, гадәттә, тел исрафлыкка юл куймый, анда бер мәгънәгә – бер сүз, дибез. Бу – дөрес, әмма әлеге төшенчә, тормышның, кеше аңының үзе кебек үк, бик күп төсмерле, ньюанслы. Шуңа карап тел дә чагыштырмача бер мәгънәгә күп төрле запас вариантлар – синонимнар тота. Бер караганда, әйтик, *бөтен – барлык, шактый – байтак* синоним рәтләрен алсак, алар бер мәгънәле (абсолют) синоним кебек, ә контекстта, редакцияләү барышында *шактый*ның предметка тартымлыгын (шактый күп), ә *байтак*ның вакытка бәйлелеген тоемлавы кыен түгел. *Мәче – песи, көпчәк – тәгәрмәч* синонимнарның да мәгънәви аерымлыгын тоемларга буладыр. Автор еш кына боларга сизгерлеген югалта. ә редакторга мондый кимчелек гафу ителми. Бу каршылыкны ул һичшиксез җиңәргә тиеш.

Хәзер инде, бер караганда, авторлар белемле, телне мәктәптә, хәтта югары уку йортларында өйрәнә, төрле шартларда (мәгълүмат чараларында, матур әдәбият, фәнни, рәсми әдәбият, эпистоляр әдәбият, реклам, сәхнә-эстрада һ.б.) куллана алалар. Күрәсең, югары сыйфатлы итеп редакцияләү өчен бу шартлар гына җитми. Нинди өстәмә шартлар кирәк?

– редактор да телне, язучы, журналист кебек үк, нечкә тоемларга, бу һөнәргә аның сәләте генә түгел, таланты да булырга тиештер. Гамәлдә дә редактор таланты дигән сыйфатның булуын танырга кирәк, аны белү, фәнни өйрәнү, үзеңдә тою күнекмәләре булдыру зарурдыр;

– телне гомумән белү генә җитми, андый белем кирәк тә кирәк инде, тик телне белү дигәндә асылда редакторның сөйләмне белүе, ягъни телнең хәрәкәттәге, кулланыштагы хәлен, закончалыкларын төпле белүе таләп ителә. Ә бу исә һәр редакторның сөйләмият нәзәриясен, аның төп категорияләрен (сөйләм мотивлары: С.И, С.А., С.Н., С.Ш., сөйләм чарасы-кораллары һ.б.) белүе мәҗбүридер. Төзәтү барышында теге-бу кимчелекне бетерү кыенлыгы килеп чыкканда менә шушы сөйләм формуласына, аның төп мотивларына игътибар итү, күзаллау үзенә күрә бер ачкыч та була ала. Әйтик, төзәтелә торган текстның авторын, аның язу үзенчәлекләрен, әсәрен кемгә адреславын, нинди ният-максатны күз алдында тотып язарга алынуын, кайсы төбәктән, нинди һөнәр иясе булып телне ни дәрәҗәдә белүен, шул ук вакытта текстны басарга тәкъдим ителгән газет, журналның, радио,-телевидение тапшыруының үзенчәлекләрен, тагын да эчкә кереп – жанрының, стиленең нәкъ шушы язма, тапшыруга тәңгәл килүен һ.б. күп кенә төсмерләрне белү зарур;

– төп шартларның янә берсе ул – корал-чара (инструмент) буларак телне һөнәри инструмент дәрәҗәсендә яхшы, җентекле белү мәҗбүри. Һәр элементын-өлеш-кисәген-категориясен: аваз, иҗек, сүз, тезмә, җөмлә, микротекстны һ.б. Шул ук вакытта телдән аерылгысыз экстралингвистик, паралингвистик чараларны (тавыш, төс, ым-ишарә, хәрәкәт һ.б.). Һәр категориянең куллану үзенчәлекләрен (мәсәлән, авазларның әйтү һәм язу

аерымлыкларын), әйтик, татар теленең иҗек-кушымчаларының, мөнәсәбәтле берәмлекләренең мәгънә мөстәкыйльлегенең башка телләр белән чагыштырганда күпкә продуктив булуы, сүзләрнең туры мәгънәлелек (исем-атамалар, терминнар, алынма, неологизм, архаизм, диалектизм, профессионализм, жаргон һ.б.), төрле мәгънәлелеге (синоним, омоним, антоним, пароним), күчерелмә мәгънәлелеге (троплар); тезмәләрнең күп төрле булу мөмкинлеге (туры мәгънәле һәм күчерелмә мәгънәле – фразеологизмнар, язма сүзтезмәләр һәм синтагмалар); җөмлә төрләрен максатчан куллану проблемасы, текст синтаксисы мөмкинлекләрен редакцияләүдә файдалану күнекмәләре һ.б.

Редакторга татар теленең мондый мөмкинлекләрен нечкә белү – үзмаксат түгел. Бу аңарга әсәргә, текстка куела торган төп таләпләрне җиренә җиткереп үтәү өчен кирәк. Беренче чиратта нинди максатларны? Без аларны галим Вәли Хангилдин күрсәткән тәртип-система белән китерәбез:

**Ачыклык яки җиңел аңлаешлылык.** Үзе төбәлгән кешеләргә (укучыга, тыңлаучыга, утырдашка) карата сөйләмнең җиңел, анык аңлаешлы булуы “ачыклык” дип атала. Бу таләп буенча сөйләмнең лексик, фонетик-орфоэпик, грамматик, стилистик һәм орфографик яклары, аннан аңлашылырга тиешле төшенчәне, эчтәлекне төрлечә боргаларга, юрарга юл калдырмаска тиеш. Сөйләм төзелмәсендәге сүз, сүз формалары, синтаксик бәйләнеш, язылыш һ.б. анда тәгъбир ителгән төшенчәнең, эчтәлекнең тиешенчә аңлашылуына комачауламавы зарур.

Сөйләмдә ачыклыкның булмавы яки җитешмәве, күбесенчә, анда аңлаешсыз яки авыр аңлаешлы сүзләр, чит сүзләр, ят формалар, тәгъбир һәм синтаксик төзелмәләр катнашудан килә. Һәрбер әдәби сөйләм үзе төбәлгән кешеләрнең хәленә, аң-белем дәрәҗәләренә исәп тотып, шуларга ачык аңлашылырлык итеп төзелергә тиеш.

Шул шартлар үтәлмәсә, хәзерлекләре җитәрлек кешеләр дә (С.А. – *И.Н.*) кайбер җөмләләрнең эчтәлеген тиешенчә аңлар өчен артык вакыт һәм көч исраф итәргә мәҗбүр була.

Бу тезисларны исбатлар өчен китерелгән мисалларның кайберләрен дә без, алар бүген дә кимчелек буларак еш кабатланганга күрә һәм галимебезгә хөрмәт йөзеннән, аныкыларны алырга булдык:

*Язгы ташкыннар бик каты тирәнәйткән* (С.Т., 1964). *Бик нык тирәнәйткән...* кирәк; *Майский урамында кайчандыр тавык атлап чыга торган ермакка хәзер ике катлы өйне утыртсаң да кыегы белән кереп бетәчәк* ( С.Т., 1964). *Атлап чыга алырлык ерганак; түбәсе белән кереп бетәчәк* ... диелергә тиеш (Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. Казан, 1976. 35 б. Алга таба битләр генә күрсәтеләчәк);

**Сафлык.** Бу таләп әдәби сөйләмдә лексик, фонетик, грамматик, стилистик яктан кытыршылыклар, чуарлыклар урын алмаска тиешлекне, сөйләмнең андый күренешләрдән чиста, саф булуын күздә тота. Чөнки алар сөйләмнең тыңлаучыга һәм укучыга җиңел аңлаешлылыгын киметә.

Мәсәлән, кирәксезгә бүтән тел сүзләрен, борынгы диалекталь яки гади сөйләм сүзләрен, фонетик күренешләрне һәм синтаксик әйләнмәләрне куллану әдәби сөйләмнең сафлыгын боза, шуның белән бергә аның күрке, хәтта әйтелү, укылу җиңеллеге дә кимергә мөмкин. Андый нәрсәләрне сөйләмгә кертү бары тик стилистик әһәмияте яки бүтән берәр кирәге булганда гына аклана. ...Берничә мисал: *Әлләни доходлы эш түгел бу* (С.Т., 1964); *Бу турыда мин җитәкчеләрдән сорашып бактым* (С.Т., 1964); *...станция буенча тыңлагыз* (Радиодан). Дөресе: *... станциядән тыңлагыз*". (36 б.).

**Җыйнаклык.** Бу таләп әдәби сөйләмдә билгеле төшенчәне уйны аңлату өчен кирәге булмаган, артык тел чаралары (сүз, термин, сүз формасы, синтаксик чаралар, урынсыз кабатлаулар һ.б.) булмаска тиешлекне күздә тота. Ягъни, тел материалын файдалануда экономияле булырга һәм тавтологиядән сакланырга кирәклекне искәртә.

Сөйләмнең җыйнаксызлыгы төрлечә чагылырга мөмкин:

а) Билгеле бер сөйләмдә сүзләрнең һәм сүзформаларның кирәгеннән артык булуында. Мәсәлән, ким җөмлә яки сүз-җөмлә белән тәгъбир итәргә кирәкле яки мөмкин уйны тулы җөмлә белән белдерү; ярдәмлек сүздән яки кушымчадан башка ук аңлашыла торган төшенчәне яки аның төсмерләрен белдерү өчен, кирәге булмаган шул элементларны куллану. Мәсәлән, *библиотеканың бу китабы миндә* диясе урында *библиотеканың бу китабы минем артымда* дию. һ.б.

б) Сөйләмдә бер үк сүзне һәм сүзнең теге йә бу элементын яки җөмләнең бер үк кисәген кирәксезгә кабатлауга. Мәсәлән, җөмләнең тиңдәш кисәкләре арасында бер үк мәгънәдәге теркәгечләрне яки кушымчаларны яисә тезмә кушма җөмлә төзелешендә шундый ук элементларны кабатлау һ.б.

в) Сөйләмдә гади җөмлә белән белдерелергә тиешле яки мөмкин булган фикерне кушма җөмлә белән тәгъбир итүдә.

г) Бер баш кисәкле җөмләдә тәгъбир ителергә кирәкле яки мөмкин булган фикерне ике баш кисәкле җөмлә белән белдерүдә.

д) Сөйләмдә мәгънәдәш (синоним) сүзләрне һәм синтаксик төзелмәне (конструкция) кирәксезгә күбәйтүдә. (Мисалларны текстан кара, 36–37 б.).

**Аһәңлелек.** Сөйләмнең һәм аның кисәкләренең әйтелеш, укылыш, ишетелү һәм аңлау ягыннан уңайлылыгы аһәңлелек дип атала.

Бу таләп җиңел һәм аңлаешлы укуны тәэмин итәргә, шуның белән, ул укылганны тыңлаучыга җиңел аңлау мөмкинлеге тудырылырга тиеш.

Телдән сөйләгәндә исә бу таләпнең әһәмияте тагы да зуррак. Чөнки аһәңсез сөйләм тыңлаучыны тиешенчә кызыксындырмый; сөйләмнең эчтәлеге әһәмиятле булса да, тыңлаучыны үзенә тиешенчә тарта алмый. Шуңа күрә аһәңсез сөйләгәндә тыңлаучылар, гадәттә, пассив булалар. Аһәңлелек таләбе җиренә җиткерелеп сөйләнгән речләрне, лекция һәм, гомумән, чыгышларны тыңлаганда исә тамашачылар үзләрен бөтенләй

башкача тоталар: җанланып, йотылып тыңлыйлар, сөйләмнең эчтәлеге дә аларга барлык мәгънә төсмерләре белән бик җиңел барып җитә. Шуның өчен, тел культурасы турында сүз йөрткәндә, сөйләмгә карата мондый таләпне бервакытта да онытырга ярамый.

Сөйләмдә аһәңлелек нинди чаралар белән булдырыла соң? Ул – әдәби сөйләмнең һәр ике төрендә яшәгән нормаларны җимермәү, тулысынча үтәү белән тәэмин ителә. Мәсәлән, бүгенге әдәби телебездәге сөйләмдә, кем дә булса, бөтенләй кирәксез һәм урынсыз *"инкыйлаб, ясак"* сүзләрен яки *"әйтмәк кирәк", "алгалы килдем", "кайчан ки авылга кайтам, сиңа хат язармын"* кебек сүз яки әйтелмәләр кыстырып яза яки сөйли икән, ул инде ягымлылык таләбен үтәмәгән була. Иске яисә диалекталь сүзләрне еш куллану, бер үк сүзне һәм тәгъбирне кирәксезгә кабатлау – һәммәсе дә аһәңлелекне киметәләр.

Телдән сөйләгәндә исә аһәңлелек әдәби әйтелешне һәм, гомумән, телдәге авазларны, ритмик-мелодик күренешләрне оста файдалану юллары белән тәэмин ителә.

Аныклый төшсәк, бу өлкәдә ягымлылыкны боза торган моментларның ешрак очрый торганары менә болар: укыганда яки сөйләгәндә ыңгырашу, бер тонлылык, тукталыш, тынышларга тиешенчә игътибар итмәү, басым һәм интонацияләрне урынсыз куллану, бер үк һәм бер-беренә бик якын авазларны еш кабатлау һ.б.

Аһәңлелекне төзәтү өчен редакторга тел чаралары белән бергә экстралингвистик һәм паралингвистик чараларны белеп, ышанычлы куллану да зарур икән. Бу чараларга без алда махсус тукталырбыз. Хәзер исә В.Хангилдин күрсәткән таләпләрнең редакцияләү барышында тулысынча үтәлмәү аркасында килеп туа торган җитешсезлекләргә тукталып китү кирәктер. Нинди төр төгәлсезлек һәм аларга ни сәбәпле юл куела?

– икеле-микелелек – мәгънә төсмере ап-ачык түгел: "Әйбернең икенче сортка китүе *мөмкин*" (рөхсәтме әллә ихтималмы?); "Суд карары буенча идарә аны *эшеннән азат итү* турында карар чыгарды" (эштән бушатумы, әллә эштән азат итүме?).

Мондый очракта автор "Контексттан аңлашыла ул?" дип котылырга маташа, ягъни текстны кабат-кабат азагынача укып чыгарга куша. Йа Хода! Укучыны бит алай эшләргә мәҗбүр итеп булмый – һәр төшенчә уку барышында ук төгәл аңлашылып барырга тиеш. Фикерне ике төрле аңларга, боргаланырга, юрарга юл калмаска тиеш. Уйланып тору, кире кайтып уку, сүзнең урынсыз кулланылуына ризасызлык белдерү булмаска тиеш.

Төгәлсезлекнең сәбәбе бу очракта әйтергә теләгән төшенчәгә тәңгәл мәгънәле сүзне белмәү, синоним эзләү күнекмәләре булмау, укучы алдында моның өчен җаваплылык тоймау. "Бу – бик *нәзберек* техника, чималның бер өлеше әз генә килеп җитмәдеме, аны кабул итми". Бу сүз туры мәгънәсендә җанлы нәрсәгә генә әйтелә. "Тик яңа линиягә күнегеп

бетү җиңел булмаячак. *Аңарда* эшләргә яңа эшчеләрне өйрәтергә кирәк Монда шул ук хәл, дөресе; *аңа*).

Төгәлсезлеккә әле сәерлек, гайре табигыйлык та өстәлә. Бу аеруча сирәк очрый торган, алынма берәмлекләрне кулланганда килеп чыга. “Мәктәптә реформаның дошман радиоавазлар тарата торган *идея кисәкчекләре* белән бернинди уртаклагы юк, әлбәттә (“*Вак-төяк идея”, “чүп-чар” идея* мәгънәсендә). Мондый кимчелек, гадәттә, тәрҗемә текстларына хас: “Анда 150ләп кеше катнашты, һәм һәркем икеләтә, өчләтә *энергия куеп* эшләде (“көч салып” мәгънәсендә).

Мондый очракларда дөрес сайланмаган сүзнең кәсәфәте ризасызлык, канәгатьсезлек белән генә чикләнмичә, җитди хатага да китерүе ихтимал: Халык суды аны 2 елга иркеннән мәхрүм итәргә *мәҗбүр була* (Радио, 1987, 17 дек.). Судны теге-бу карарны чыгарырга беркем *мәҗбүр итә* алмый, мондый гамәл Конституцияне тупас бозу була.

– Аеруча хәвефле төгәлсезлек – ул сүздә мәгънә тәңгәллегенә ирешә алмау. 1) Мәгънә артыклыгы: а) предмет артыклыгы: Бу кимчелек кушымчалар белән дә, өстәмә сүзләр (ярдәмче фигыльләр, мөнәсәбәтлекләр, бөтен бер сүзләр (алмашлыклар һ.б.) белән дә хасыйл була: “Бу үтенеч берләшмәдә дә күпләрне *уйландырырга* мәҗбүр итә. (Якты юл, 1982, 1 июнь). Дөресе: *уйланырга*); Билгеле, йөрәк кайнарлыгын, *аналык* мәхәббәтен, туган илне ярату хисен кушып эшләгәндә, һәр эшләре уңышлы чыга (дөресе: *ана*); ...Планны шактый*га* арттырып үтәделәр (Коммунизмга, 1979, 21 июль); Исраф*чыл*лык һ.б. *Безнең* халкы*быз үзенең* мәдәният үсешендә яңа уңышларга иреште; *Үзенең* шәхси үрнәге белән; *Җиткерелгән* задание; Аларның максаты – халыкның *һаман* үсә барган ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү; Ул халык артисты *дигән* исемгә лаек булды; Сезгә уку*лар*ыгызда яңа уңышлар телибез; Элекке бакчаларны балаларга *кире* кайтарачакбыз;

ә) сан (микъдарь) артыклыгы (тавтология): арматура*лар*, канику*ллар*, хатын-кыз*лар*, ир-ат*лар*, мотор*лар* төзү заводы (Чистай сәгать заводы бит), явым-төшем*нәр*; *Аларның икесенең* дә яше җитмештән узган; Класслы механизаторлар *бары тик* 35 процент *кына* тәшкил итә; Фәкать быел *гына*;

б) вакытның артыклыгы: *бүгенге (бүгенгесе)* көндә, *хәзерге (хәзергесе)* вакытта;

в) процессны кирәксезгә көчәйтү (арттыру): *Әледән-әле* борга*лап* куя; Әтиебез *еш кына авыргалап* тора; *Рациональ* файдалану; Сату *эшендә*; Идарәдә аны мактап *кына* телгә алдылар; Һәр участокны *пөхтәләп* чистартырга туры килде; Сокланмаслык та түгел *икән шул;*

Урынсыз көчәйтүләр (артыклыклар) өстәмә синонимнар, урынсыз тиңдәшләр белән хасыйл була: Төрле авыр хәлләрдә калган чаклары булды энинең, шулай да *түзде, сабыр итте; Тавыш, гауга* куптара. Җәмиләне төрле *әшәке сүзләр мыскыл итә, җәберли;*

г) сыйфат, рәвешләрне урынсыз (кирәкмәгәнгә) көчәйтү: Алар язгы кыр эшләрен комплекслы *төстә* алып баралар; хезмәтне дөрес *итеп* оештыру;

махсус *рәвештә*; даими *рәвештә* һ.б. Кушымча урынына аерым сүз куллану да шушы төр кимчелеккә керә; Әнием *турында* алар кайгырта (дөресе: әниемне); Чәчәкләрне аның *өчен* өздем (дөресе: *аңарга);* Урам *буенча* килә (урамнан); Җитәкче кушуы *буенча* (Җитәкче *кушканга; кушкач)*;

Мәгънәгә укучы бер сүзне кулланып күнеккән булып, автор аңа бүтән сүз (аеруча алынма берәмлек тәкъдим итсә, редактор аны төзәтмәсә, бу мәгънә барыбер төгәлсез, "томанлы" булып кабул ителә: Бригада ул хезмәтне *коллектив* оештыруның төп һәм алдынгы формасы булып тора (Кама таңнары, 1982, 12 июнь). (Укучы бит бу очракта *күмәк* сүзен кулланып күнеккән).

Төгәлсезлек мәгънә төсмеренең нейтральлегеннән дә килә, ягъни сүз битараф хәлдә гомуми мәгънә төсмерен белдереп тә контекстта конкретлыгын югалта, "томанлыга" әйләнә, күз алдына ап-ачык булып килми: Алар озак еллар буе бу *эшкә хезмәтләрен куйдылар* (Ленинчы, 1978, 15 июль). (Бу урында *эш* нәрсә дә*, хезмәт* нәрсә*; куйды* нәрсәне аңлата?). Сүз уйнату, "матур, әдәби" язарга омтылу да төгәлсезлекнең бер сәбәбе. Галия апа белән Гали абый *гомере буе* умарталыкта эшлиләр. *Чын күңелдән сөеп башкаралар* аны (Т.я., 1980, 15 февр.). Икмәк – эссегә дә, зәмһәрир салкыннарга да бирешмичә, маңгай тире белән җирне сугаручы игенченең фидәкарьлек җимеше (С.Т., 1983, 24 ноябрь).

Төгәлсезлек янә сүз мәгънәгә тәңгәл килеп тә нәкъ менә шушы сөйләмдә, шушы җөмләдә үз урынына куелмавыннан да килә:

– нәкъ шушы стиль (жанр) сүзе булмавы: ТР авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты тау битендә, *галәмәт тә матур* урында, агачларга *күмелеп* утыра. Аның 87 еллык тарихы бар. Монда фән өлкәсендә *азау ярган* белгечләр төрле сортлар тудыру, орлыкчылык белән шөгыльләнәләр (В.Т., 2007, 22 сент.). Фәнни сөйләм белән гади-көнкүреш сөйләме буталган;

– нәкь шушы урынга куелмавы: Вакытында аны *дару гына итеп* кулланганнар (Татар календаре, 1984, 20 окт.). ... *дару итеп кенә* түгелме? ЦРУ ФБРның төп эш методларын һәм формаларын үзләштерә һәм аларны *тулысынча эшендә* файдалана (*эшендә тулысынча*...). Татарда мәгънә җөмлә азагына таба – хәбәр янындарак ачыклана, төгәлләнә, тулылана бара.

Контекстта бер мәгънәле, бер төрле сүзләрнең кабатлануы (сүзгә ярлылык, сүз кытлыгы) да укучыда ризасызлык тудыра: ул бит татар телен мәгънәдәш берәмлекләргә (синонимнарга) бай дип, горурланып күнеккән. Бүген без төзүчеләр сафында алдынгы урында барырга *тиешлегебезне* онытмаска *тиешбез* (Яңа юл, 1977, 8 гыйнв.).

Төгәлсезлек сәбәпләренең янә берсе – ул күчерелмә мәгънәле берәмлекләрне (тропларны) урынлы-урынсыз куллану. Аларны кулланганда да әле туры мәгънәле берәмлекләрне кулланганда җибәрелә торган хаталарга юл куелу ихтималы бар. Мәсәлән, мәгънәгә тәңгәл килеп

бетмәгән троп: Менә скрипка ике яшь йөрәкнең бер-берсенә булган кайнар мәхәббәте турында *“сөйли”*. (С.Т., 1984, 27 апр.). (Бәлки *җырлый, көйли, моңлана*дыр);

Троплар катлаулы булмаска тиештер. *Азау ярган бөркет...* ап-ачык кабул ителми. *Бөркет* уңай – троп, ә *азау яру* – тискәре. Аларны тезмә итү төгәлсезлеккә китерә.

**Сөйләмнең төгәллек таләпләрен үтәү өчен редакторның эш алымнары**

– Тел нормаларын, стиль үзенчәлекләрен нечкә тоеп, яхшы белеп язган автор да редакторлык вазыйфасын тулысынча үз өстенә ала алмый. Әйткәнебезчә, редактор сәләте, таланты, шушы һөнәргә һәвәслеге ана сөте белән генә бирелә. Шул ук вакытта ул шушы табигый сәләтне, мөмкинлекне файдаланырга өйрәнергә, күнегергә тиеш. Моның өчен ул телне тоемлау, аны сөйләм максатларын (мотивларына бәйләп, яраштырып) белеп файдаланырга, махсус күнегүләр ясарга, кыскасы, гомере буе укырга, өйрәнергә, бөртекләп тәҗрибә тупларга тиеш. Моңа ничек өйрәнү, тәҗрибәне ничек туплау һәркемнең шәхси эше, кем әйтмешли, һөнәри “сере”. Шулай да кайбер гомуми закончалыклар, кагыйдәләр дә бар. Аларны мәгълүм авторларыбызның дәреслекләреннән, уку кулланмаларыннан да чүпләп тупларга була. Тәҗрибәле редакторлар шулай остаралар да;

– текстның тәэсир чаралары дигән максат-бурычны үтәгәндә, тел, стиль чараларына анализны шушы авторның, шушы әсәрнең гомуми (беренче чиратта, әдәбият төрен, жанр төрен истә тотып), икенче чиратта, шәхси (хосусый) үзенчәлекләрен ачыклаудан башларга. Авторы кем, тәрҗемәи хәле, ана телен белү, куллану тәҗрибәсе, осталыгы ни хәлдә, ни дәрәҗәдә. Әсәрнең темасы, хикәяләү, тасвирлау куәсе ни дәрәҗәдә, телне белү чыганаклары нидән килә, типик хаталары бармы, ул аларны үзе ничек аңлата, ничек кабул итә, редакцияләү куәсе бармы, холкы нинди, төзәтүләргә сәләте бармы?

Бу сорауларга җавапны редактор әсәрне беренче уку барышында ук, төзәтергә керешкәнче, төп анализга керешкәндә үк ачыкларга тиеш. Сискәндерә, уйландыра торган, махсус ачыклауны таләп иткән сораулар әсәрне укый башлагач бик кечкенә факт, детальләрдән үк борынлана. Әйтик, текст *Кичә килделәр алар безгә* дигән җөмлә белән башлана икән, автор урынсыз инверсия белән мавыкмыймы? дип шик белдереп, уку барышында аны игътибарда тотасың. Яисә контроль*лек*, хата*лык*, тырыш*лык,* мәрхәмәтле*лек* кебек ясалмаларга колак торгызып, аның *-лык/-лек* белән “чирләмиме” дигән сорауны ачыкларга тырышасың. Әгәр дә мондый “кытыршылыклар”ны баштук “карандашка төртеп” куймасаң, аларны әсәр азагында ачыклагач, кире кайтып өр-яңадан укырга мәҗбүр булачаксың.

Әлбәттә, иң мөһиме – “чирне” табу, ачыклау гына түгел, ә аны әсәрнең буеннан-буена төзәтеп бетерү, моның өчен шушы очракка гына кирәкле,

яраклы алымнар табу, редакторлык осталыгыннан файдалана белү. Һәр редакторның үзенә генә хас тел тоемлавы, белем дәрәҗәсе, сөйләмгә мөнәсәбәте үзенчәлекле (авылда яисә шәһәрдә туып тәрбияләнгән, төгәл яисә гуманитар фәннәр белән мавыккан, редакторлык тәҗрибәсен нәшрияттәме әллә матбугаттамы туплаган, эшчәнлеге Казандамы әллә башка төбәктәме бара, остазы кем һ.б.).

Дөрес, телгә-сөйләмгә битараф булган кеше гомумән дә юк, ә андый редактор була да алмый. Тик ул барыбер телгә үзенчә мөнәсәттә, робот редакторлар юк. Гәрчә кайбер авторлар аларны шундый дип күз алдына китерергә тели. Шул ук вакытта ул шәхси үзенчәлеген өстен куярга, субъективлыгын күрсәтергә яисә тагарга тиеш түгел. “Мин редактор, димәк, нидер сызарга тиеш”, дигән чирдән ерак торганда гына ул үз эшенең белгече була ала. Редакторның субъективлыгы менә бу аспектта аерылып тормаска тиеш: язма сөйләмгә һәм әйтмә сөйләмгә тигез карый, кайсына да өстенлек бирми, берәрсе белән мавыкмый (әйтик, *-лар/-ләр, -лык/-лек* кушымчалары һ.б.); диалектизм, җирле сөйләм үзенчәлекләренә фәнни нигездә, объектив карый, бу юнәлештә әдәби нормаларны яхшы белә, саклый; шәхси сөйләме үзенчәлекләрен (фонетик, морфологик, лексик, орфоэпик, афоризм-гыйбарәләрен) өстен күрми, такмый (шагыйрь редакторлар, мәсәлән, инверсия күренешенә битараф яисә хуплап караучан); алынмаларга “мөкиббәнлек” яисә, киресенчә, аларны “күрәалмау”; норма төшенчәсенә “акыл” белән карау, тел һәм сөйләм нормаларын аеру, вариативлык төшенчәсенә фәнни-гамәли караш. Норманы “күсәк” итмәскә, шаблон-калып тәэсиренә бирешмәскә; автор авторитетына мөкиббән китмәскә (Г.Бәширевнең “гүзәл” сүзенә мөнәсәбәтен, аны татар теленнән “сөреп” чыгару куркынычы тудыруын искә төшерик. “Хатын – тормыш иптәше”н дә искә төшерергә кирәк). Зәвыкка – объективлык!

Редактор авторның кимчелекләрен күрсәтү белән канәгатьмичә, аның белем дәрәҗәсен үстерү өчен дә тырышуы сорала (тел фәненең, сөйләм фәненең категорияләрен, телнең төп законнарын, сүз ясалышы, сүз бәйләнеше закончалыкларын, сөйләмият нигезләрен һ.б. әсәрен редакцияләү барышында авторның бу өлкәдәге белемен, күнегүләр эстәү, күнегүләр ясарга омтылышын хупларга, кыенлыкларны җиңәргә булышырга кирәк. Тел, сөйләмият фәнендәге яңалыклар белән танышырга, дәреслекләр, сүзлекләр белән актив эш итүенә ирешергә кирәк.

Шул ук вакытта редактор, “мөкиббән китмәү”не онытмаган хәлдә, авторның яхшы якларына (белеменә, һөнәри осталыгына – белгечлеге буенча термин-атамаларны өйрәнүгә) битараф булмас.

**Сөйләмне төзәткәндә бөтенлек хисе**

Бик гомумиләштереп әйткәндә, редактор хезмәтенең максаты, асылы һәм нәтиҗәсе – ул төзәтергә алынган әсәрнең бөтенлегенә ирешү булып чыга. Эчтәлек бөтенлегенә, форма (композиция) бөтенлегенә. Дәреслегебезнең

буеннан-буена без моңа диккатьне юнәлтә, кисәтә килдек. Аеруча текст, композиция турындагы бүлекләрдә махсус игътибар бирдек. Сөйләм категориясен үзәккә куеп, редакцияләү эшчәнлегенең асылы да сөйләм эшчәнлегеннән тора, дигән концепцияне куерткан бүлектә нәкъ менә шушы хакта да сөйләнергә тиештер дә. Әсәрне сөйләм объекты дип шәрехләү моңа нигез була ала.

Менә ни өчен без бүгенге редактор сөйләм нәзәриясеннән, сөйләмият фәне нигезләреннән һичшиксез хәбәрдәр булырга тиеш дип саныйбыз. Бар әдәбияттән файдаланырга кирәк (Низамов И.М. Уем – тел очында... Татар сөйләме нигезләре.–Казан, 1995 һ.б. "Әдәбият"не кара). Ә биредә без сөйләм закончалыкларының нәкъ менә турыдан-туры редакцияләү эшенә кагылган кайбер әһәмиятлеләрен генә искә төшерербез.

Мөстәкыйль фән тармагы булганга, сөйләмият үзенең берәмлекләре (категорияләре) белән эш итә. Алар башка фәннәрнекеннән, аерым алганда тел гыйлеменекеннән, аерылып тора. Шуңа күрә атамалары да башкаларныкыннан мөмкин кадәр аерымрак булырга тиеш. Алар чагыштырмача мөстәкыйль, бербөтен фикерне белдерергә тиеш. Сөйләмиятнең төп берәмлеге, асылы бербөтен фикерне белдерү булу белән бергә, ул әле сөйләмне язуда гына түгел (лингвистиканың берәмлекләре язып анализлауга көйләнгән), бәлки телдән әйткәнне дә, күрсәткәнне-ымлаганны да һ.б. теркәргә (фиксацияләргә) сәләтле булырга тиеш, ягъни без ул берәмлекне фәнни максатларда язып та, укып та, күреп тә, ишетеп тә тоя алырга тиешбез булып чыга. Кыскасы, сөйләмиятнең төп берәмлеге, аны эчтәлек ягыннан да, төзелеше ягыннан да анализлау өчен кулай берәмлек –ул хәбәрләмә дип саныйбыз.

**Хәбәрләмә** – ул мөстәкыйль бер конкрет фикернең мәгълүм бер сөйләм системасында сөйләм мотивлары нигезендә, асылда, тел чаралары белән оешып, телдән әйтү, язу, күрсәтү, ишарәләү һ.б. кебек ысуллар белән теркәлгән (фиксацияләнгән) формасы.

Хәбәрләмә булу өчен өч шарт: 1) уйланылган мәгънә белдерелүе, 2) ситуатив мохит барлыкка килү, 3) мәгълүм бер фактор турында раслап яисә инкарь итеп хәбәр белдерү. Беренче шартның үтәлүе өчен хәбәрләмәнең грамматика кагыйдәләренә тәңгәл булган җөмлә, фраза, тезем, микротекст һ.б.) булырга тиеш. Алар максатчан уйлап төзелгән булырга, грамматика норма-кагыйдәләренә буйсынган мәгънәви бөтеннәр тәшкил итәргә тиеш (Свинцов, с.85, 94).

Кешенең фикере хәбәрләмә хәлендә оеша. Хәбәрләмә (высказывание) – атомнар, ә төшенчәләр (исемнәр) атом эчендәге электрон, протоннар һ.б. Аларның (атом эчендәгеләрнең бәйләнешен) тел төзелеше өйрәтә. Ә менә атомнарның бәйләнешен сөйләмият фәне (текст грамматикасы) өйрәнергә тиеш.

Бу берәмлек тел ярдәмендә формалашса да, баштагы мәлдә ул конкрет лингвистик берәмлекләр белән тәмам ныгымаган була. Әгәр әйтү яисә язу хаҗәте тоткарланса, хәбәрләмә шулай, конкрет бер калып-формага

салынып бетмичә дә кала. Эчтән үз-үзең белән “сөйләшкәндә” дә, мәсәлән, шулай килеп чыга. Хәбәрләмәне телдән әйткәндә дә эле фикернең барлык төшенчәләренә дә сүз табу ихтыяҗы булмый – кайберләрен ишарә, ымнар, интонация, паузалар алыштыра ала, аеруча төшенчәләрне бәйләү чаралары конкретлаштырылмаган килеш кала. Хәбәрләмәне язып белдерергә кирәк булганда инде төшенчә дә, аларны бәйләү юллары да тел һәм башка чаралар – тыныш билгеләре, сурәт, тамгалар һәм башкалар – белән конкрет тәгаенләнә, димәк, эчтәлеккә муафыйк форма эзләнә.

Моңардан мөһим бер нәтиҗә ясап китик: кеше аңында фикер катып калган, үзгәрмәс сүз калыбы булып оешмый, бәлки хәбәрләмә бер кешенең (С.И.нең) аңында туып, икенче кешенең (С.А.ның) аңына барып җиткәнче, С.И.нең, С.А.тының кемлегенә, С.Н.нә, С.Ш.на карап төрле формаларга керә ала. Бер эчтәлекле хәбәрләмә бер аралашу процессында ук төрле формалы булырга мөмкин.

Кечкенә генә бер эксперимент ясыйк: театр кассасына билет белешергә кергән кешене күзәтик. Кеше белешә. Билет юк. Аның аңында: “Бүгенге спектакльгә билет беткән”, дигән хәбәрләмә формалаша. Әмма шушы хәбәрләмәне ул адресатка төрле формаларда җиткерә ала. Берничә ситуацияне карыйк. Мәсәлән, урамда ук көтеп торган иптәшенә ул сүзсез хәбәрләмә белән – күз карашы белән, баш яисә кул ишарәсе белән, башка мимик чаралар белән белгертә. Телдән әйтүнең, язмача белдерүнең дә формалары бик күп төрле була ала. Менә берничәсе: “Юк”, “Беткән”, “Кассир иртәгә килегез, диде”, “Безне генә көткәннәр”, “Җилләр искән” һ.б.

Әлеге нәтиҗәнең нигезле икәнен бер үк эчтәлекле хәбәрләмәнең аны язган авторның яисә төзәтергә алынган редакторның төрле вариант-формаларга кертә алуы, төрле тәрҗемәченең төрлечә тәрҗемә итә алуы да раслый. Менә мисаллар*: “Үзәк статистика идарәсе белдерүенә караганда, 17 августта бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар 70 миллион гектардан җыелып алынды*” (С.Т., 1981, 21 авг.). Шушы хәбәр белән танышкан журналист иптәшенә болай ди: *“Менә кара, 17 августка 70 миллион гектардан җыеп алынган. Бөртекleләр, бөртекле-кузаклылар. Үзәк статистика белдерүендә шулай диелгән”* (Сөйләшүләрдән). Яисә тәҗрибәле бер редакторның төзәткән текстыннан мисаллар: Авторныкы: *“Кеше синең турында үзеңнән күбрәк белә”*; редакторныкы: *“Үзеңне беләсең килсә, кешеләрдән сора”*; авторныкы: “*Экспортка бик күп төрле товар озатыла”*, редакторныкы: “*Экспортка нинди генә товар озатылмый”*.

Бу мисаллар хәбәрләмәнең формасын камилләштерүнең мөмкинлекләре чиксез икәнен сөйли. Килешегез, бу бит гамәли әһәмиятле нәтиҗә, ул барыбызга да, беренче чиратта редакторларга, кагыла – уеңда оешкан фикер берәмлеген үзгәртергә, адресатка җиткергәнче кире кайтып-кайтып, кат-кат уйларга, төрле сүзләр һәм бүтән чаралар ярдәмендә тәмам үтемле, ачык, аһәңле итеп “шомартырга” мөмкин икән.

Искә төшерик әле: сөйләм, беренче чиратта, мантыйкый (логик) нигездә оеша. Димәк, хәбәрләмә – мантыйкый фикерләү нәтиҗәсендә туган берәмлек. Бербөтен күренеш дип караганда, мантыйкый фикер һәм аның чагыштырмача бөтен өлешләре нидән гыйбарәт? Формаль логика фәнен искә төшерик. Фикри хәрәкәт (уйлау процессы) үзара бәйләнгән өч берәмлек белән эш итә: төшенчә, хөкем һәм фикри нәтиҗә. Әлбәттә инде, формаль логика бу категорияләрне, әлеге дә баягы, катып калган итеп күз алдына китереп тикшерә, хәрәкәттәге, ягъни сөйләмдәге хәлен диалектик күзалламый. Шуңа күрә дә фикер берәмлекләренең сөйләмгә мөнәсәбәтен хәзергә сөйләмият фәне ачыкларга тиеш. Аның категорияләрен редакцияләү эшендә кулланырга күнегү күп кенә кыенлыктан котылырга юл ача да. Шул ук хәбәрләмәне алсак та, бербөтен фикри берәмлекнең мәгънәви күләме бер хөкем дә, уннарча, йөзләрчә хөкемнәр белән дә белдерелергә мөмкин. Димәк, хәбәрләмә үзе дә зур сөйләм күләмендә дә, кечкенә күләмдә дә була ала. Редакцияләү барышында әлеге амплитуданың һәм кечкенә ягын, һәм зур ягын күзалларга кирәк була. Бу – зур осталык сорый. Башта редактор барлык хәбәрләмәләргә дә хас уртак сыйфатларны күзалларга өйрәнергә тиеш. Әлегә кадәр без мисал итеп китергән хәбәрләмәләр типик, уртакул хәбәрләмәләр иде. Алар: 1) мәгънәви яктан чагыштырмача бербөтенлеккә, тәмамланганлыкка ия; 2) аларда төшенчәләрне белдерү һәм аларны үзара бәйләү өчен лексик, грамматик чаралар сайлау сөйләм мотивларына бәйле рәвештә үтәлә, димәк, теләсә кайсы хәбәрләмәнең формалашуы нигезенә теге йә бу сөйләм мотивы салына.

Хәбәрләмә төшенчәсе бүгенге редактор фикерендә синтаксик бөтен (микротекст, макротекст) һәм текст төшенчәләре белән тәңгәлләштерелә, шулар хакында укыган, өйрәнгән закончалыклар истә тотылып, гамәли эшчәнлектә шуларга нигезләнә. Шуларга бәйле кайбер гамәли кирәкле нигезләмәләрне искә төшереп китү урынлы булыр дип уйлыйбыз. Һәрхәлдә һәр очракта без хәбәрләмә төшенчәсен күз алдында тотабыз. Шуңа күнегергә тәкъдим итәбез.

Синтаксик бөтенне грамматик категория буларак тасвирлый торган төп асыл билге, ул да булса, аны ниндидер өлешләрдән “бөтенгә” әверелдергән **бәйләгеч чара.** Редактор эшенең осталык сыйфатларыннан иң әһәмиятлеләреннән берсе – ул татар теленең бәйләү чараларын нечкә тоемлау, аларны тәртип-система белән белү, гамәлдә куллану осталыгына ирешү. Редакторга булышлык күрсәтү максатыннан без заманында “Уем – тел очында...” хезмәтенең бөтен бер бүлеген бәйләү чараларына (алар тел чараларына һәм телдән башка чараларга төркемләнә) махсус багышлап, аларны бәйнә-бәйнә классификацияләнгән һәм куллану мөмкинлекләрен барлауга багышлаган идек. Бу курсны үткәндә аларга кире кайтып, куллану җаен табарга омтылып карарга киңәш итәбез.

**Күнегү**

1. *Тел* сүзенең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен барлап чыгыгыз. Редакторлык эшчәнлегендә аның кайсы төрләре кулланыла? *Тел* сүзенең синонимнары бармы? Сез аларны бутамыйсызмы? Мәсәлән, *тел* һәм *сөйләм* сүзләренең нинди төсмерләре уртак һәм аерым? Тел һәм сөйләм төшенчәләре катнашкан мәкальләрне искә төшерегез әле (15 ләп);

2. *Һ* авазы сүз башында *(һәм, һаман*), сүз уртасында (*шәһәр, аһәң),* сүз ахырында (*эһ, шаһ)* килгән 10–15 мисал табып, шуларны дөрес әйтү күнекмәләре ясагыз;

3. *Бәләк, калтырча, киндерә, җилпуч, шүре, шөшле* сүзләренең мәгънәсен беләсезме? Сез аларны кулланасызмы? Туры һәм күчерелмә мәгънәләрендә? Бу берәмлекләрне нинди мәкаль, әйтемнәрдә очратканыгыз бар?

4. *Менгерү, менгезү, мендерү* сүзләрен Сез бер мәгънәле дип саныйсызмы, әллә аларда төрле мәгънә төсмерләре бармы?

5. *Ак* – үзенә бер мәгънәле сүз,; *кара* – үзенә мәгънәле; *ак-кара* исә үзенә аерым мәгънәле. Аның мәгънәсе нидән гыйбарәт? Шушы рәвешле ясалган 10–15 парлы сүз табарга яисә үзегез ясарга тырышыгыз. Ясалу рәвешләрен төрләндерергә омтылыгыз (*көнен-төнен, керәле-чыгалы* һ.б.). Мәгънә төсмерләрен аңлатып бирегез;

6. *Әзерләү – хәзерләү, ошаш – охшаш, кара-каршы – капма-каршы* паронимнарының мәгънә аерымлыкларын ачыклагыз. Үзегез яисә таныш-белешегез “бутый” торган шундый берәмлекләрне барлагыз;

7. Бер генә төрле язылып та *(к),* төрлечә әйтелергә тиешле (мәсәлән, *къ – канат, к – канат, къә – канәгать, кә – кәнәфи*) авазларын дөрес әйтүдәге кыенлыкларны Сез ничек җиңәсез? Шушындый берәмлекләрдән 6–8 төркем (оя) җыеп, аларны дөрес әйтү күнекмәләре үтәгез. Җырчыларда, артистларда, радио, телевидение чыгышларында, балаларда очрап, Сезне борчыган кимчелекләрне барлагыз;

8. *Белгертү – белдертү, үсенте – үренте* сүзләрен Сез бер мәгънәле дип саныйсызмы, әллә аларда төрле мәгънә төсмерләре бармы?

9. *Авыз турсайту, авызны арандай ачу* фразеологизмнарын кулланасызмы? Алардагы *турсайту, аран* сүзләре нәрсәне аңлата?

10. *Икътыйсат, мантыйк, мөнбәр, җөмһүрият* сүзләренең мәгънәсен беләсезме? Кулланасызмы? Шундый төрдәге дип исәпләнгән, Сез бүгенге сөйләмдә ишеткән яисә үзегез дә куллана башлаган 3–4 берәмлекне атагыз әле;

11. Бер генә төрле язылып та *(г),* төрлечә әйтелергә тиешле (мәсәлән, *гъа – гарасат, га – гармун, гъә – гарьлек, гә– гәрәбә*) авазларын дөрес әйтергә Сез ничек күнегәсез, балаларыгызны ничек өйрәтәсез? Шушындый берәмлекләрдән 6–8 төркем (оя) җыеп, дөрес әйтү күнегүләре башкарыгыз;

12, *Барлык* төшенчәсенең (урысча *все* мәгънәсендә) синонимы күп (мәсәлән, *бөтенесе, барысы, җәмгысы, барчасы*). Шуларны барлагыз әле. Сез аларны мәгънә төсмерләренә карап кулланасызмы, әллә очраклы рәвештә генәме?

13. Бүгенге матбугатта урын ала башлаган *вәзгыять, ганганә, мөхтәбәр* , *нәмзәт* сүзләренең мәгънәсен беләсезме? Кулланасызмы? Тагын нинди "иске" сүзләр кайтырга тиеш дип санныйсыз?

14. Исәнләшер өчен нинди сүз, гыйбарәләр кулланасыз. *Сәлам*гә ничек җавап бирәсез. Нинди җавапны, мөрәҗәгать сүз (гыйбарәләрен) дөрес түгел дип саныйсыз?

15. Язуда бер генә төрле теркәлеп тә *(в)*, төрлечә әйтелергә (сүз башында, уртасында, азагында) тиешле (мәсәлән, *уа-үә – вакыт, авыл, Әнвәр вәсвәсә, Сәвия, боравы, хәлвә һәм ва-вә – валюта, вышка, совет, состав, варвар, Вәлиев*) авазларын дөрес әйтүдә һәм язуда кыенлык кичерәсезме, башкалар дөрес әйтмәгәндә, шуны тоясызмы? *Вәзир, вафат, вөҗдан* кебек гарәп-фарсы тамырлы сүзләрдәге *в* авазын ничек әйтәсез. Шушындый өч төрле әйтелешле берәмлекләрдән 6–8 төркем (оя) туплап, аларны дөрес әйтү күнекмәләре башкарыгыз;

16. *Алаканат, алпамша, алтатар* сүзләренең ничек ясалышын, нинди мәгънә белдерүен аңлатыгыз. Сез аларны кайсы әдәби һәм фольклор әсәрләрендә очратасыз?

17. Әйтмә сөйләмдә урыс алынмалары белән белдерелә торган *варенье, кухня, сдача, подъезд, переход, подписка, самолет, вертолет, аэропорт* терминнарына сездә төрдәш татарча берәмлекләр кулланылмыймы? Тәкъдимнәрегез юкмы?

18. "Үзешчән сәнгать конкурсы да *булды,* әлбәттә, Сәхнәдә нибары дүрт хатын-кыз *булса да* аның программасы эчтәлекле иде (Таң, 1982, 13 март). Текстны төзәтергә, *булу* фигыленең синонимнарын табарга. Контекстуаль синонимнарның мөмкинлекләрен аңлатырга.

19. Фермада эшне *җиңелләштерү буенча* бернинди чара күрелми (Игенче, 1978, 3 авг.); Администрация белән берлектә зур *түземлелек белән алып барган* бу эше эзсез калмаган (С.Т., 1979, 19 авг,); Шундый *мөмкинчелекләрдән чыгып* ул киләсе елда да савымны арттырырга ниятли (Йолдыз, 1976, 11 дек.). Төзәтергә. Урынсыз аффексларны һәм мөнәсәбәтле сүзләрне (ярдәмче фигыльләрне) дөресләү чаралары табарга;

20. ... Ашау-эчү ягыннан да *зарланырлыклары* юк (С.Т., 1978, 1 окт.); Бу – балаларда яңа гаиләгә карата билгеле мөнәсәбәтләр урнашуына *бәйлекле* (Игенче, 1978, 3 ноябрь); Н.Хәйруллин һәм Ф.Сафиуллин үзләрен оста *рәссамчылар* итеп күрсәттеләр (Коммунизмга, 1979, 1 март): Техника кадрлар белән *комплеклаштырыла* (Шунда ук). Төзәтергә. Татар теленең сүз ясау чараларын барларга, аларның дөрес кулланылуына ирешергә.

# Йомгак

Көндәлек, гомерлек шөгыле басма текстны төзәтү булган редактор эш барышында нинди генә чыганакларга, белешмә, китапларга мөрәҗәгать итмәс! Нинди генә максат-ният белән, нинди генә теләк-ихтыяҗын канәгатьләндерергә омтылып, төрле басмаларга карашын текәмәс. Иң әүвәле аңарга, бигрәк тә яшь редакторга – тәҗрибәсе әле җыелып кына килгән белгечкә, гап-гадәти эшендә кинәт төртелеп, югалып, аптырап калган мизгелләр дә килеп чыгып тора. Шул мизгелдә аңарга һөнәри әлифбасының асылын, хәсиятен төшендергән, әлифтән башланган менә шушындый дәреслек, кулланмаларга да мөрәҗәгать итмичә булмый. Моңа уңайсызланмаска, олы башыңны кече итеп булса да гади генә кагыйдәләргә дә кабат-кабат күз салырга тарсынмаска кирәк. Дәреслегебез редактор эшчәнлегенең күп еллык тәҗрибәсен искә алып, аның “механизмын”, өйрәнү һәм куллану методикасын фәнни нигезгә салып, шул ук вакытта көндәлек куллану өчен уңайлы итеп төзергә омтылынды.

Тәкъдим ителгән күнегүләрне даими үти бару, тәҗрибәле редакторларның эшен, “лаборатория”сен, архивын игътибар белән күзәтеп, күнегү мисалларын алардан үзең дә туплый бару – осталыкны эстәүнең өстәмә чарасыдыр. Редакторлык тәҗрибәсен барлаган һәр чыгыш, язмага диккатьле булырга, без тәкъдим иткән әдәбият исемлегенә дә әледән-әле күз салып, бу бай хәзинәдән системалы файдаланырга өйрәнергә киңәш итәбез.

Бу хезмәттә редактор эшчәнлегенең үзенчәлекләрен гомумиләштергән нәзәри нигезләмәләрне, гамәли әһәмиятле нәтиҗәләрне кабатлап тормыйбыз – алар һәр теманың эчтәлегендә тәгаенләнгән, ихтыяҗ туганда куллануның ысул, алымнары тәгаен бәян ителгән. Тырышып үзләштерергә, алардан файдалану тәҗрибәсен көннән-көнгә. китаптан-китапка, басмадан-басмага бөртекләп туплый барырга гына кирәк.

Хезмәтебезнең төп максаты һәр китап, журнал, газетны, радио,-телевидение тапшырулары текстында бер генә хатага да урын бирмәү теләге белән көн-төн тырышучы, бөтен гомерен шуңа багышлаган гади хезмәт кешесе – редакторның көндәлек эшенә ярдәм итү булса, шул ук вакытта аларның һәркайсында үз һөнәренә, үз хезмәте нәтиҗәсенә (китап исеме белән гомумиләштерелгән һәр басмага, текстка) карата горурлык хисе дә тәрбияләүдер. Без халык, милләт мәнфәгатендә изге эш башкарабыз. Китап – ул милләтебезнең йөзе. Китап – ул мәңгелек! Кулымнан килсә, мин һәр китапның титул битенә күренекле язучыбыз Ибраһим Газыйның шушы сүзләрен урнаштырыр идем: “Дәүләтләр яшәгән – беткән, халыклар яшәгән – сөяге дә калмаган. Ай калган, кояш калган да китап калган...”.

# Әдәбият

## Төп әдәбият

*Вәлиев М.Х.* Китап редакторы: иҗат һәм оештыру эшчәнлеге /Дәреслек.– Казан: Милли китап, 2006.– 143 б.

*Вәлиев М.Х.* Милли нәшрият һәм китап редакторы: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы.– Казан: Мәгариф, 2006.– 351 б.

*Голуб И.Б.* Конспект лекций по литературному редактированию.–М.: Айрис-Пресс, 2004.–258 с.

*Мильчин А.Э.* Методика редактирования текста.– 3-е изд., перераб. и доп.–М.: Логос, 2005.– 320 с.

*Накорякова К.М.* Редактирование материалов массовой информации.– М.: Изд-во Моск. ун-та, 1982.– 112 с.

*Низамов И.М.* Матбугатның тәэсирле сүзе: Газета лексикасы мәсьәләләре.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1981.– 144 б.

*Низамов И.М.* Татар социолингвистикасы.– Казан: Казан ун-ты нәшр., 2006.– 152 б.

*Свинцов В.И.* Смысловой анализ и обработка текста.– М.: Книга, 1979.– 272 с.

*Сикорский Н.М.* Теория и практика редактирования: 2-е изд. испр. и доп. – М.: Высш.шк., 1980.–328 с.

*Татар теленең* практик стилистикасы һәм әдәби редакцияләү буенча курс эше. Темалар һәм методик киңәшләр. Төзүчесе М.Мәрдиева.– Казан: Казан ун-ты нәшр., 1984.– 12 б.

*Харрасова Р.Ф.* Әдәби редакцияләү: Махсус дисциплина буенча программа.– Казан: КДУ, 2007.–53 б.

*Хәсән Сарьян* – Агыйдел егете: хикәяләр, мәкаләләр, истәлекләр. Төз. Р.М.Миңнуллин.– Казан: Татар.кит.нәшр., 2006.– 479 б.

## Өстәмә әдәбият

*Әдәби редакцияләү* // Махсус дисциплина буенча программа. Төзүчесе Р.Ф.Харрасова.–Казан: КДУ, 2007.–53 б.

*Вьюкова Т.Б.* Восемьдесят пять радостей и огорчений. Размышления редактора: 2-е, доп.изд..– М.: Книга, 1986.– 239 с.

*Гарифуллин В.З.* Язар сүзең булса…: Журналист текстын оештыру ысуллары.– Казан: Мәктәп, 2000.– 172 б.

*Закон Российской Федерации* «Об авторском праве и смежных правах».– М.: Ось-89, 2000.

*Мәһдиев Мөхәммәт.* Ачы тәҗрибә авазы // Казан утлары, 1991, №1–2, 88–120 б.

*Справочная книга* редактора и корректора.– М.: Книга, 1984.- 486 с.

*Терехова В.С.* Литературное редактирование: Учебное пособие.– Л.: Изд-во Ленингр. ун-та, 1975.– 94 с.

**Кереш, Беренче, Икенче темаларга**

*Былинский К.И., Розенталь Д.Э.* Литературное редактирование: Изд.втор., исп., доп. –М.: Искусство, 1961.– 356 с.

*Әхмәтҗанов М.И.* Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000.–180 б.

*К.Маркс, Ф.Энгельс, В.И.Ленин* әдәбият һәм сәнгать турында.–Казан: Татар.кит.нәшр., 1976.– 559 б.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983.– 542 б.

*Печать,* радиовещание и телевидение Татарии 1917–1980: Сборник документов и материалов.–Казань: Татар.кн.изд-во, 1981.– 298 с.

*Фәттах Н.С.* Шәҗәрә: Тарихи-лингвистик эзләнүләр.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1990.– 325 б.

**Өченче темага**

*Ибраһимов Г.И.* Әсәрләр. Сигез томда. 8 т. Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр. Казан: Татар.кит.нәшр., 1987.– 482 б.

*Исәнме, китап!* Здравствуй, книга! Казан: Татар.кит.нәшр., 1989.– 252 б.

*Каримуллин А.* Книги и люди.– Казань: Татар.кн.изд-во, 1985.–303 с.

*Каримуллин А.* Татарская книга пореформенной России.–Казань: Татар.кн.изд-во, 1983.–320 с.

*Кәримуллин Ә.Г.* Китап дөньясына сәяхәт: Татар басма сәхифәләреннән.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1979.– 208 б.

*Ялкынлы* еллар авазы. Публицистика һәм тормыш.–Казан: Татар.кит.нәшр., 1982.–248 б.

**Дүртенче темага**

*Гальперин Н.Р.* Текст как объект лингвистического исследования.–М.: Наука, 1981.– 140 с.

*Гарифуллин В.З.* Газета текстының төзелеше. –Казан: Татар.кит.нәшр., 1995.–104 б.

*Курбатов Х.Р.* Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы.–Казан: Татар.кит.нәшр., 1971.– 192 б.

*Мучник Б.С.* Человек и текст. Основы культуры письменной речи.– М.: Книга, 1985.– 252 с.

*Низамов И.М.* Уем – тел очында. Татар сөйләме нигезләре.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1995.– 287 б. (Икенче бүлек).

*Сафиуллина Ф.С.* Текст төзелеше. Югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма.–Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993.–264 б.

**Бишенче темага**

*Гаймакова Б.Д.* Методика и практика редактирования телевизионных передач.–М.: Изд-во Моск. ун-та, 1975.– 58 с.

*Зарва М.В.* Слово в эфире. О языке и стиле радиопередач.– М.: Искусство, 1971.– 177 с.

*Памятная книжка* редактора.–М.: Книга, 1980.– 288 с.

*Юсупов Р.А.* Икетеллелек һәм сөйләм культурасы.–Казан: Татар.кит.нәшр., 1987.– 214 б.

**Алтынчы темага**

*Виноградов С.Н. һәм башкалар.* Логика: Урта мәктәп өчен дәреслек/ Тәрҗемә.–Казан: Таткнигоиздат, 1953.–179 б.

*Гарифуллин В.З.* Журналист текстында дәлил.– Казан: Казан ун-ты нәшр., 1996.– 22 б.

**Җиденче темага**

*Рабочая книга* редактора районной газеты: Опыт. Методика. Рекомендации.– М.: Мысль, 1988.– 576 с.

**Сигезенче темага**

*Әдәбият* теориясенә кереш.–Казан: Татар.кит.нәшр.,1987.–303 б.

**Тугызынчы темага**

*Бахарев Н.Е.* Структурно-функциональное развитие заголовков/Автореф. канд. диссертации/.–Алма-Ата, 1971.–22 с.

*Блисковский Э.Д.* Муки заголовка.– М.: Книга, 1972.–205 с.

**Унынчы темага**

*Ибраһимов С.М.* Газета теле: Студентларга кулланма.–Казан: Казан ун-ты нәшр., 1971.–52 б.

*Ибраһимов С.М., Сафиуллина Ф.С.* Практик стилистика: Күнегүләр җыентыгы.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1978.– 144 б.

*Низамов И.М.* И туган тел... “Татар теле – дәүләт теле “ сериясе –Казан.: Мәгариф, 1998.– 207 б.

*Низамов И.М.* Татар терминчылары, берләшегез!– Мәдәни җомга,–2006.– 29 дек.

*Низамов И.М.* Ярдәмең берлән синең.../Фәнни публицистика. Казан: Мәгариф, 2008.– 239 б.

*Рамазанов Ш.* Татар теле буенча очерклар.–Казан: Таткнигоиздат. 1954.– 200 б.

*Фәйзуллин С.* Ике тел хәзинәсе.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1964.– 108 б.

*Хаков В.Х.* Татар теле стилистикасы: Күнегүләр җыентыгы.–.–Казан: Татар.кит.нәшр., 1980.–142 б.

*Хангилдин В.Н.* Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре.– Казан: Татар.кит.нәшр., 1976.– 96 б.

*Юсупов Р.А.* Икесен дә яхшы бел: “Татар теле – дәүләт теле” сериясе.– Казан: Мәгариф, 2000.– 324 б.

## Кушымта 1

### Автордан кабул ителә торган кульязмага дәүләт стандарты таләпләре

Текст А4 форматындагы ак кәгазьнең бер генә ягына юл хәрефләре белән басыла, баш хәрефләр грамматика кагыйдәләренә ярашлы урында гына куела.

Кызыл юл (абзац) өч хәреф киңлегендә булырга һәм текст дәвамында тигез сакланырга тиеш.

Биттәге юллар саны 29±1, бер юлдагы хәрефләр саны (сүз аралары белән бергә) 60±2. Бит чите кырлары (поля): сулдан 25 мм, уңнан – 10 мм, өстән һәм астан – 20 мм. Компьютер бит читен һәръяктан 20 мм, 14 кегльле юл арасын берярым рәвештә тәкъдим итә.

Бүлек исемнәре яңа биттән башлана; бүлекчә, параграф исемнәре (тамгалары) өстән дә (алдагы тексттан), астагы юлдан да ике интервал белән аерыла.

Кулдан язылырга тиешле (төрле тамгалар, сурәт, формулалар һ.б.) материал кара төстәге язу карасы белән басма шрифт зурлыгындагы хәрефләр белән язылырга тиеш.

Автор нәшрияткә тапшыра торган кульязма нөсхәсенә карандаш белән, сан тәртибен катгый саклап ( 1а, 2б кебек өстәмәләр кертмичә), битнең уртасына цифр сугып чыга. Титул бите – беренче бит, тик аңа цифр сугылмый. Шунда ук автор кульязманың тулаем бит санын, иллюстрация материалы санын күрсәтеп кул куя, тапшыру датасын күрсәтә.

**Кушымта 2**

## Кулъязма тексты өстендә төзәтү билгеләре (тамгалары)

### Алыштыру билгеләре

Бер яисә берничә хәрефне алыштыру:

*ш* *хәт*

*Ниһаять! Ап-ак йомгак кар яуды. ... Бала рәтәхлектән көлеп җибәрде.*

Бер яисә берничә сүзне алыштыру:

*кабаланабыз*

*Тик без аларга сокланубызны белдерергә ашыгабыз, артык якын*

*чамасыз дорфа*

*киләбез, артык каты тотабыз...*

Юл хәрефен баш хәрефкә алыштыру:

*Ул тагын әтнәгә кайтып китте...*

Баш хәрефне юл хәрефенә алыштыру:

*Аның Мәскәүләр белән аралашуы очраклы түгел иде.*

### “Алып ташлау” билгеләре

Бер яисә берничә хәрефне, тыныш билгесен алып ташлау:

*Миллионнар белән эш итә; Быел йортларга җылылыкны бик соң бирделәр; ... аерым бер вакыт аралыгында үтүче процессларга бәя бирү...:*

Бер яисә берничә сүзне алып ташлау:

*Урыны-урыны белән аннан пар күтәрелә. Тагын бер тапкыр кабатлыйбыз.*

Бер яисә берничә юлны (текст өзеген) алып ташлау:

*–Рәхмәт инде... бу хәбәрегез өчен дә,– диде Кадыйр. Капыл гына судьяны бәйрәм белән котлау теләге кабынып киткән иде дә, Таштау ягыннан телефоннан юк-юк-юк дигәнне хәтерләткән пипелдәү тавышы ишетелде.*

**Өстәү билгеләре**

Бер яисә берничә хәрефне, тыныш билгесен өстәү:

*л ,*

*Без кигәндә ул юк иде инде;*

Бер яисә берничә сүзне өстәү:

*еп барсам*

*Мин китсәм, эшең арта дип котың алынды инде.*

**Урын үзгәртү билгеләре**

Бер яисә берничә сүзнең урынын үзгәртү:

*Ашламаган җир бирми аш;*
*Мондый аек, туры аңына сүзләр кешеләрнең акрынлап тәэсир итте.*

Бер яисә берничә сүзнең (текст өзегенең) бер биттәге яки текст эчендәге урынын үзгәртү:

*Абыйсының хуҗалыгы тәмам таркалу хәленә килүен күреп тә Фәйзрахманның җаны телгәләнә. Бөтен өмет абыйсының үзе уңган, үзе булган, сөлектәй егет, җир җимертеп дөнья күтәсе урынга окопта бет симертә яшь гомерен заяга уздыра олы улы Муллагалидә иде, тик ул менә алты ел инде армиядә.*

*Брошюралар алу, лектор тоту өчен 20 мең сум 289 биткә*
*....акча юлланган иде 288 биттән*

**Аеру (ара калдыру) яисә араны бетерү билгеләре**

Сүзләрне бер-берсеннән аеру:

*Фәйзрахманда моны күрә;*
*Татарлар төрле концертларны, милли чараларны нәкъ менәәлеге бинада оештыра;*

Сүзләр арасын бетерү:

*Чуер таш түялгән машиналар килеп-китеп тора;*

**Кызыл юл (абзац) билгеләре**

Кызыл юлдан башлау билгеләре:

*Ни белән үлчәнә үткән гомер? Калган эзләр белән,*
*кеше күңеленә орлык итеп*
*салган сүзләр белән.*

Кызыл юлны бетерү билгеләре:

*Ул Мулланур Вахитов иде.*
*Аны хуплап күтәрелгән алкыш театрның иң ерак почмакларыннан кузгалды.*

Кызыл юл чикләренә алу билгеләре:

*Җитәкләшеп икәү бара,*
*эзләренә ак кар ява*

**Шрифтны аеру (үзгәртү) билгеләре**

Шушы ук шрифт белән җыярга билгесе:

Татарстан Республикасы *Президенты...*

Авыш хәрефләр (курсив) белән җыю билгесе:

Татарстан Дәүләп советы сессиясе

Хәрефләрне аерып-аерып җыярга:

“Ватаным Татарстан” газеты...

Хәрефләр арасындагы аеруны бетерергә:

“В а т а н ы м Т а т а р с т а н” газеты

Ярымкара (пж) итеп җыярга, йә үзгәртергә:

Казан – республикабыз мәркәзе

Ярымкара авыш (пж. курсив) итеп җыярга, йә үзгәртергә:

“В.Хаков укулары” гадәткә әйләнсен иде

Якты (светлый) итеп җыярга, йә үзгәртергә:

**Татарстан радиосы** тапшырулары үрнәк алырлык

Кара итеп (жирный) җыярга, йә үзгәртергә:

Махсус искәрмәдә “Дымлы урында сакларга!” диелгән.

**Төзәткәнне кире кайтару билгесе**

Төзәтмәскә, элеккечә калдырырга:

*Ул тагын, тагын килде...*

**Юлларны тигезләү (бер рәткә тезү) билгеләре:**

Җәйне күрми күзгә кердем...
Күңелем тулып китте.

**Кушымта 3**

**Текст корректурасын төзәтү билгеләре**

Бер яисә берничә хәрефне (тыныш билгесен) алыштыру билгесе

Бер яисә берничә сүзне алыштыру билгесе

Берничә җөмләне, текстның өлешен өстәү, алыштыру билгесе

Бер һәм берничә хәрефне “алып ташлау” билгесе

Хәреф арасын якынайту билгесе

Хәреф арасын ерагайту билгесе

Сызык һәм сызыкча (дефис) билгеләрен кую

Сүзләрнең җөмләдәге тәртибен үзгәртү, дөресләү билгеләре

Кызыл юл (абзац) кую, алу, үзгәртү билгеләре

Шрифт рәвешләрен үзгәртү, төзәтү билгеләре

Авыш хәрефләр (курсив) итү билгесе

Туры шрифт итү билгесе

Ярымкара (пж) итү билгесе

Якты шрифт итү билгесе

Кара шрифт итү билгесе

Ярымкара, яссы (курсив) итү билгесе

Аралар калдыру (разрядка) билгесе

Араларны бетерү билгесе

**Юл араларын төзәтү билгеләре**

Бер юлны алыштыру (төзәтү) билгеләре

Текст эчендәге юлларны (өзекне) алыштыру, төзәтү билгеләре

**Техник типографик кимчелекләрне бетерү билгеләре**

Юл читләрен тигезләү билгеләре

Юл эчендә хәрефләрнең бер рәттә булуын тигезләү билгеләре

Сүз араларын дөресләү билгеләре

Юл араларының тигезлеген дөресләү билгеләре

Юлдан юлга күчерү кимчелеген төзәтү билгеләре

Төзәтмәскә, элеккечә калдырырга

## Эчтәлек

**Кереш сүз .......................................................................... 3 б .**

***Кереш тема:* “Татарча әдәби редакцияләү” курсының предметы, максаты, бурычлары, уку-өйрәнү тәртибе ...... 5**

***Беренче тема*: Редакцияләүнең бурычлары ................... 12**

***Икенче тема:* Редакцияләүнең принциплары ............... 24**

***Өченче тема*: Редакторның һәм редактор хезмәтенең асылы ...................................................................................... 33**

***Дүртенче тема:* Текст. Төрләренә карап төзәтү ........... 51**

***Бишенче тема:* Төзәтү алымнары һәм төрләре .............. 55**

***Алтынчы тема*: Редакцияләүнең мантыйкый нигезләре 63**

***Җиденче тема*: Текстта фактик материалны төзәтү .... 91**

***Сигезенче тема*: Текстның композициясен төзәтү ........ 111**

***Тугызынчы тема*: Баш исемен сайлау, төзәтү ................. 124**

***Унынчы тема:* Редакцияләү – сөйләм эшчәнлегенең бер төре (Текстның тәэсир чараларын, телен, өслүбен камилләштерү) ....................................................................... 135**

**Йомгак ........................................................................ 151**

**Әдәбият ....................................................................... 152**

**Кушымта 1 ........................................................................ 154**

**Кушымта 2 ........................................................................ 155**

**Кушымта 3 ........................................................................ 159**